ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№10 (369)
ОКТЯБРЬ 2022

ЯҢА ЮЛЛАР: ТИГЕЗ ҺӘМ ТИЗ

4 612750 670011

Республиканы руда булмаган төзелеш материаллары белән тәэмин итәбез!

Безнең компания 20 елдан артык эре төзелеш компанияләрен, торак һәм юл төзелеше оешмаларын, тимер-бетон эшләнмәләр заводларын, физик һәм юридик затларны материаллар белән тәэмин итә. Без ышанычлы тәэминатчы абруен казандык, югары профессиональлеккә ия коллектив булдырдык, руда булмаган төзелеш материалларын җитештерүдә һәм сатуда зур тәҗрибә тупладык.

Шулай ук төрле фракцияләрдәге башка руда булмаган материаллар да бар (ком-чуерташ, баетылган ком-чуерташ, вак таш-ком катнашмалары, вак таш ясау калдыклары һ.б.).

Продукция сыйфаты
Безнең продукция кайбер параметрлар буенча ГОСТ

Зур запаслар
Без сәгать саен 1000 тоннага кадәр материал төяп җибәрәбез

Материалларны – заказ белән
Без билгеләнгән таләпләргә туры килерлек теләсә нинди материалны җитештерә алабыз

КАЗАНСКИЕ НЕРУДНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

«Казан руда булмаган материаллар» ҖЧҖ

Тел. +7 (843) 207-10-00
Адресы: Казан ш., Магистраль ур., 66 нчы корылма
E-mail: sales@knm.com.ru

www.knm.com.ru

Реклама

КАЗАНСКИЕ НЕРУДНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

Татарстанда руда булмаган материаллар җитештерәбез һәм китереп бирәбез

ЧУЕРТАШТАН ЯСАЛГАН
ВАК ТАШ

Чуерташтан ясалган вак таш — Татарстанның руда булмаган материаллар базарында яңа продукт. Граниттан ясалган вак ташка заманча алмаш.

Дөрес сайлау!

Гранит һәм чуерташтан ясалган вак ташларның үзлекләренә чагыштырма таблица

Күрсәткече	Граниттан ясалган вак таш	Чуерташтан ясалган вак таш
Ваклану маркасы	М1400	М1200 - М1400
Ышкылып уалучанлык	И1	И1
Шәкеллелек	Л-10 (ваклары 10% ка кадәр)	Л-10 (ваклары 10% ка кадәр)
Суыкка чыдамлык	F300	F150
Бәясе	**Кыйммәт**	**30% ка арзанрак**

Ихтыяҗлары өчен тулысынча туры килә:

Автомобиль юллары төзелеше

Бетон конструкцияләр һәм эшләнмәләр җитештерү

Шәхси хуҗалыклар

Күпләп сату бүлегендә заказ бирү өчен:

+7 (843) 207-10-00

КАЗАНСКИЕ НЕРУДНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

«Казан руда булмаган материаллар» ҖЧҖ

Тел. +7 (843) 207-10-00
Адресы: Казан ш., Магистраль ур., 66 нчы корылма
E-mail: sales@knm.com.ru

www.knm.com.ru

Реклама

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

БУ ДА ФЕЙК ТҮГЕЛ

Татарстандагы юлларга зарлану инде күптән онытылды. Безнең юлларда тормыш кайный: кайдадыр зур тизлекле автомобиль трассасы гөрли, кайдадыр вакытлыча сузылганы эшен дәвам итә. Ком өемнәре магистральләргә әверелә: тизлек ягыннан караганда, бәлки, киләчәктә алар буенча җилдерәчәк машиналар җәһәтлегендә түгел дәдер, әмма эш бара. Һәм бу фейк түгел, чыннан да шулай. Моңа инану өчен кулыгыздагы басмабыз битләре буенча сәфәргә чыгарга чакырабыз.

Сезнең зур тизлекле редакциягез

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Ксения Сёмина, Ландыш Фәезова
Фотографлар: Александр Ефремов, Илнар Өметбаев
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта Рамил Гали фотосы.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–2996
Басарга кул куелды: 14.10.2022
Басмадан чыкты: 20.10.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 101 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

КҮМӘК ЭШ ТАШ КҮЧЕРӘ

Рыбнорядская мәйданы (хәзерге Тукай мәйданы) Казан тарихында каты өслек җәелгән беренче урам санала. 1829 елда бу урамга таш түшиләр. Моңа кадәр шәһәр урамнары һәм мәйданнарына иң яхшы дигәндә дә – бүрәнә, ә тротуарларга такта түшәлгән була. Таш салу эшендә казанлыларга император Александр I ярдәм итә: ул әле 1812 елда ук шәһәргә керүче барлык судноларга урам-мәйданнарга салу өчен 130 лап таш ала килергә боера. 17 ел эчендә шактый таш җыела, һәм казанлылар ул арада инде бакыйлыкка күчкән патшаның әмерен зур тырышлык белән үтәргә керешә. 1833 елга Крепостная (Кремльдә), Рыбнорядская, Проломная, Воскресенская, Петропавлов, Кунак сарае һәм Успение-Мәскәү урамнарын таштан киендерәләр, ә инде тагын 10 елдан калада таш түшәлгән 19 урам һәм 4 мәйдан пәйда була. Ә асфальтка килгәндә, ул Казан урамнарында бары тик 19 гасыр ахырында гына күренә башлый. Казаннан читтә асфальт юллар совет чорында – 1950 нче еллар уртасында гына салына башлый. Беренче асфальт Казан–Оренбург трассасына түшәлә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

Иллюстрация: Виталий Булатов. Казан. Рыбнорядская мәйданы (хәзерге Тукай мәйданы).

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр
ТӨП ТЕМА

8. Камиллеккә чикләр юк
Яхшы юлларны ничек бик яхшы итәргә

16. Казан–Мәскәү М-12 юлы
«Гасыр төзелеше» ничек бара

22. Вознесение тракты
Яңа магистраль кайдан узачак

24. Киң вәкаләтле дублёр
Горький шоссесын кайсы юл бушатачак

28. Вак таш үзебезнеке
Чыгымны арттырмыйча ничек күбрәк юллар төзергә

30. Башкала юллары
Шәһәрне ничек бөкеләрдән коткарырга

игелекле эшләр

52. Министр белән таныш
Леонид Мачтаков
Зәй ГРЭСын ничек төзегән

54. Тышкы разведка «Чибәркәе»
Сәмра Бикмиева ничек яшерен мәгълүмат тапкан

56. Ат көчен кулланып
Ришат Хәлиуллин кайда юлсызлык белән көрәшкән

60. Аудитория – «Бөтен Россия»
Безнең басма Сочины нәрсә белән әсир итте

66. Фән дөньясы
Сүзлекләр кайда туа

мәңгелек кыйммәтләр

72. Икенче Җәмигъ, Апанай мәчете
Аны кайчан байлар мәчете дип атаганнар

74. Әбидә кунакта
Кайда татар изүе тегәргә өйрәтәләр

76. Китап киштәсе
Ринат Мөхәммәдиевта кунакта

78. «Озын-озак балачак»ка сәяхәт
Кариев театрында нинди яңа тамашалар куела

80. Татар авыллары
Каргалы Карга

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

28.09

Максим РЕШЕТНИКОВ, РФ икътисадый үсеш министры, – РФ Дәүләт Думасындагы Хөкүмәт сәгатендә:

– Тулаем алганда, икътисадның иң түбәнге ноктасы бу елның дүртенче кварталында үтеләчәк, дип көтәбез. 2022 ел нәтиҗәләре буенча тулаем эчке продукт 2,9% ка кимиячәк. Икенче яртыеллыкта уртача дәрәҗәдәге кимүдән соң, инвестицияләр күләме якынча 2% ка азаячак. Инфляция акрынаячак – 17,8% лы иң югары апрель күрсәткеченнән һәм бүгенге 13,9% тан соң, декабрьдә 12,4% ка кадәр төшәчәк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

6.09

Илья АВЕРБУХ, боз тамашалары режиссёры, продюсеры, хореографы, Солт-Лейк-Ситида узган Олимпия уеннарының көмеш призёры, – Казанда «XXI гасыр лидеры» конкурсында катнашучы яшьләргә мөрәҗәгать итеп:

– Нәкъ менә көндәшлек сине алга барырга мәҗбүр итә. Бу – чиксез марафон. Алдынгылыкны яулап алуга караганда, аны саклап калу күпкә авыррак. Син үз артыңнан килүчеләр өчен максат булып торасың. Эзгә басып, куып бару һәрвакыт җиңелрәк, ә лидер үз максатларын үзе формалаштыра. Бу зуррак үрләргә илткән җиңүләрнең берсе генә икәнен онытмыйча, һәрвакыт җиңәргә омтылырга кирәк.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

18.09

Андрей УСАЧЁВ, балалар язучысы, – Түбән Камада узган «Сүз көче» фестивалендә:

– Тормышка сөенергә кирәк. Укучыларыма җиткерергә тырышкан иң төп фикерем шул. Балалар – өлкәннәрне, алар исә балаларны рәнҗетмәскә тиеш. Мөмкинлекләргә карап, намус кушканча яшәргә тырышыйк. Без бик еш кына институтны, эш урынын дөрес сайламыйбыз, ә кайберәүләр хәтта хәләл җефетен сайлаганда да ялгыша. Бу дөньяны рәнҗетмәскә, уңайлы итеп яшәргә тырышырга кирәк.

Фото: Антон Новодережкин/ТАСС, Салават Камалетдинов/tatar-inform, Роман Пименов/«Петербургский дневник»

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр
мәңгелек кыйммәтләр /

ТӨП ТЕМА

Бу санда тәкъдим итәбез:

Яхшы юлларны **ничек** бик яхшы итәргә

Авыл юллары **кайчан** камиллеккә ирешәчәк

Чыгымны арттырмыйча **ничек** күбрәк юллар төзергә

Шәһәрне **ничек** бөкеләрдән коткарырга

ЯҢА ЮЛЛАР: ТИГЕЗ, ЧЫДАМ ҺӘМ ТИЗ



Фото: Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар министрлыгының матбугат хезмәте

Яңа юллар картасы, мөгаен, соңгы вакытта карыйсы, өйрәнәсе килгән иң күңелле карталарның берседер. Иске юллар белән яңа үрләр яулап булмый.

Төзелеп килә торган Казан–Мәскәү зур тизлекле магистрале, аның Екатеринбургка кадәрге дәвамы, бүген республика территориясендә гамәлгә ашырыла торган башка киң колачлы һәм бигүк юлга карамаган яңа төзелешләр чыннан да татарстанлылар өчен офыкларны киңәйтә.

Эш монда заманча юлларның бөтенләй башка тизлек, уңайлылык тудыруында гына да түгел. Кайсы гына заманны алсак та, юлларның торышы икътисадның үсеш дәрәҗәсен билгеләвен, үсеш катализаторы булуын, инвестицияләрне, икътисадның алгарышын тәэмин итүен күрәбез. «Татарстан» журналы үзенең октябрь санында укучыларына бүгенге көндә юл төзүчеләр тарафыннан тормышка ашырыла торган төп проектлар, алар китерәчәк файда, перспективалар турында сөйләргә булды.

Фәрит Хәнифов: «Юлның сыйфаты турында сөйләгәндә, камиллеккә чик юк»

Ольга Туманская

Рәсми статистика мәгълүматларына нигезләнеп, «Рейтинг» РМА юл сыйфаты буенча Россия төбәкләренең рейтингын төзегән. Андагы 85 катнашучы арасында Татарстан 18 нче урынны били. Нәтиҗә мондый – бездә юллар яхшы. Аларны ничек тагын да яхшырак итәргә соң? Без бу турыда Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Мөдәррис улы Хәнифов белән сөйләштек.

– Фәрит Мөдәррисович, соңгы елларда Татарстандагы юлларның сыйфаты үзгәрдеме?

– Татарстанда «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли проекты гамәлгә кертелә башлаган 2019 елда республикабызның күрсәткечләре мондый иде: агломерацияләрдә юлларның – 80%ы, төбәкләрдә 46%ы нормага туры килә. Бүген, өч елдан соң исә, агломерацияләребездәге юлларның – 83,19%ы, төбәкләрдә 50,3%ы норматив күрсәткечләренә җавап бирә. Проектның беренче этабын 2024 елда төгәлләү планлаштырыла. Һәм менә шул урында кечкенә генә, әмма бик мөһим төгәллек кертү сорала. Бу программа кысаларында төбәкләрдә төзәтелгән юлларның күбесе бүген кабат ремонтлауга мохтаҗ. Сәбәбе гади: элеге челтәрнең 500 километрдан артыграк өлеше зур федераль трассалар төзелешендә файдаланыла. Төбәкләрдәге юлларга бик зур авырлык төшә – материалларны һавадан гына китереп

Фото: Александр Ефремов

булмый бит. Шуңа күрә кичә генә нормада саналган юл бүген инде кабат төзәтелүгә мохтаҗ булып чыга. Бәхеткә, проблеманы хәл итү мөмкин – милли проектның федераль заказчысы безнең мәнфәгатьләрне кайгырта, РФ Хөкүмәте әлеге максатларга акча бүлеп бирергә җыена. Һәм инде, әлбәттә, безнең эксплуатацияләү предприятиеләре һәм дәүләт юл системалары да бу мәсьәлә белән актив шөгыльләнә.

– «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли программасы республикада шактый зур юл проектларын гамәлгә кертү мөмкинлеген бирде. Алар киләчәктә безнең өчен нинди мөмкинлекләр ачачак?

– Зур Казан боҗрасы безнең өчен аларны ача да инде! Асылда, бу Казан районнарын үзара бәйли торган туктаусыз хәрәкәттәге боҗралы магистраль. Күптән түгел генә без Мехчылар урамындагы өлешне төзеп бетердек. Алда зур, ахыргы дип әйтерлек участок – Казан Кремле яныннан үтеп, Ленин дамбасына төшү юлын төзү тора. Юлның Несмелов урамыннан «Серебряный бор» ТК кадәрге өлеше дә быел файдалануга тапшырылачак. Анда яхшы трафик булыр, дип планлаштырабыз, шунлыктан барлык куркынычсызлык нормалары сакланган (моңа каршы агымнарны аеру һәм яхшылап яктырту да керә) дүрт полосалы юл салабыз.

М-12 трассасының безнең аша үтә торган Мәскәү–Казан өлеше дә зур мөмкинлекләр ачачак. Бу иң югары категорияле юл булачак. Ул түләүле, шуның белән бергә зур тизлекле һәм бик уңайлы да булыр, дип өметләнәбез. Анда бернинди юл киселешләре планлаштырылмый, зур транспорт чишелешләре уртача һәр 50 километрга бер генә очраячак. Трассада тракторлар һәм терлек көтүләре өчен махсус кичү урыннары, кыргый хайваннар өчен экодуклар төзеләчәк. Ягъни бернинди көтелмәгән хәлгә дә очраудан курыкмыйча, зур тизлектә бару мөмкин булачак. Мәскәүдән Казанга нибары 6,5 сәгатьтә барып җитү безнең чынбарлыкка әйләнәчәк! М-12 трассасының Мәскәү–Казан юлы Екатеринбургка кадәр озайтылып, безнең төбәкне Урал белән тоташтырачак.

Шунысын да искәртү кирәктер: М-12 автомобиль юлын төзегәндә файдаланылган төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларының саклanышын тәэмин итү өчен ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Автодор», «Росавтодор» ДК белән берлектә, Меморандум кабул итүне планлаштыра.

– Өр-яңадан башлап заманча магистраль төзү – бер эш булса, инде «үлем юлы» дип яманаты чыкканын рәтләү – бөтенләй икенче. Шундый «әверелү»гә мисал китерә аласызмы?

– Мөгаен, бу М-7 трассасының Казан–Яр Чаллы өлешедер. Аның кайчандыр бик катлаулы булуын аңлар өчен, юл ремонтланган вакытта барлык машиналар агымы бер яктан бара торган шимбә яки якшәмбе көннәренә эләгү дә җитә. Әлеге юлга элек без ничек сыйганбыздыр. Бүген исә ул бик төзек трассага әйләнде, уңайлылык һәм куркынычсызлык буенча барлык нормаларга җавап бирә. Алай гына да түгел әле: федераль коллегаларыбыз анда хәзерге бер катлы җәяүлеләр кичүләре урынына егермедән артык яңа җир өсте кичүе төзүне планлаштыра. Шул рәвешле бу юл тагын да куркынычсызракка һәм уңайлыга әйләнәчәк. Әгәр юлында Түбән Кама ГЭСы плотинасы тормаса һәм юлның шактый зур өлеше Яр Чаллы шәһәре аша үтмәсә, бу трассаны идеал дип атап булыр иде.

– ЗУР КАЗАН БОҖРАСЫ – АСЫЛДА, ШӘҺӘР РАЙОННАРЫН ҮЗАРА БӘЙЛИ ТОРГАН ТУКТАУСЫЗ ХӘРӘКӘТТӘГЕ БОҖРАЛЫ МАГИСТРАЛЬ. Күптән түгел генә без Мехчылар урамындагы өлешне төзеп бетердек. Алда зур, ахыргы дип әйтерлек участок – Казан Кремле яныннан үтеп, Ленин дамбасына төшү юлын төзү тора.

ЮЛЛАР, ЮЛЛАР...

– Республикабыздагы зур федераль һәм төбәк трассаларын салу колачы таң калдыра, ә район үзәкләрендәге юллар ни хәлдә?

– Россия Федерациясенең терәк юллары челтәре дигән төшенчә бар. Аңа федераль һәм республика юллары керә. Әмма безнең Татарстан Республикасында да терәк юллар челтәрен булдырасыбыз килә, анда һәр район үзәген үзенең күршеләре белән яхшы юл тоташтырсын иде. Болар барысы да безнең планга кертелгән, әмма бу эшне кыска вакыт эчендә генә башкарып чыгып булмый. Шулай да ул инде башланды. Республикабызда терәк юллар челтәрен булдыру тәртибе бүген Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек, Сәнәгать һәм сәүдә, Икътисад министрлыклары белән бергә тикшерелә. Һәм бу чыннан да республикада җөйсез транспорт логистикасы оештыру өчен җаваплы бик мөһим мәсьәлә. Ул киләчәктә безнең юлларның артык каты таушалмавын һәм ел әйләнәсе көйле эшләвен тәэмин итәчәк. Бүген исә без төбәк юлларын кар эрегән чорда ябарга мәҗбүр – алайса алар ватылып бетәчәк бит. Язгы чорда бары тик федераль трассалар гына ачык. Әйе, алар төбәк юлларындагы кимчелекләрдән азат, чөнки юл кучәренә 11,5 тонна һәм хәтта артыграк та авырлыкка түзәрлек итеп төзелгән.

– Авыл юлларына карата да шундый планнар бармы соң?

– Ихтимал, бу иң кызыклы сораудыр. Авыл юллары республика терәк юллары

челтәренә кермәячәк. Шуңа да карамастан, алар, кан тамырлары кебек, Татарстанның бөтен территориясе аша үтә. Аларның гомуми озынлыгы 40 мең километрдан арта. Мин төп кагыйдәне үтәргә тиешбездер, дип саныйм: төрле рангтагы юллар бөтенләй башка төрле вазыйфа башкарырга тәгаенләнә бит, һәм бу җәһәттән авылныкылар, төбәк һәм бигрәк тә инде федераль трассаларга караганда, күпкә азрак функционалга ия. Без алар өчен нәтиҗәле чишелеш эзлибез. Чөнки, әгәр бөтен авыл юлларын федераль юл дәрәҗәсенә җиткерергә карар кылабыз икән, – моңа илнең дә, хәтта җиһанның да акчасы җитмәячәк! Әлегә без болай хәл иттек: төбәк терәк юллар челтәре хисабына район үзәкләре арасында җөйсез логистиканы тәэмин итәбез. Ә авыл юлларын җимермәс өчен, зур машиналар йөкләрен кечерәк машиналарга бүлеп ташырга тиеш. Авыл юлларына таләпләр исә югары түгел – алар тигез булса җитә.

– **БҮГЕН КАЗАН–ЯР ЧАЛЛЫ** юлы төзек трассага әйләнде, уңайлылык һәм куркынычсызлык буенча барлык нормаларга җавап бирә. Алай гына да түгел әле: федераль коллегаларыбыз анда хәзерге бер катлы җәяүлеләр кичүләре урынына егермедән артык яңа җир өсте кичүе төзүне планлаштыра.

– Юлларны ремонтлау чираты нинди принцип буенча билгеләнәчәк? Кайсы авылга яңа юл салу кирәклеген, кайсылары исә һаман таш түшәлмәгән юл белән калачагын кем хәл итәчәк?

– Без район башлыклары белән өстенлекле юллар таблицасын төзедек. Ягъни республикадагы барлык юлларны төзү һәм ремонтлауның «тере чиратын» булдырдык – кайсыларын беренче чиратта торгызу зарур, кайсыларын – иң ахырдан. Әлеге мәсьәләгә мөмкин кадәр объектив якын килергә тырыштык – торак пунктларда яшәүче халык санын исәпләдек, хәрәкәт интенсивлыгын, ягъни трафикны, ачыкладык... «Активрак» юллар өстенлеккә ия – без аларны беренче чиратта ремонтлаячакбыз.

– Өстенлекле юлларны ремонтлау гадирәк юлларны торгызудан конструктив чишелешләре буенча да аерылачакмы?

– Әлбәттә. Юлның километрын 70 миллион сумга да, 7 миллион сумга да ремонтлап була. Әмма бөтен җирдә дә бер үк дәрәҗәдәге бик яхшы юллар салырга омтылырга кирәкми. Авыл юлларының кайберләрендә артык кыйбатлы булмаган материаллар куллану да үзен аклый. Менә сез искә төшергән таш түшәлмәгән арба юллары да бар бит әле! Бүген безнең министрлык ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм «Автодор» компаниясе белән таш түшәлмәгән юлларны нәкъ менә каты өслекле юлларга әйләндерү хакында сөйләшүләр алып бара. Һәм моның иң арзанлы конструктив чишелеш булуы да куркыныч түгел: безнең өчен иң мөһиме – кеше үз машинасында иң ерак торак пунктка кадәр дә тигез юлдан хәвеф-хәтәрсез барып җитәрлек булсын.

– Мондый карар кабул итәргә республиканы нәрсә этәрде?

– Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, пандемия. 2020 елда барыбызны да үзизоляциягә җибәргәч, әлеге куркыныч чирдән эби-бабайларының йортында качып калуга өметләнеп, күпләр кече ватаннарын эзләп китте. Әмма иске торак пунктларны бөтенләй ташламас өчен тагын бер сәбәп бар. Алар искиткеч уңайлы урыннарда урнашкан бит! Безнең бабаларыбыз ничек шулай барысын да төгәл исәпләп чыгара алгандыр. Әлеге ташландык диярлек авылларда базларга да су төшми, төньяк җилләре дә зыян китерерлек итеп исми. Өстәвенә, аларның күбесенә электр кертелгән, скважиналар казылган инде... Бары юл саласы гына калган! Без менә шул урыннарны саклап калырга тиеш.

КӨТЕЛМӘГӘН НӘТИҖӘ

– «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли проекты кысаларында планлаштырылган бөтен нәрсә файдалануга тапшырылгач, Татарстан тагын нишләячәк? Инде бүген үкниндидер озак вакытка исәпләнгән планнар бармы?

– Әлбәттә, һәм аларның күбесе авыл юлларын төзүгә кагыла. «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы республикабызда тормышка ашырылырга уйламый да әле. Авыл халкының мобильлеген арттырып, районнарда җитештерүне үстерүгә булышып, бик мөһим социаль нәтиҗәгә китергәнгә, аны озайттылар... Без, юл төзүчеләр исә, әлеге программа тагын бер көтелмәгән нәтиҗәгә китерер дип өметләнәбез: ул төзелеш техникасы җитештерү тармагында импортны алыштыруга булышачак. Бүген без барыбыз да «Башкаларга ышан, тик үзең дә кымшан» әйтемен истә тотып эшләргә тырышабыз. Татарстан – юл-төзелеш техникасы җитештерүне үзенә туплаган төбәк. Без КАМАЗлар, грейдерлар, бульдозерлар, төягечләр җитештерәбез. Әмма нечкәлекләре дә бар: әлеге техника безнең илдә эшләнгән саналса да, суверен түгел. Мәсәлән, машинаның

алгы һәм арткы күчәрләре – Италиядән, двигателе исә – Англиядән, башка өлешләре тагын башка илдән кайтартылган булып чыга... Якындагы планда – суверен техника җыюга керешү. Баштарак мәлдә ул сыйфаты һәм бәясе ягыннан чит илдә эшләнгәннән кайтышрак һәм кыйбатрак булыр. Чөнки шул ук Италия җитештерүчеләре елына миллионнарча данә күчәр чыгара, безнең предприятиеләрнең күләме исә башта меңләп кенә исәпләнәчәк. Бурыч әле тагын шуның белән дә катлаулана: безгә суверен техника гына җыясы түгел, моны әле 3D-җиһазлар белән комплектациядә дә эшлисе була. Сезнең, мөгаен, бүген юл кырыйларының ничек ясалуын күргәнегез бардыр: пульт артында оператор утыра һәм команда бирә. Компьютерның болыт сервисыннан сигнал идарә пультына килеп керә, һәм машина кирәкле эшне миллиметрга кадәр төгәллек белән башкарып та куя. Бәхеткә, АлАЗда инде 3D-җиһаз куелган беренче грейдер җыелып ята. Һәм без Алабуга заводы белгечләре үзләренә йөкләнгән бурычны лаеклы башкарып чыгар, дип өметләнәбез.

– Суверен техникага күчү безнең юлларның сыйфатында чагылырмы соң?

– Әгәр без аны чит ил машиналары белән беррәттән шундук юл төзелешенә чыгарсак, ярык тагарак янында калуыбыз бар – яңа машиналарның конструктив кимчелекләре үз эшен эшләячәк. Һәм менә нәкъ шул урында авыл юлларын ремонтлау программасы ярдәмгә килергә мөмкин – илебездә җыелган яңа техниканы сынау өчен чын «клондайк» менә кайда яшерелгән ул! Авыл юлларын салу һәм ремонтлауда яңа машиналарны рәхәтләнеп сынарга була. Чөнки биредә хата ясалса да, ул төбәк трассалар һәм бигрәк тә федераль магистральләр төзелешендәге кебек зур чыгымнарга китермәячәк. Авыл юллары программасы буенча ике-өч ел эшләгәннән һәм камилләштерелгәннән соң, безнең техника да ул вакытка инде искергән һәм тузган чит илнекен лаеклы алыштырыр, дип өметләнәбез.

– Материаллар һәм технологияләр җәһәтеннән дә шундый яңарту планнары бармы? Бүген юлларның сыйфатын ничек яхшыртып була?

– Юлның сыйфаты турында сөйләгәндә, камиллеккә чик юк. Шулай булса да, без асфальт-бетон катнашмаларның сыйфатын яхшыртуга ирештек – аларны әзерләүдә инновацияле полимер тоташтыргычлар куллана башладык. Аларның бердәнбер җитешсезлеге – мондый җитештерүнең бәясе кайчагында сыйфатка бәйсез рәвештә үсә. Казанның үзәгендә нинди генә асфальт салсаң да, ике елдан соң барыбер таушалган катламны алыштырырга кирәк булуын белгәч, ихтыярсыздан уйлана башлыйсың: бәлки мондый бик кыйбатлы заманча технологияләр артыннан куарга да кирәкмидер?



Шул ук вакытта безнең бик күп йөк ташыла торган сәнәгать юлларында цемент-бетон материаллардан файдалану тәҗрибәбез дә көчле. Бетон юл инде Яр Чаллы һәм Түбән Кама кебек «гасыр төзелешләрендә» үзенең нәтиҗәлелеген күптән исбатлады. Башка нинди юл шулкадәр авырлыкка чыдар иде икән? Аларны соңыннан гына асфальтка алыштырдылар. Бүген без асфальт-бетон юллар темасын бик яхшы үзләштердек – безнең бөтен техника шуңа көйләнгән, аны исә бер генә көндә алыштырырлык түгел. Җитмәсә, асфальт юлларның үз өстенлеге бар – алар йомшак. Цемент-бетон юллар исә бик каты һәм төзелештә киткән хаталарны кичерми. Начар юл салсаң, автомобильчеләр һәр ялганган-тоташкан урынны «санап» барачак. Күптән түгел тәҗрибә уртаклашырга Белоруссиягә бардык – анда юллар сокландыргыч сыйфатлы. Шунысы гаҗәп: аларның күпчелеге Олимпиада-80 гә дип төзелгән булган! Татарстанда авыр йөкләр күп ташыла торган урыннар бар. Анда асфальт салсаң, ике елдан соң юкка чыгачак. Безгә дә менә шундый мәңгелек цемент-бетон юллар төзисе иде! Болар барысы да безнең планнарыбызда бар.



ӘЙЛӘНЕЧТӘН ЮЛ ТУРЫ

Ихтимал, яхшы юлларны алардан тормыш үзе ага торган артерияләр белән чагыштырып буладыр. Бигрәк тә алар ерак районнарны үзара тоташтырган һәм аларның үзәк белән элемтәсен тәэмин иткән очракта. Республикада әлеге юллар тармагында бүген ниләр эшләнүе хакында безгә «Главтатдортранс» ДКУ директоры Эдуард Данилов сөйләде.

– Сезнеңчә, бүген Татарстан юлларының транспорт-эксплуатация халәте нинди? Безнең юллар кайчан нормага туры килә башлаячак?

– Республикада яшәүчеләр соңгы вакытта юлларның сыйфаты шактый яхшыруын билгеләп үтә. Мин болай уйлыйм: зур эш эшләнде, әмма алда тагын да күбрәк эш тора әле. Безнең оператив идарәдәге Татарстан юлларының гомуми озынлыгы якынча 13,5 мең километр тәшкил итә. Бу – торак пунктларны район үзәкләре, аерым торак пунктлар, шулай ук шәһәрара трассалар яки, мәсәлән, «Волга» М-7 кебек федераль магистральләр белән тоташтыра торган төбәк әһәмиятендәге юллар.

Юл эшләре программасы кысаларында 2022 елда аларны төзү һәм ремонтлауга 60 миллиард сумнан артыграк акча бүленде. Һәм бу былтыргыдагыдан 10 процентка артыграк. Барлыгы 52,5 километр юл төзү, 610,3 километрын ремонтлау планлаштырыла. Бүген төзелеш һәм реконструкция эшләре автоюлларның 30 участогында бара. 73 участок ремонтлана.

Аеруча әһәмиятле реконструкция объектлары арасында Казанның Киров районындагы Осиновская урамын аерып әйтә алам, аның хисабына без зур Салават Күпере микрорайонының, шулай ук Горький шоссесының транспорт сыйдырышлылыгын арттырачакбыз. Болотников, Фрунзе, Горький шоссесы, Залесная урамнарында, Музыкальная урамыннан федераль әһәмияттәге «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участокта алты полосалы хәрәкәт оештыру ниятләнә. Реконструкция шулай ук юлның Техническая урамыннан Киров дамбасына кадәр өлешенә (бу Зур Казан бәжрасын үстерү кысаларында үтәчәк) һәм Мехчылар урамының Магистраль урамыннан Девятаев урамына кадәр участогына да кагылачак. Болары башкала урамнарына килгәндә. Яр Чаллыда исә күптәннән Гостев урамындагы автомобиль юлын (Аэродром урамыннан Батенчук урамына кадәр өлешен) реконструкцияләү көтелә.

– Сезнең ихтыярдан гына торса, кайсы юлны бүген үк сала башлар идегез?

– Беренчесе – безгә әйләнеп узу юлларын төзү кирәк. Иң зур торак пунктларны гына урап үтәрлек булса да. Бу чыннан да бүген үк зарур булган нәрсә. Икенчесе – безгә Татарстанны күрше субъектлар белән тоташтыра торган юллар күбрәк кирәк. Һәм өченчесе – республиканың төрле районнарын берләштерә торган юллар челтәрен булдыру мөһим. Бу әчке логистиканы шактый яхшыртачак. Хәзер безнең хәрәкәт барлык юллар район үзәкләренә һәм башкалага алып бара торган итеп планлаштырылган, ә районара элемтәләр җитешми. Якын арада әлеге проблеманы ничек тә хәл итәсе иде.

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

– Татарстанда күпләр «үлем юлы» дип атаган Казан–Яр Чаллы трассасын уңайлы итеп ясауга мисал бар инде. Сезнең профессиональ күзлектән караганда, мондый «әверелү»нең критерийлары нинди? Мондый юлларны уңайлылык һәм иминлекнең бөтен таләпләренә җавап бирә торганга ничек әйләндерергә?

– Питрәч районындагы Казан–Шәмәрдән автоюлын реконструкцияләү моңа яхшы мисал булып тора. Бу – «Волга» М-7 трассасыннан Питрәч ягына таба – «Царево» ТК кадәр участок. Хәрәкәт интенсивлыгы буенча әлеге юлны беренче техник категориягә кертеп була. Реконструкциягә кадәр аның Яңа Шигали авылына кадәр өлеше кирәкле таләпләргә җавап бирми иде. Шунлыктан юл һәлакәтләре дә еш булды. Без бу юлны бөтен нормаларга туры килерлек итеп үзгәрттек: каршы агымнарны аердык, борылу бокҗралары төзедек, хәрәкәт тизлегенә йогынты ясый торган радиусларны үзгәрттек. Куркынычсыз җир өсте кичүләре төзедек, тавыш йота торган экраннар куйдык һәм яктыртуны көчәйттек. Хәзер әлеге юнәлештәге юл имин һәм бик уңайлы трассага әйләнде, анда аварияләр дә, бөкеләр дә юк.

Әмма, кызганыч ки, Казан-Шәмәрдән генә төбәк әһәмиятендәге бердәнбер куркыныч юл түгел иде шул. 2021 елда республикада булган юл-транспорт һәлакәтләрен анализлап, гомумкулланыштагы автомобиль юлларында 167 куркыныч участок ачыкланды. Юл хәрәкәтенең куркынычсызлыгын көчәйтүгә булышачак чаралар уйлап табылды. Бу – тротуарлар төзү, урамнарны яктырту, аеру полосасында металл коймалар һәм юллар кушылган урында ясалма тигезсезлекләр кую...Бүгенге көнгә без барлык планлаштырылган эшләрнең 85 процентын үтәдек, утыз районда исә алар тулысынча башкарылды.

– «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли проекты буенча республикада берьюлы берничә зур юл салына. Ә авыл юллары белән эш ничегрәк тора?

– Әлеге проект гамәлгә кертелә генә башлаган 2017 елда безнең юлларның норматив таләпләргә тәңгәллеге күрсәткече түбән иде. Әгәр, мәсәлән, шактый уңышлы Казан агломерациясен алсак та, ул 67 проценттан артмады. Нәтиҗәдә шул вакыттан бирле республикада барлыгы 852 километр юл ремонтланды. Быел финанслауның тулаем суммасы 9 787, 68 миллион сум тәшкил итте. Чагыштыру өчен: шул ук Казан агломерациясендә 2022 ел азагына юлларның инде 84,6 проценты норматив таләпләренә җавап бирәчәк. Яр Чаллы агломерациясендә әлеге күрсәткеч 82 процент тәшкил итәчәк.

Ә менә Татарстандагы төбәк әһәмиятендәге юлларда ул, әлбәттә, түбәнрәк: быел, 31 километр юлны ремонтлап бетергәч, бу юлларның 50 проценттан артыгы нормативларга тәңгәл килер, дип планлаштырабыз. Без барлыгы 16 объектны ремонтларга ниятлибез, алар арасында, мәсәлән, Яр Чаллы–Зәй–Әлмәт автоюлы һәм Буа–Тәтеш юлы да бар. Һәм монда безнең беренче чираттагы бурычыбыз – республиканың бөтен терәк челтәрен, ягъни башкаланы район үзәкләре белән һәм район үзәкләрен бер-берсе белән тоташтыра торган юлларны нормага китерү. Һәм без әкренләп моны гамәлгә ашырабыз.

Моннан тыш, Татарстан ел саен торак пунктлардагы урам юллары челтәренең халәтен яхшыртуга шактый акча бүлә. Бүген гомуми озынлыгы 150 километр булган 380 объектта эш бара. Шуңа охшаш тагын ике программа гамәлдә, шулар кысаларында без быел тагын гомуми озынлыгы 120 һәм 312 километр булган авыл юлларын ремонтларга тиеш. Күрүегезчә, республикада авыл халкына аеруча игътибар һәм кайгырту күрсәтелә.

> БЕЗНЕҢ ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ БАРЛЫК ЮЛЛАР РАЙОН ҮЗӘГЕНӘ ҺӘМ БАШКАЛАГА АЛЫП БАРА ТОРГАН ИТЕП ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН. **РАЙОНАРА ЭЛЕМТӘЛӘР ҖИТЕШМИ.**

– Татарстан юл төзүчеләре үз эшләрендә яңа технологияләр һәм материаллар куллануда никадәр алга киткән?

– Бик ерак! Милли проект кысаларында төзелгән барлык контрактлар да яңа технологияләр һәм материаллар куллануга нигезләнгән килешүләр ул. Кагыйдә буларак, яңа илкүләм стандартларга ярашлы итеп эшләнгән асфальт-бетон катламы турында сүз бара. Моннан тыш, без сыйфатлы җирле минераль материаллар һәм композит эшләнмәләрдән, заманча гидроизоляция һәм саклау системаларыннан мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга тырышабыз. Алай гына да түгел, Идарә ел саен яңа материаллар һәм технологияләр кертү планын гамәлгә ашыра. Былтыр өр-яңа эшләнмәләр 14 объектта кулланылса, быел мондый объектлар саны 23 кә җитте.

Күрүегезчә, үзебезнең һөнәри бәйрәмебезне без лаеклы каршы алабыз. Шунлыктан миңа хезмәттәшләремне Юл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне белән котлау бигрәк тә рәхәт. Алдыгызга куелган максатларга ирешүдә уңышлар телим, һәм халык сезгә намуслы хезмәтегез өчен рәхмәт сүзләре генә әйтсен. Барыгызга да нык сәламәтлек, бәхет, муллык телим!

ЯҢА ЮЛЛАР КАРТАСЫ





1

Осиновская урамындагы автоюлны реконструкцияләү. Озынлыгы – 1,4 км. Осиново бистәсен Горький шоссесы белән тоташтыра торган әлеге юл дүрт полосалы булачак. Реконструкция алып барыла.

2

Горький шоссесына дублер юл. Озынлыгы – 13 км. Ничек уза: беренче этап – Несмелов урамыннан Барлык диннәр гыйбадәтханәсенә кадәрге юл (төгәлләнә). Төзелешнең икенче этабында юл М-7 трассасы белән тоташачак.

3

Горький шоссесын реконструкцияләү һәм киңәйтү. Озынлыгы – 11,5 км. Ничек уза: Кызыл Кокшай урамыннан М-7 трассасына кадәр. Әлеге участок светофорлар куелмаган алты полосалы магистральгә әйләнәчәк. Реконструкция алып барыла.

4

Зур Казан боҗрасы. Озынлыгы – 34 км. Туктаусыз хәрәкәтнең боҗралы магистрале шәһәрнең Яңа Савин, Мәскәү, Киров, Вахитов, Идел буе, Совет районнары аша узачак. 2022 елда Магистраль урамыннан Девятаев урамына кадәр булган 1,7 км озынлыктагы дүрт полосалы юлны реконструкциялиләр.

5

Вознесение тракты. Озынлыгы – 12 км. Беренче этап – Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге 4 км лы юл өчәр полосалы ике хәрәкәт итү өлешеннән тора (төзелеп беткән). Икенче этап төзелеше бара – Җиңү проспектыннан М-7 трассасына кадәр сузылган 8 км лы юл. Ул шулай ук ике як буенча хәрәкәт итү өчен ясалган өчәр полосадан тора.

6

«Казан» аэропортына керү юлын реконструкцияләү. Яңартыла торган участокның озынлыгы – 5 км дан артык. Р-239 юлының Кече Кабан авылыннан ерак түгел ясалган ике катлы автомобиль чишелешеннән аэропорт территориясенә кадәрге участогы. Проектны 2013 елда тәмамлау көз уңында тотыла.

7

Сокуры авылын урап узу юлы. Көздә тотылган озынлыгы–23 км. Дүрт полосалы урау юл Олы Кабан авыл җирлегеннән Державиного кадәр сузылачак. Проектны эшләү башланган.

8

Мәскәү–Казан М-12: 7 нче һәм 8 нче этаплар. Озынлыгы – 142 км га якын.

9

«Волга» М-7 автомобиль юлының 757 нче километрында Зөя елгасы аша күпер кичүен реконструкцияләү. 392 м дан артык озынлыктагы яңа күперне төзү тәмамланган. Гамәлдәге 389 м озынлыктагысын яңарту алып барыла. Кулланышка тапшыру вакыты – 2023 ел.

10

Шәле–Баулы. Озынлыгы – 299 км. Юл «Волга» М-7 трассасын «Урал» М-5 белән тоташтырачак. 145 км лы Аллексеевск – Әлмәт участогы Татарстанда беренче түләүле трасса булачак. Эшләр бара. Кулланышка тапшыру вакыты – 2024 ел.

ЮГАРЫ ТИЗЛЕКЛЕ М-12 ТРАССАСЫ.

МӘСКӘҮ–ТҮБӘН НОВГОРОД–КАЗАН

М-12 НЕҢ ТАТАРСТАН УЧАСТОГЫ



142 км

ТРның Кайбыч районында Чувашия чигеннән башланып Питрәч районында Шәле–Саескан Тавы трассасы белән кисешкәнгә кадәрге юл озынлыгы.

3360 м

Идел елгасы аша күпер озынлыгы. М-12 магистралендә иң озыны. Елганың төзелеш урынындагы максималь тирәнлеге – 19 метр.

50 дән артык

ясалма корылма, гомумән алганда 350 ләп корылма төзелергә тиеш.

шулай ук

Зөя, Мишә аша яңа күперләр салыначак.

729 км
юлның озынлыгы

Сәгатенә **120** км
күздә тотылган тизлек

4 хәрәкәт полосасы

6,5 сәгатьлек юл
Мәскәүдән Казанга кадәр

1Б
юл категориясе

Йөргән өчен түләүнең **барьерсыз системасы**

2,4 трлн сум
проектны гамәлгә ашырудан алыначак гомуми макроикътисадый нәтиҗәлелек



ПЕРСПЕКТИВАДА НӘКЪ МЕНӘ ТАТАРСТАН «ЕВРОПА–КӨНБАТЫШ КЫТАЙ» ХАЛЫКАРА ТРАНСПОРТ КОРИДОРЫНЫҢ ҮЗӘК НОКТАСЫ БУЛАЧАК. Әлеге маршрутта кластер тармакларында җитештерелә торган төп продуктлар портфеле тупланачак: Россия автомобиль сәнәгатенең 70%ы, аэрокосмик һәм оборона сәнәгатенең 50%ы, металлургиянең 40%ы, машина төзелеше һәм прибор төзелешенең 30%ы, нефть эшкәртү, химия, нефть химиясе һәм газ химиясенең, минераль ашламалар җитештерүнең 25%ы. М-12 трассасы яңа эш урыннары ачачак, территория үсешенә этәргеч бирәчәк, йөк ташуларны файдалырак, тизрәк һәм куркынычсызрак итәчәк, төбәктә технологияләр үсешенә һәм сәнәгатьне үстерүгә яңа импульс өстәячәк.

һәр **50–60** км саен

ягулык салу станциясе, автосервис, мини-отель һәм тамак ялгап алу урыннары ачылачак.

6 транспорт чишелеше

төзеләчәк, гомумән М-12 трассасында 16 транспорт чишелеше пәйда булачак. Монда башка юллар белән бернинди дә кисешүләр булмаячак, бу берничә катлы юл чишелешләре төзеп хәл ителәчәк, җәяүлеләр өчен кичүләр бары тик җир өстеннән яисә җир астыннан гына булачак.

146 млрд сум

якын киләчәктә яңа трассадан республика алган файда шулкадәр дип бәяләнә.

М–12 ТРАССАСЫ.
МӘСКӘҮ–ТҮБӘН НОВГОРОД–КАЗАН.
ЭКОЛОГИК АСПЕКТ

12 экодук

төзеләчәк.

Иң күбе -

7 экодук –

Татарстан территориясендә.

ЭКОДУКЛАР – ТРАССА ӨСТЕННӘН САЛЫНГАН КҮПЕР КОРЫЛМАЛАРЫ, АЛАР ЭРЕ ҺӘМ ВАК ХАЙВАННАР ӨЧЕН ТАБИГЫЙ СУКМАККА ӘЙЛӘНЕРГӘ ТИЕШ. Экодуклар җирлекнең табигый ландшафтына максималь рәвештә яраклаштырып, сизелмәслек итеп ясала. Юлны мөмкин кадәр күбрәк хайван куркынычсыз чыга алсын өчен, аларга килү юлы, кагыйдә буларак, бик киң итеп эшләнә. Машина тавышы урманда яшәүче киек-җанварларны куркытмасын өчен, экодукларга тавыш йоту экраннары урнаштырыла. Европада экодуклар бик күп кулланыла, ә Россиядә алар моңа кадәр юк дәрәҗәсендә иде.



Терлек һәм кыргый хайваннар өчен **22** юл чыгу урыны

Алар трасса өстеннән үтәчәк. Татарстанда шундый дүрт урын булачак.
Экодуклар һәм чыгу урыннарын кыргый хайваннарның миграция сукмагы статистикасына һәм йорт хайваннарын куу маршрутлары турындагы мәгълүматка таянып сайлыйлар. Мондый ысул кыргый хайваннар популяциясен һәм трасса узачак төбәкләрдәге тормыш рәвешен сакларга мөмкинлек бирәчәк.

160 гектар урман

Татарстанда М-12 трассасын төзегән вакытта барлыгы шулкадәр урман киселәчәк.

2,5 тапкырга күбрәк агач

Киселгәннәрне каплау максатында подрядчылар шулкадәр агач утыртачак.

4000000 үсенте

Татарстанда һәм Чувашиядә М-12 трассасын төзегәндә киселгән агачлар урынына утыртылган. Бу – нарат, чыршы, карагай, каен, имән һәм корычагач. Татарстанда, әлеге эшләрне башкарган «Автодор» дәүләт компаниясе мәгълүматларына караганда, миллионнан артык агач утыртылган. Республикада урман торгызу һәм урман үрчетү эшләре 263 гектар җирне биләгән 164 участокта башкарылган. Агачларны Бөгелмә, Кайбыч, Лаеш, Югары Ослан, Питрәч, Биектау районнарында, шулай ук Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнарына кергән территорияләрдә утыртканнар.

5 метр - тавыш йоту экраннарының күздә тотылган биеклеге.

Аларны М-12 трассасының торак пунктлар янәшәсеннән уза торган өлешләрендә урнаштырачаклар. Халыкны шау-шудан сакларга сәләтле иң яхшы техник ысулларны сайлап алу өчен Владимир өлкәсендә махсус полигон ачылган. Тавыш йоту экраннары Татарстанның Лаеш һәм Югары Ослан районнарына кергән торак пунктлар янында куелачак.

25 000 артык чөгә маймычы

Югары тизлекле магистральнең күперләрен һәм суүткәрү корылмаларын төзегәндә әйләнә-тирә мохиткә китерелүе ихтимал булган зыянны каплау максатында Татарстандагы Куйбышев сусаклагычына шулкадәр чөгә маймычы инде җибәрелгән. Аңа кадәр Түбән Новгород янында Идел суына 620 меңнән артык чөгә маймычы җибәрелгән иде. Бу су саклау законнары таләпләренә ярашлы итеп эшләнә.

М–12 ТРАССАСЫ.
ДӘВАМЫ. УРАЛГА ТАБА



Казан–Екатеринбург
маршруты

Татарстан, Башкортостан, Пермь крае һәм Свердловск өлкәсе аша узачак.

800 км
гомуми озынлыгы

425 км – яңа төзелеш

бер өлеше – гамәлдәге федераль юлларны реконструкцияләү

ЮЛ ВАКЫТЫ	Бүген	М-12 трассасы эшли башлагач
Казаннан Екатеринбургка кадәр	**14** сәгать	**7** сәгать
Санкт-Петербургтан Екатеринбургка кадәр	**30-35** сәгать	**17,5** сәгать

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН, РФ ХӨКҮМӘТЕ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ: «Быел без Казан–Екатеринбург юлын тулысынча ачарга тиеш. 2024 елда Санкт-Петербургтан Екатеринбургка кадәр барып җитү бурычын Президент куйды. Шуңа күрә 2024 елда без тулысынча кулланышка тапшырылган трассага ия булырга тиеш. Россия төзелеш тарихында безнең беркайчан да мондый трассаны салганыбыз булмады. Күреп торабыз: без моны эшли алабыз».



Татарстанда юл участоклары:

126 км — Питрәч районы Шәле авылы янынннан Алабуга районы Костеево авылы борылышына кадәр. Гамәлдәге «Волга» М-7 трассасы буйлап узачак.

Биредә **22** җәяүлеләр кичүе төзеләчәк.

81,4 км — Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы. «Волга» М-7 трассасының 987 нче чакрымыннан – Костенеево авылы янынннан башланачак. Сосновый Бор бистәсе янында тәмамланачак. Урау юлның бер өлеше – Кама елгасы аша салыначак күпер.

98 км — Яр Чаллыдан Башкортостан чигенә кадәрге юл. Ул Тукай, Минзәлә, Актаныш районнары буйлап узачак. Маршрут – гамәлдәге «Волга» М-7 трассасы. Аны дүрт полосага кадәр киңәйтеп, 1 нче категорияле юл дәрәҗәсенә җиткерәчәкләр.

Сәгатенә **120** км

күздә тотылган тизлек

5 млн тоннага кадәр

Казаннан Екатеринбургка йөк ташу күләме елына шулкадәргә артачак.

Төзеләчәк:

5 транспорт чишелеше

23 җәяүлеләр кичүе

Яңартылачак:

Минзәлә, Ык, Сөн елгалары аша күперләр.

һәм тагын **5** күпер

Финанслау

Акчалар

Милли иминлек фондыннан

бүленә

Алга таба ничек?

Трассаны Омск, Новосибирск һәм Чиләбегә кадәр сузу, Кытай һәм Монголия чикләренә кадәр җиткерү (әлеге мөмкинлек карала) күздә тотыла.

ВОЗНЕСЕНИЕ ТРАКТЫ. КАЗАННАН ЧЫГУЧЫ БИШЕНЧЕ МАГИСТРАЛЬ



Маршрут

Әмәт магистраленнән Бохара урамы аша, алга таба Минск һәм Зәкиев урамнары арасыннан «Волга» М-7 трассасына кадәр.

Максат

Вознесение тракты Азино, Горки, Салмач, Вознесение, Привольный кебек якын-тирәдә урнашкан торак микрорайоннардагы транспорт хәрәкәтен җайлый. Бу якларда торак төзелешен үстерергә мөмкинлек тудыра.

11,7 км

гомуми озынлыгы

4 км

Вознесение трактының беренче этабына кергән Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге беренче участокның озынлыгы

7,9 км

юлның икенче этабына кергән Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 трассасына кадәрге участокның озынлыгы

2,2-2,4 м

тротуарларның киңлеге

6 полосалы юл

һәр яктан – өчәр полоса

Сәгатенә 70 км

транспорт хәрәкәтенең күздә тотылган тизлеге

Вознесение трактының беренче чираты – КАЗАННАН ЧЫГУ МАГИСТРАЛЕНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ. Ул Әмәт магистраленнән башланачак һәм «Волга» М-7 федераль трассасында тәмамланачак.

ИЛСУР МЕТШИН, КАЗАН МЭРЫ: «Вознесение тракты – безнең күптәнге хыялыбыз. Бу юл Мамадыш трактындагы хәрәкәтне шактый җиңеләйтәчәк, ә киләчәктә Универсиада проспектыннан һәм гомумән шәһәр үзәгеннән М-7 федераль трассасы ягына тиз чыгуны тәэмин итәчәк».



2023 ел

төзелешнең беренче этабының тәмамлануы

Булачак трасса юлында урнашкан **72** җир кишәрлеген һәм күчемсез милек объектын хуҗаларыннан алырга туры киләчәк.

Юлны кулланышка тапшыру вакытына Казанда **500000** мең данәгә якын автотранспорт исәпләнәчәк.

Төзеләчәк:

3 җир асты җәяүлеләр кичүе

1 җир өсте җәяүлеләр кичүе

2 тоннель беренче этап участогында

Проект буенча **велоюллар** салу каралган

Юл чишелешләре Гвардия урамында һәм Җиңү проспектында

КАЗАНДА ГОРЬКИЙ ШОССЕСЫНА ДУБЛЁР ЮЛ

Маршрут

Несмелов урамы белән Клара Цеткин урамы чатыннан «Серебряный бор» торак комплексы аша «Волга» М-7 трассасына кадәр

Максат

Горький шоссесындагы хәрәкәтне киметү, яңа микрорайоннарның җәмәгать транспорты белән тәэмин ителешен яхшырту

16 км
гомуми озынлыгы

4 полосалы юл
һәр яктан - икешәр полоса

18 метрга якын
хәрәкәт өлешенең киңлеге

Светофорлар

бары тик җәяүлеләр кичүе урыннарында гына

Юлларның кисешмәве, уңайлы узып китү урыннары

Беренче этап:	Несмелов урамыннан Барлык диннәр храмына кадәрге **6,2 км юл**	**– әзерлекнең югары дәрәҗәсе**
	Беренче этапның беренче эшләтеп җибәрү комплексы: Несмелов урамыннан Адмиралтейство күленә кадәрге **1,5 км юл**	**– тапшырылган**
Икенче этап:	Барлык диннәр храмыннан Киров районындагы М-7 трассасына кадәрге (Займище бистәсе) **9,5 км юл**	**– проектта**

Трасса белән параллель рәвештә түбәндәгеләр ясала:

Тротуарлар һәм велоюллар	**Җәмәгать транспорты тукталышы өчен эчкә кереп торган урыннар**	**Тавыш йоту экраннары** якын-тирәдәге йортларны һәм урамнарны шау-шудан саклый

Юл буйлап агачлар утырту һәм яңгыр сулары өчен чистарту корылмалары төзү - мәҗбүри шарт	**Берничә катлы транспорт чишелешләре, күперләр төзү** күздә тотыла

ГОРЬКИЙ ШОССЕСЫ. РЕКОНСТРУКЦИЯ



Маршрут

Казандагы Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан «Волга» М-7 трассасына кадәрге участок

2022 ел

Эшләрнең башлануы

2025 ел

Реконструкциянең тәгәлләнүе

11,8 км

гомуми озынлыгы

Сәгатенә **70** км

күздә тотылган тизлек

20 м

хәрәкәт итү өлешенең киңлеге

2,7 м

төп аеру сызыгының киңлеге

Фото: kzn.ru

Горький шоссесы буйлап велосипед юлы узачак

Булачак		Бүген
6*	Хәрәкәт полосасы	4
0**	Светофор	8
5 шуларның 3се – җир астыннан	Борылыш урыны	0



«Факел» сәүдә үзәге

СҮЗ УҢАЕННАН. 2022 елда милли проект кысаларында Татарстанда төбәк һәм җирле әһәмияткә ия, гомуми кулланыштагы 91,3 км озынлыктагы автомобиль юлында эшләр башкару планлаштырыла.

Төзеләчәк:

Җәяүлеләр кичүләре

Болотников, Фрунзе һәм Восстание урамнары киселешендә **өч катлы транспорт чишелеше*****

Залесный бистәсендә борылыш урыны****

Тротуар һәм велосипедчылар сукмагы юлның буеннан-буена

Яңа җир асты җәяүлеләр кичүләре

«Олимпиец» спорт комплексы янында, Осиново урамында, Алеутская урамында

Яңа җир өсте җәяүлеләр кичүләре

Музыкальная, Фрунзе, Коләхмәтов, Восстание урамнары тирәсендә, «Факел» сәүдә йортына якын урында

* «Факел» сәүдә йортыннан «Олимпиец» спорт комплексына кадәрге участокта
** «Волга» М-7 трассасыннан Музыкальнаяя урамына кадәрге участокта
*** кулланышка тапшыру – 2023 ел азагында
**** быел

ЧЫГЫМНЫ АРТТЫРМЫЙ ГЫНА НИЧЕК КҮБРӘК ЮЛ САЛЫРГА?

«Казан руда булмаган материаллар» компаниясе җирле базарга рациональ ысул тәкъдим итә.

ТАУЛАР... САТАБЫЗ!

Каршыбызда – кызыл төснең кояш баегандагыдай барлык төсмерләре белән балкыган биек тау. Ә аның янындагы соргылтрагы исә күз алдында үсә-күтәрелә бара. Аның башында төягечле машина эшләп йөри. Порт зонасының яр буе территориясендәге «Казан руда булмаган материаллар» компаниясе базасында мондый «таулар», саный башласаң, Һималай хәтле җыеладыр. Биредә, кечкенә генә мәйданда, бик күп руда булмаган материал тупланган.

– Безнең исәпләүләр буенча, Казанның руда булмаган төзелеш материалларына ихтыяҗы уртача биш миллион тонна чамасы тәшкил итә, бу ихтыяҗның өчтән бер өлешен без канәгатьләндерәбез, – дип сөйли «Казан руда булмаган материаллар» компаниясе хуҗасы Рафис Шәңгәрәев. – Сүз нигездә вак таш, чуерташ, ком-чуерташ катнашмалары, баетылган ком турында бара... Елга комы турында аерып әйтергә мөмкин – соңгы ике елда аңа ихтыяҗ күп тапкырга үсте. Сәбәбе бик гади: федераль хакимият юл һәм төзелеш тармакларын финанслауны арттырырга карар кылды.

Бүген «Казан руда булмаган материаллар» компаниясе арсеналында гражданлык төзелеше ихтыяҗлары өчен кирәкле ахыр продуктны җитештерү һәм китереп бирү эшендә таләп ителгән барлык техника гына түгел, ә географиясе Пермь краеннан Татарстанга кадәр җәелгән үз карьерлары да бар. Аларда компания эре фракцияле чуерташ чыгара, ә монда, Казандагы базасында, аны ваклап, юллар һәм биналар төзелешендә уңышлы кулланыла ала торган җирле продукт җитештерә. Кечкенә генә төгәллек: кулланыла ала торган, ләкин әлегә бик аз тармакта кулланылыш тапкан...

ЧӨНКИ ТАБЫШЛЫ!

Рафис Шәңгәрәев, чит ил тәҗрибәсенә таянып, игътибарны җирле базарга юнәлтергә тәкъдим итә. Мәсәлән, АКШтагы кебек. Анда иң заманча технологияләр ярдәмендә җирле материалларны төзелеш максатларына яраклаштыру гадәткә кергән. Ни әйтсәң дә, анда икътисадый табышны санап эш йөртә беләләр.

– Узган ел без базарга яңа продукт – чуерташтан ясалган вак таш чыгардык. Материал лабораториядә тикшеренүләр узды һәм үзенең югары сыйфат күрсәткечләрен практикада раслады. Бу эштә безгә «Татавтодор» АҖ һәм «Волго-Вятскуправтодор» ФКУ ярдәм итте. Алар яңа продуктны сынап карады һәм яхшы сыйфатлы асфальт-бетон катнашмалар алуга иреште. Бу катнаш-

Фотолар «Казан руда булмаган материаллар» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

маларны исә бөтен Татарстан буенча һәм аннан читтә дә файдаланырга мөмкин. Әлбәттә, проект таләпләре моңа мөмкинлек биргән очракта. Мондый юлларның сыйфатына карата бернинди дә шелтә алынганы юк. «Татавтодор» акционерлык җәмгыятенең юл төзелеше материаллары сайлаганда кыю һәм тәвәккәл эш итүен аерым билгеләп үтәсем килә. Мондый компанияләр тармакны алга алып бара! Шул ук вакытта күпләр элеккечә читтән китерелгән материаллар белән эшләвен дәвам итә. Әйтик, гранитттан ясалган вак ташны меңнәрчә чакрым ераклыктагы башка төбәкләрдән кайтарталар, чөнки Татарстанда үзендә ул юк.

– Бәлки, сәбәп сыйфатындадыр? – дип, Шәңгәрәевкә көнүзәк әһәмияткә ия соравыбызны бирәбез.

– Сүзне шуннан башлыйм: безнең материаллар начаррак түгел – монысы чыннан да шулай. Алар дәүләт стандартларының юллар төзү өчен дә, биналар төзү өчен дә кирәкле барлык параметрларына туры килә. Өстәвенә, бүген төзүчеләр арсеналында бик күп өстәмәләр, яхшырткыч матдәләр, пластификаторлар бар. Рецептураны сайлап алу аша әзер продуктның кирәкле үзлекләргә һәм сыйфатларга ия булуына ирешергә мөмкин. Мәсәлән, продуктның салкынга чыдамлылыгын һәм башка үзенчәлекләрен сизелерлек арттырып була. Һәм шул ук вакытта икътисадый яктан нәтиҗәлелекне дә арттыра аласыз. Никадәрме? Ким дигәндә, 30 процентка! Кайбер күрсәткечләр буенча тагын да күбрәк. Юлның һәр өченче километры бүләк дип әйтергә мөмкин.

СУ ТАШ ТАШЫЙ

2020–2021 еллар, пандемия. Төзелешләрдә өзеклекләр килеп чыга. Сәбәбе тимер юл транспортының Урал карьерларыннан материаллар алып кайтуны тулысынча тәэмин итә алмавы белән бәйле. Сәнәгать җитештерүчәнлеген бик тиз торгызу белән бәйле рәвештә, йөк ташкыннарының зур өлеше Кытайга юнәлә. Юл төзүчеләр шактый озак вакытка ресурслар җитешмәү белән күзгә-күз очраша. Мәсәлән, М-12 трассасын салганда, төзелешнең кыйммәтләнүенә китергән чимал дефициты барлыкка килә. Төп сәбәпләрнең берсе – автобан төзелеше барган урыннарда тимер юл составлары җитмәү һәм аларда йөк ташу күләменең нык артуы…

– Тәэминат эшендә өзеклекләрнең төзүчеләр өчен җитди проблемалар китереп чыгаруы «классик» күренеш инде ул, – ди Рафис Шәңгәрәев. – Пандемия вакытында логистикага бәйле нечкәлекләр материал бәясенең берничә тапкыр артуына китерде – төзелеш компанияләре тапшыру срокларын бозмас өчен, теләсә нинди акчалар түләргә әзер иде. Ярый ла түләп алырлык әйбере булса, чөнки хәтта зур акчаларга да материал табуы авырайды. Татарстан базарына яңа продукция тәкъдим итү өчен, мөгаен, нәкъ менә шушы хәл этәргеч биргәндер дә инде.

Вакланган таш җитештерү өчен ихтыяҗ аеруча зур булган вакытта компания чуерташны үз карьерларыннан эчке су юллары буенча китерә, бу исә тәэминат эшендә өзеклекләр тудырмаска мөмкинлек бирә. Гранитттан ясала торган вак ташка караганда чуерташтан ясалганының тагын бер өстенлеге – беренчесен су юлы буенча зур күләмдә ташып булмый.

– Бүген без клиентларыбызны вак лау өчен чимал белән дә, әзер продукт белән дә тәэмин итә алабыз, – дип сөйли «Казан руда булмаган материаллар» компаниясенең геология һәм казып чыгару бүлеге башлыгы Эмиль Мөхетдинов. – Әйтик, Пермьдәге карьерларда без эре фракцияле (фр. 20+) чуерташ чыгарабыз, баржага төяп, аны Казандагы базабызга алып киләбез. Клиент ихтыяҗы һәм таләпләре нигезендә чуерташны ваклыйбыз. Ә юл салучыларда яки йортлар төзүчеләрдә ул таләпләр, аңлаганыбызча, төрле булырга мөмкин.

– Әгәр иртәгә сезнең продукциягә шактый зур ихтыяҗ туса, булдыра аласызмы? – дип сорыйбыз компания Рафис Шәңгәрәевтән.

– Әлбәттә. Ваклап ясала торган продуктны миллион тоннага кадәр җитештерерлек куәтебез бар, алар читтән кайтартыла торган материалларны лаеклы рәвештә алыштырып, сизелерлек икътисадый файда бирә ала. Моның өчен без проектантлар белән хезмәттәшлек итәргә, фәнни эзләнү һәм аңлату эшләре алып барырга әзер, чөнки алар безнең җирле материалларны граждан лык төзелеше объектлары, шул исәптән юл төзелеше өчен килешенгән катнашмалар рецептурасына кертә башламыйча торып, күзгә күренерлек икътисадый алгарышка ирешеп булмаячак.

Егерме ел уңышлы эш дәверендә «Казан руда булмаган материаллар» компаниясе кулланучыларның ышанычын яулады. Продукциянең киң ассортименты югары дәрәҗәдә күрсәтелә торган хезмәт белән тулыландырыла. Мәсәлән, электрон шәхси бүлмәгә кереп, клиент заказның үтәлеше ничек баруын күзәтә ала, заказ башкарылганда qr-кодлар системасы кулланылуын да искә алырга кирәк. Сүз уңаеннан, компания карамагындагы материаллар базасының уңайлы җирдә урнашуы заказчыларга йөкне төяп җибәрү урынына тоткарлыксыз барып җитәргә мөмкинлек бирә, хәтта шәһәр юлларында хәрәкәт бик тыгыз булган җомга көннәрендә дә. Моннан тыш, йөк ташуның үзкыйммәтен киметү өчен, компания төяп җибәрү өчен уңайлы шартлар тудыра, шул исәптән төнге хезмәт күрсәтүне дә оештыра. Болар барысы да вакытны әрәм итмәскә (һәм нервларны да сакларга) булыша, шул рәвешле компания клиентларына үз объектларын материаллар белән тиз һәм өзеклекләрсез тәэмин итүне җайга салу өчен туры юл ача. Ә бу, килешәсездер, төзүчеләрдә бик югары бәяләнә.

ЮЛЛАР: НИЧЕК УҢАЙЛЫРАК, ЯХШЫРАК ҺӘМ КУРКЫНЫЧСЫЗРАК ИТӘРГӘ

Алсу Троицкая

Шәһәрне чыннан да бөкеләрдән азат итү мөмкин хәлме? Кешеләр өчен җәмәгать транспортын ничек уңайлырак һәм җайлырак, урам-юл челтәрен куркынычсызрак ясарга? «Татарстан» журналы әлеге һәм башка сорауларга җавап табарга тырышты. Редакциядә оештырылган түгәрәк өстәлдә Казан Башкарма комитеты, Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе, пассажир автотранспорт предприятиеләре, республика автомобильчеләре берлеге, электромобильләр инфраструктурасын үстерү буенча коммерциячел булмаган оешма вәкилләре катнашты.

Түгәрәк өстәлнең модераторы – **«ТР Автомобильчеләре берлеге» республика иҗтимагый оешмасы рәисе Рәсүл Таспенов.**

Фото: Александр Ефремов

ШӘҺӘРНЕ БӨКЕЛӘРДӘН НИЧЕК АЗАТ ИТӘРГӘ?

– Ни өчен бездә, әйтик, кайбер башка шәһәрләр үрнәгендә реверсив (өстәмә) хәрәкәт кертмәскә, бигрәк тә транспорт аеруча күп булган юлларда?

Эльнар Садриев, Казан шәһәре буенча Россия ЭЭМИнең ЮХИДИ бүлеге башлыгы:

– Реверсив хәрәкәтне оештыруга килгәндә, Казанда тарихи яктан хәрәкәт итүнең радиаль-божра схемасы урнашкан.

Бөкеләр ситуациясен хәл итү өчен соңгы 10–15 елда юл инфраструктурасы җитди үстерелде, шул исәптән юлларның аерым бер өлешләрендәге хәрәкәт схемасы да үзгәртелде.

Реверсив хәрәкәтне кертү өчен урам челтәрен яңадан оештыру таләп ителә.

ИКЕ ЕЛ ЭЧЕНДӘ РЕСПУБЛИКА БАШКАЛАСЫНДА 1 МЕҢ КЕШЕГӘ ТУРЫ КИЛГӘН АВТОМОБИЛЬЛӘР САНЫ 10%КА – 375 КӘ КАДӘР АРТТЫ.

– Бөкеләр шәһәр автобусларын йөртүчеләрнең эчкә кереп торган тукталыш «кесә»ләрендә туктамаулары яисә кайбер автомобильчеләрнең ул урыннарны алулары аркасында да килеп чыга....

Илдар Шакиров, Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары:

– Һичшиксез, машина йөртү культурасын яхшыртырга кирәк. Казан автотранспортчылары моның белән актив шөгыльләнә. Автобус йөртүченең тукталышка кереп тормыйча, икенче рәттә туктавына, әлбәттә, юл куелмаска тиеш. Ләкин кайчак алар моны эшләргә мәҗбүр, чөнки тукталыш «кесә»ләрендә әлеге дә баягы җавапсыз автохамнар туктаган була.

Без бүген нәрсәләр эшлибез? ЮХИДИ дагы коллегаларыбыз белән бергә пилот режимда алты автобуста автомат фотовидеотеркәү җайланмалары урнаштырдык. Алар автобус полосаларына кереп йөргән машиналарны терки. Тәртип бозучыларга беренче йөз хат инде китте. Камералар шулай ук автобус тукталашындагы «кесә»ләргә кереп туктаган тәртип бозучыларны да терки. Автомобиль йөртүчеләр автобус тукталышына кереп туктауның кагыйдәләрне бозу икәнлеген, моның өчен җаваплылык каралганлыгын аңларга тиеш.

Моннан тыш, без муниципаль парковкалар өчен түләнү-түләнмәүне контрольдә тотарга тиешле машиналарга куела торган фотовидеотеркәү комплексларын эшләп бетердек һәм ЮХИДИ белән бу турыда килешү төзедек. Хәзер әлеге машиналар тыю билгеләре астында калдырылган машиналарны терки ала.

Сергей Темляков, АТП Ассоциациясе рәисе:

– Пассажир ташучы предприятиеләр онлайн режимда автобус йөртүчеләрне видеоконтрольдә тота. Статистика шуны күрсәтә: бүген шәһәр пассажир автобусларының 80%ы тукталыш «кесә»сенә кереп туктый.

Ә инде «ПАРКОН» системасы камераларына килгәндә, алар үзләренең нәтиҗәле эшләүләрен күрсәтте. Бүген автобуслар өчен бүленгән юл полосаларында машиналарның хәрәкәт итүе күзгә күренеп кимеде. Ләкин кагыйдәләргә исләре китмәгән йөртүчеләр әле бар. Мондый очракларда штраф белән генә чикләнмичә, тәртип бозучының автомобилен эвакуацияләргә тәкъдим итәм.

ЭКОЛОГИЯЛЕНЕ НИЧЕК КУРКЫНЫЧСЫЗ ИТӘРГӘ

– Һәр юл, кагыйдә буларак, экологиягә зур йогынты ясый. Татарстанда боларны бер-берсе белән ничек бәйли алдылар?

Рөстәм Галимҗанов, «РЕСТАРТ», Электромобильләр инфраструктурасын үстерү буенча коммерциячел булмаган оешма вәкиле:

– Ике ел эчендә республикада электр транспорты өчен бик зур эш эшләнде, бигрәк тә корылма бирү инфраструктурасын булдыру ягыннан. 2021 ел эчендә электромобильләр саны 4 мәртәбәгә артты! Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру юнәлешендә эшне дәвам итәргә кирәк, шул исәптән электромобильләр өчен яшел номерлар кертүгә ирешү («Россия Федерациясе милли стандарты. Транспорт чараларының дәүләт теркәү билгеләре» ГОСТ Р 50577-2008 гә үзгәрешләр кертү), экологик яктан чиста транспорт өчен ниһаять транспорт салымыннан азат итү (моны РФ нең 32 субъекты башлыгы эшләде инде), шәһәрдә яңа объектлар төзегәндә электромобильләр өчен мәҗбүри рәвештә парковка урыннары ясау турында проектлаштыру һәм төзү нормаларына үзгәрешләр кертү кебек эшләрне дә башкарырга.

Ләкин электротранспорт электромобильләрдән генә тормый, бу әле индивидуаль мобильлек чаралары (СИМ) яисә тәгәрмәчле тизләткечләре булган җәяүлеләр дә. Электросамокат, монокөпчәк, электроскейтборд, гироскутер, сигвейлар да...

Мондый төр транспорт (без аларны соңгы миль транспорты дип тә йөртәбез) кулланучыларга бөкеләрдән качарга мөмкинлек бирә. Машинаны ярты юлдагы парковкада калдырып, эшкә самокатта барып җитү – ни өчен бу булмаска тиеш әле? Бик уңайлы һәм популяр ысул, бигрәк тә яшьләр арасында. Әгәр мондый парковка урыннары күп була икән, без шәһәрне өлешчә бөкеләрдән коткара алабыз. Аларда куркынычсыз розеткалар урнаштырылса, тагын да әйбәтрәк. Ләкин хәл ителергә тиешле кайбер сораулар тагын бар әле.

Һичшиксез, индивидуаль мобильлек чараларын кулланучылар өчен юл хәрәкәте кагыйдәләрен эшләү проблемасы бар. Хәзер инде алар җәяүле дә, йөртүче дә түгел. Алар катнашында юл һәлакәте килеп чыккан очракларда кеше югалып калырга, төрле күңелсез хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Бүгенге көнгә кадәр җигүле транспорт турында юл хәрәкәте кагыйдәләре яши, ә менә техник СИМнар белән идарә итүче затларның велосипед һәм җәяүлеләр хәрәкәтенә куркынычсыз кушылып китүен җайлаучы кагыйдәләр эшләнмәгән. Шул ук вакытта сәгатенә 84 км тизлек белән монокөпчәктә баручы кеше теркәлгән камера язмаларын актив тикшерәбез.

Шуңа күрә тизләткечләре булган җәяүлеләрне идентификацияләү һәм юл хәрәкәте кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе көн үзәгендә – гражданнарга велоюлларны куллану тәртибен аңлатырга һәм хәрәкәттә катнашучыларга бер-берсен хөрмәт (бүген син җәяүле, ә иртәгә тизләткеч белән булырга мөмкинсең) итәргә вакыт җитте.

ФӘРИТ ХӘНИФОВ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЫ:

– Хайваннар дөньясына кагылышлы сораулар юлларны, бигрәк тә зур трассаларны планлаштырганда мәҗбүри рәвештә ике төрле – экологик һәм төзелеш экспертизасы үтә. Барысы да исәпкә алына. Кайвакыт яңа трасса узасы урыннан ерак түгел кечкенә генә елга ага – атлап узарга мөмкин, ләкин экологлар балыкларның нәкъ менә шунда уылдык чәчүен раслый. Димәк, саклау чаралары күрергә кирәк. Шулай ук поши, кабан дуңгызы һәм башка кыргый хайваннарның миграция сукмаклары өйрәнелә. Шуңа күрә бу урыннарда экодуклар – хайваннар узар өчен күпер һәм тоннельләр салмасак, алар туп-туры юлга йөгереп чыгачак, чөнки алар үз сукмакларын үзгәртмәячәк.

Илдар Шакиров:
– Телибезме-теләмибезме, СИМнар безнең тормышның бер өлешенә әйләнде инде. Аларның хокукый статусының билгеләнмәгән булуы зур проблема тудыруы белән килешәм.

Әлеге шартларда ЮХИДИ нең актив позициясе нәтиҗәсендә без шеринг компанияләре белән өч яклы джентельмен килешүенә ирешә алдык. Шеринг самокатлары өчен тизлекнең чикләрен билгеләү, хәрәкәт итү тыелган яисә тыныч хәрәкәт (сәгатенә 10 км) зоналарын ачыклау, җәяүлеләр юлларының күпчелегендә СИМ нарда хәрәкәт итү мөмкинлеген тыю (программа дәрәҗәсендә) кебек сораулар каралды.

Шеринг компанияләре үзләре үк СИМнарның хокук бозу инструментына әйләнүенә каршы. Алар самокатларын прокат станцияләрендә калдырмаучыларның, СИМнарны балаларга бирүчеләрнең аккаунтларын ябалар.

Шул ук вакытта шеринг компанияләре мәнфәгатьләрен кайгыртып, без шәһәрдә башка фикерләр барлыгын да аңларга тиеш. Үз артыннан самокатта яисә монокөпчәктә зур тизлек белән килүчене берәү дә яратмас, дип уйлыйм. Бу җәһәттән җәяүлеләр, СИМнарда йөрергә яратучылар һәм автомобильчеләр арасында балансны табу мөһим.



– Әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә тискәре йогынты ягыннан электромобильләрнең өстенлеген беркем дә инкарь итмидер. Моңа бәйле рәвештә республикада электр корылмасы станцияләренең саны артуга барачакмы?

Илдар Шакиров:
– Тулы бер федераль программа гамәлгә ашырыла. Аның кысаларында электр корылмасы станцияләрен урнаштыру чыгымнары субсидияләнә. Безнең республикада бүген 95 станция бар. Мантыйкый парадокс: электр корылмалары структуралары ихтыяҗ булмаганга, электромобильләр аз булганга төзелми, ә электромобильләр исә инфраструктура җитмәгәнгә сатылмый. Федераль үзәк ярдәме белән бу программага субсидияләр бирелә, һәм без инфраструктураны үстерү автомобиль хуҗаларына электр транспортына күчеп утырырга этәргеч бирер, дип ышанабыз. Ноябрь ахырына кадәр Казанда тагын 46 электр корылмасы станциясе ачылырга тиеш.

Төзелеш барышында да катгый экологик контроль саклана. Әйтик, грунтны эшкәртер алдыннан якынтирәдә ташландык карьерларның барлыгын-юклыгын тикшерәбез. Бармы? Димәк, күмәбез, өске катламны да салабыз һәм шул рәвешле кайчандыр югалган территорияне табигатькә кайтарабыз. Күптән түгел генә Югары Ослан районында бик зур эш башкарылды: ике иске карьерны күмдек – бирегә 9 млн кубометр күләмендәге туфрак салынды.

Юллардан грунт суларын читкәрәк җибәрү – игътибар таләп итә торган экологик сорауларның берсе. Тозлар, май, бензин… Бүген болар барысы бергә чистарту корылмаларына агып төшә, анда күп тапкырлар чистарту узганнан соң, табигатькә зыян китермичә, туфракка сеңә.

Инерт материаллар табу сораулары буенча да экологлар белән хезмәттәшлек итәбез. Идел һәм Кама елгалары тирәсендә мондый байлык шактый. Эшне 5–6 млн тонна күләмендә чыгарудан башлаган идек, бүген безнең юллар өчен 15 млн тонна инерт материал табыла. Бу Уралдан кыйммәтле вак гранит ташын азрак алып кайтабыз дигән сүз. Шул рәвешле йөк ташу вакытындагы углеводород эзен, димәк, экологиягә тискәре басымны да киметәбез.

КЫЗЫЛ АВТОБУСЛАРГА – ЯШЕЛ УТ

– Җәмәгать транспортын пассажирлар өчен ничек уңайлы һәм җайлы ясарга?

Сергей Темляков:

– «Яндекс.Пробки» сервисы көн саен башкалабызда 6 баллы бөкеләрне теркәп тора. Кайбер очракларда хәтта кечкенә генә юл-транспорт вакыйгасы аркасында да 8–10 баллы бөкеләр хасил була. Ә алда – карлы-буранлы кыш. Бөкеләргә каршы бердәнбер рецептны мин җәмәгать транспортын үстерүдә генә күрәм.

Пассажир ташучыларның һәм Ассоциациянең үтенечен ишеткән республикабыз Президентының шәхси катнашлыгы нәтиҗәсендә агымдагы елда лизинг түләүләрен каплау өчен 195 млн сум акча бүлеп бирелде. Барыбыз да шәһәр агломерациясендә транспорт проблемаларын хәл итәргә тиешле карарлар белән кызыксына, шуңа күрә бүген җәмәгать транспортын үстерү буенча финанслар белән тәэмин ителгән махсус программа эшләнергә тиеш, дип саныйм.

Пассажирлар автобусларның йөрү вакытын озынайтуны сорый – кичке 9 дан соң алар йөрми диярлек. Бу очракта барысы да рентабельлеккә килеп терәлә. Дизель ягулыгына бәяләрнең артуы, йөртүчеләрнең, кондукторларның хезмәт хаклары, кыйммәтләнгән запчастьләр, ОСАГО полислары... Шул ук вакытта җәмәгать транспорты бернинди дә федераль ярдәм программаларына эләкми. Әйе, «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» программасы бар, аның буенча пассажир ташучылар лизингка 113 автобус алды. Ләкин Казанда гына да 250 автобусны алыштырырга кирәк. Казан янындагы бистәләрдә яшәүчеләр маршрутларда автобусларның җитмәвенә зарлана. Безнең өчен барлык бу маршрутлар финанс ягыннан зыян гына китерә.

Әмма әлеге проблемаларның нигезендә икътисадый сәбәпләр ята. Шуның белән бергә без кадрлар кытлыгын да тоябыз. Эшче һөнәрләренең абруен күтәрер вакыт җитте. Тармакның кадрлар потенциалын формалаштыру турында махсус төбәк программасы эшләнергә тиеш, дип уйлыйм.



КҮРӘБЕЗ, ИШЕТӘБЕЗ, ЭШЛИБЕЗ

Эльнар Садриев:

–Уңайлы һәм аңлаешлы урам-юл челтәрен булдырсак кына, куркынычсызлык ягыннан тиешле нәтиҗәләргә ирешәчәкбез, дип уйлыйм. Йөртүче тыныч булганда, бөкеләрдә тормаганда, минутына кадәр төгәллек белән үз вакытын «А» ноктасыннан «Б» ноктасына барып җитәрлек итеп оештырганда һәм тиешле урынга вакытында барып җиткәндә генә юл куркынычсыз һәм уңайлы була.

Моны тәэмин итү өчен республикада һәм аның башкаласында тиешле ведомство һәм хезмәтләр тарафыннан гаять зур комплекслы эш алып барыла. Нәтиҗә – яңа транспорт чишелешләре, күпкатлы җәяүлеләр кичүләре, адаптив светофорлар... Бүген миңа күзәтчелек органы вәкиле буларак юл хәрәкәтен оештыру, аны җайлау ягыннан кимчелекләр табу өчен тырышырга туры килә. Бу – бик зур көндәлек хезмәт нәтиҗәсе.

Илдар Шакиров:

– Безгә һәрвакыт тәкъдимнәрегезне җиткерә аласыз. Әгәр сездә шундый уй-фикерләр бар икән, аларны бик рәхәтләнеп кабул итәбез. Тормышка ашырырга мөмкин булганнарын эшкә җигәчәкбез. Сүз уңаеннан, Казанда сулга борылышларны тыю идеясен безгә бер шәһәрдәшебез әйтте.

Төрле җәмгыятьләр, шәһәрлеләр, активистлар белән эшләү буенча яхшы мисаллар, үрнәкләр бар. Күрәбез, ишетәбез, эшлибез...

КИЛӘЧӘКТӘ – ТУКТАЛЫШСЫЗ

Фото: Александр Ефремов

Олеся Бондаревская

М-12 юлының җөйсез полосалары Мәскәү белән Казанны инде 2024 елда ук тоташтырырга тиеш.

Озын сөзәк калкулыкның кызыл балчыгын кызгылт-сары экскаватор «кимерә». Аның артында исә – галәмәт зур бетон корылма: юлның «беренчел калыбы»н берничә терәк тотып тора. Без Ядегәр авылында (Татарстанның Югары Ослан районы) Р-241 федераль юлы белән яңа М-12 трассасы кисешкән урында ясалачак юл чишелеше төзелешен күзәтәбез.

Тирә-юньдәге табигать фонында бу корылма колачы белән шаккатыра. Авыл янында төзелешне тәэмин итү өчен салынган бетон заводының аклы-зәңгәрле төсе күзгә манзарага ямь өстәп җибәрә.

Болар барысы да – трассаны кулланышка тапшырганнан соң пәйда булачак үзгәрешләрнең башы гына. М-12 трассасы М-11 (Мәскәү белән Санкт-Петербург арасындагы «Нева» зур тизлекле магистрале) белән тоташачак һәм рухи үзәк буларак заманында Казан башкарган рольне уйнаячак, ягъни Европа белән Азия арасында күпер булачак. Белгечләр киләчәктә аның йөк ташуларга бәйле гомуми икътисадый файдасы 2,5 трлн сумга җитәчәк, дип фаразлый. Трасса Мәскәү, Владимир, Түбән Новгород өлкәләренең, Чуваш, Татарстан республикаларының (якын киләчәктә – Свердловск, Чиләбе һәм Төмән өлкәләренең дә) эре агломерацияләрен турыдан-туры автомобиль юлы белән тоташтырачак. Бу исә күпсанлы тармак җитештерүләренең кластерлы үсешенә этәргеч бирергә мөмкин. М-12 трассасы, төрле мультипликатив йогынтыдан тыш, элек юллардан чагыштырмача кыерыйдарак калган республика торак пунктлары үсешенә этәргеч бирер дип тә карала.

ЧУВАШИЯДӘН ШӘЛЕГӘ КАДӘР ҺӘМ ТАГЫН ДА АРЫРАК

– Чәчкабка кагылып чыгыгыз, трасса шул таба барачак, – диделәр безгә Олы Кайбыч тирәсендәге юл чатын төзүчеләр. Шулай итеп, без Чувашия чигенә кадәр килеп җиттек дияргә була, М-12 Татарстанга әнә шуннан «килеп керә». Иделнең уң ягында трасса Иске Чәчкаб, Олы Кайбыч, Урта Колаңгы (Кайбыч районы), Югары Аккуҗа, Азбаба (Апас районы), Карагуҗа, Ядегәр, Мулланур Вахитов исемендәге (Югары Ослан районы) авыллар яныннан узып, Гребени тирәсендә Идел аша чыгачак һәм аның сул ягында Лаеш районының Орел, Тарлаш, Пиголи, Сабакүл, Травкино, Хәерби, Кызыл Ил, Егорьево торак пунктлары янәшәсеннән узачак. М-12 трассасы Питрәч районында Шәле–Саескан Тавы 16К-1091 юлы белән тоташып тәмамлана.



«Автодор» башлыгы Вячеслав Петушенко бер әңгәмә вакытында телгә алганча, М-12 трассасында, беренче категорияле башка юллардагы кебек үк, штраф языльмый торган тизлек сәгатенә 150 км ны тәшкил итәргә мөмкин. Әлегә бу сан – проектта гына, Татарстанга караган участокта тизлек сәгатенә 110 км белән чикләнгән. Әмма перспективадагы тизлекләрне исәпкә алып, трасса «җөйсез» итеп эшләнә, ягъни анда светофорлар һәм башка юл белән кисешкән урыннар булмый. Шуңа күрә М-12 трассасына керү һәм аннан чыгып китү өчен әнә шул юл чишелешләре төзелә дә. Алар трассаны федераль һәм төбәк карамагындагы башка юллар белән тоташтырачак. Логистика ягыннан уйланылган мондый тоташу урыннары трассага башка төбәкләрдән, әйтик, Ульяновск һәм Самара өлкәләреннән киләчәк автомобильләр агымының җиңел кушылып китүенә мөмкинлек бирәчәк. Татарстанлыларга да республиканың бер очыннан икенчесенә барып җитү җиңеләячәк. Мулланур Вахитов исемендәге авыл янында – Югары Ослан–Казан юнәлешендә, Сапуголи авылы тирәсендә Казан–Мәскәү юнәлешендә трассага керү-чыгу юлы төзелә. Ә Лаеш районындагы Егорьево авылы янында ике катлы юл чишелеше М-12 трассасын Р-239 Казан–Оренбург федераль юлы белән тоташтырачак. Ә Шәле–Саескан Тавы юлы аша бик җиңел генә М-7 трассасына чыгып китәргә була.

КЕШЕ ФАКТОРЫ

Иске Чәчкабтан соң без хәзер төзелә торган трассага параллель рәвештә Иделгә таба юнәләбез. Әйтерсең лә, без үзеннән соң яңа киң соры буйлар, зур чокырлар, туфрак һәм кызыл балчык өемнәре, карьерлар калдырып бара торган ниндидер бер әзмәвер җан иясен эзәрлеклибез. Ләкин болар барысы да – төзелештә катнашучы берничә мең кешенең һәм йөзләгән данә техниканың фидакарь хезмәте нәтиҗәсе. Монда эш ел әйләнәсе тәүлек буе алып барыла. Төзүчеләрнең безнең белән сөйләшеп торырга вакыты да юк – монда бер төркем юл нигезен сала, бераз арырак икенчеләре эстакаданың металл конструкцияләрен эретеп ябыштыра. Ә безнең күп нәрсә турында ишетәсебез килә: төзүчеләр өчен бу проектны тормышка ашыру нәрсәне аңлата? Мондый темпта эшләү авырмы? Эшчеләрнең берсе соравыбызга җавап биреп тормады, юл тигезли торган катокка менеп утырды да эшенә кереште. Күренеп тора: җитди, үҗәт, максатчан.

Төзелеш 2020 ел уртасында башланды. Шул вакыт эчендә төзүчеләр тарафыннан бинйһая зур эш инде башкарылган. Татарстан территориясеннән уза торган 142 км трассаның 60% ында юл нигезе салынган, трассаның яртысында диярлек икенче катлам да түшәлгән. «Полировка» дип аталган процесс, ягъни өске катламны җәя башлау 2023 елга планлаштырылган.

Төзелеш (нульдән башланган!) гадәттәгедән бераз аерылып тора. Мәсәлән, асфальтның һәр катламына төрле асфальт-бетон катнашмасы салына. Хәтта Татарстан климаты шартларына туры килгән яңа битум маркасы да кулланыла. Биредә материалларда гына түгел, эшне алып бару ысулларында да өр-яңа технологияләрдән файдаланалар. Ком һәм вак таш катламнарын автогрейдер һәм бульдозерга, асфальт-бетон җәйланмасына яраклаштырап проектлау өчен 3D-модельләштерү ысулы кулланыла. Ә кюветны ясау һәм юл өемнәрен планлаштыруда 3D-системалы «акыллы» экскаваторлар катнаша, алар эшне тизрәк һәм төгәлрәк башкара. Юлның үзеннән тыш, күптөрле корылмалар – күперләр, юлүткәргечләр, авыл хуҗалыгы техникасы өчен юллар, кыргый хайваннар өчен кичүләр һәм башкалар да менә шундый инновацияләр һәм яңа технологияләр ярдәмендә төзелә.

КОРАБЛАР ҺӘМ ХАЙВАННАР ӨЧЕН

Мулланур Вахитов исемендәге авыл янында М-12 трассасына кереп китә торган (әллә аннан чыгып китүме?) юл төзелешенә сокланып туйгач, Идел аша күпер ничек төзелгәнен ерактанрак карау өчен, инде эңгер-меңгер төшкәндә диярлек Ташкабак авылы тирәсендәге яр буена килеп җиттек. Моннан ул башнялы краннардан гыйбарәт энәләр кадалган озын, нечкә җеп булып күренә. Күпер озынлыгы 3,5 километр чамасы,

МАРС ГАЗИЗУЛЛИН, «РОССИЯ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫ» ДӘҮЛӘТ КОМПАНИЯСЕ ИДАРӘСЕ РӘИСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ УРЫНБАСАРЫ:

– Югары тизлекле М-12 трассасын кулланышка керткәннән соң, татарстанлылар Мәскәүгә 6,5–7 сәгать эчендә барып җитә алачак. Планнарыгызны самолет графигы яки поезд хәрәкәте расписаниесе белән көйләргә туры килмәячәк. Логистиканың яхшыруы республикага инвестицияләр җәлеп итүне арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Идел һәм Кама аша яңа күперләр Казаннан Югары Ослан, Кама Тамагы, Түбән Кама һәм башка районнарга бару вакытын кыскартачак.

Исегезгә төшереп үтим, 2024 елга кадәр юл Екатеринбургка кадәр барып җитәчәк. Ул Чаллы һәм Түбән Каманы урап узачак, Дүртөйлегә кадәр юл дүрт полосага кадәр киңәйтеләчәк, ул торак пунктларны әйләнеп үтәрлек итеп салыначак.

М-12 трассасының 7 һәм 8 нче этапларында ике катлы алты юл чишелеше төзү каралган.

аның 1 километрга якыны инде төзелгән. Күпер Иделдә суднолар йөрешенә зыян китермәячәк – кораблар үтеп йөри алсын өчен, 155 метрлы ике аралык ясала. Шаккаткыч нәрсәләр монда шактый: әйтик, сул як ярда, Орел авылы тирәсендә, төзелеш максатларында 50 м тирәнлектәге җирне чокып барырга туры килгән.

Бер уңайдан, табигать турында да берничә сүз: М-12 проектында әйләнә-тирә мохитне (кешеләрне дә, хайваннарны да) юл йогынтысыннан саклау чаралары каралган. Трасса үтәчәк елга-инешләрне күп баскычлы локаль чистарту системалары ярдәмендә саклау күздә тотыла: фильтрлар зур чүп-чардан алып май һәм нефть тапларына кадәр – бөтен нәрсәне тотып калачак. Кыргый хайваннар трассаны исән-имин аркылы чыга алсын өчен, экодуклар – табигый сукмаклар итеп ясалган күперләр төзеләчәк. Аларга тавышны йоту экраннары куелачак. Шундый ук экраннарны торак пунктларда да көйләячәкләр.

КАРТА ДА КИРӘК ТҮГЕЛ

Әлегә трасса картинаның эскизын хәтерләтә, ләкин инде хәзер үк бу картинаның никадәр зур, колачлы булачагын чамаларга мөмкин. Күз алдына китереп карау кыен түгел: менә Шәле тирәсендәге ике катлы юл чишелешеннән трассага килеп кергәч, Идел аша биек күпердән узасың һәм 20 минут эчендә Олы Кайбыч янындагы күпфункцияле «станция» янына килеп җитәсең дә хәл кертү өчен эспрессо эчеп, кайнар өчпочмак ашап алырга туктыйсың. Бераздан кабат юлга кузгаласың һәм алты сәгатьтән инде Мәскәүдә кичке аш ашарга утырасың. Вактөяк мәсьәләләрне, ягъни юл хакын «Ирекле агым» дип исемләнгән контактсыз түләү системасы кайгыртачак, ләкин монысы әле соңрак, ә хәзер – юлга!..

АВТОМОБИЛЬ ҺӘМ ШӘҺӘР ПАССАЖИР ТРАНСПОРТЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ КӨНЕ **ОКТЯБРЬНЕҢ СОҢГЫ ЯКШӘМБЕСЕНДӘ** БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ

БАШКАЛАГА ЛАЕК ТРАНСПОРТ

Кызыл автобуслар Казанның һәм Татарстандагы башка зур шәһәрләрнең көндәлек тормышына шулкадәр җайлы кереп китте ки, безгә бик табигый тоелган бу сервиска – даими җәмәгать транспортына шәһәрнең автотранспорт предприятиеләре, шул исәптән ПАТП–2 хезмәткәрләренең көн саен никадәр зур хезмәт кертүе турында инде уйлап та карамыйбыз.

Әлеге предприятие машиналары көн саен ташыган кешеләр саны зур булмаган бер шәһәр халкын тәшкил итә ала. Предприятиегә бәйле саннар хәйран калдырырлык: 816 машина йөртүче, 555 автобус, 41 төп һәм 5 сезонлы маршрут, ай саен 10 миллион пассажир. Мондый әйләнеш һәр оешманың да хәленнән килерлек түгел, әмма ПАТП-2 ия булган ресурслар хәтта халыкара дәрәҗәдәге чараларга бәйле аеруча киеренке вакытларда да алга куелган бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә.

ЮГАРЫ КУЛЬТУРА ПРЕДПРИЯТИЕСЕ

Күп очракта уңыш сере – тәҗрибәдә. Предприятие ТАССРда 1976 елда нигез салынган беренче пассажирлар ташу транспорты оешмасыннан үсеп чыга. Ул оешманы тиздән халыкта «Гараж 400» дип атый башлыйлар – беренче автотранспорт базасы әнә шулкадәр машинага исәпләнгән була. Озак вакыт аның нигезен авырлык белән борыла торган «ЛАЗ»лар, «ПАЗ»лар һәм озын «Икарус»лар тәшкил итә. Машиналар бер-ике ел гына түгел, дистә еллар дәвамында кулланышта йөри. Пассажир ташучы көч-хәл белән эшләп бара: автопаркны да йөрерлек хәлдә тотарга, һәрчак кытлык булган шоферларны да кайгыртырга, шәһәр халкы завод-предприятиеләргә вакытында барып җитә алсын өчен, маршрутларга тиешенчә хезмәт күрсәтергә дә кирәк.

– Мин предприятиебезгә 1987 елда эшкә урнаштым. Акрынлап барлык белгечлекләрне, шул исәптән автобус йөртүче һөнәрен дә үзләштердем. ПАТП-2 оешмасындагы хезмәт тәҗрибәмнең 35 елында иң авыры эксплуатация буенча директор урынбасары булып эшләгән вакытыма туры килде. 90 нчы еллар иде ул, шактый катлаулы бурычларны хәл итәргә мәҗбүр булдык. Мин техника, шоферлар, расписание өчен җаваплы идем. Машиналар бик иске, алар белән идарә итү уңайсыз, тизлек тапшыру тартмалары да механик ысуллы. Кадрлар белән проблемалар, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр дефицит, – дип искә ала **ПАТП-2 генераль директоры, VI чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Россиянең мактаулы транспорт хезмәткәре Альберт Мөхәммәтшин.** – Әмма шәһәр ярдәмсез калдырмады, һәм без кыенлыкларны ерып чыктык. Предприятиене саклап кала алдык. 1986 елда – «Югары хезмәт күрсәтү культурасы предприятиесе», 1989 елда Автомобиль транспорты министрлыгы системасында иң яхшы предприятие кебек дәрәҗәле исемнәр яуладык. Ә 2015 елда «Алтын тәгәрмәч» халыкара транспорт премиясенә лаек булдык.

ГАЛӘМНӘН БАРЫСЫ ДА КҮРЕНӘ

«Сыйфатлы җәмәгать транспорты – гражданнарыбызның күтәренке кәефе ул», – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, КАМАЗ заводының газга көйләнгән 57 автобустан

гыйбарәт сынау партиясен ПАТП-2 һәм ПАТП-4 (хәзер ПАТП-2 составына керә) предприятиеләренә лизингка тапшыру тантанасында. 2006 елда республика һәм шәһәр хакимиятләре ПАТП-2 не заманча түбән идәнле автобусларга күчерү турында карар кабул итмәгән булса, бу тантана, бәлки, чынга да ашмас иде. Шәһәр мэры Илсур Метшин вазгыятьне үз контроленә алды, шәһәрнең транспорт системасына реформа үткәреп, пассажирлар ташу тармагына карашны тулысынча яңартты. Бүген ПАТП-2 паркы составында түбән идәнле һәм ярым түбән идәнле өр-яңа «МАЗ»лар һәм «НЕФАЗ»лар гына эшли. Һәр машинага навигация һәм видеокүзәтү системалары, җылыткычлар, инвалид коляскасы өчен күтәртү җайланмалары көйләнгән. Хәтта книлинг системасы да бар, ягъни автобус пассажирлар керү-чыгу ишекләре ягына таба 7 градуска иелә ала. Пассажирларга тукталышлар турында автоинформатор хәбәр итә.

Әлеге заманча техниканың гадәти пассажирга күренми торган мөһим функцияләре дә бар. Барлык автобуслар да космик иярченле навигация системасына тоташтырылган. Ул автобусларны линиягә чыгару тәртибенә анализ ясарга, шәһәрнең видеограммасы буенча транспорт хәрәкәтенең даимилеген һәм теге яки бу маршруттагы вазгыятьне контрольдә тотарга булыша. Диспетчер теләсә кайсы вакытта автобусның урынын билгели, машина йөртүче белән элемтәгә керә ала, хәрәкәт вакытындагы кагыйдә бозулар турында мәгълүмат та күренә. Шулай итеп, маршрутларда хәрәкәт тәртибе яхшыртылган, аңа вакытында төзәтмәләр кертү һәм шул рәвешле шәһәр халкын тукталышларда озак көтеп торудан коткару мөмкинлеге барлыкка килгән. Моннан тыш, космик иярчен элемтәсе куркынычсызлыкны тәэмин итәргә булыша: система диспетчерга юл-транспорт һәлакәтләреннән алып террорчылык очракларына кадәр – теләсә нинди гадәттән тыш хәл турында хәбәр итә һәм, тиешле хезмәтләрне чакыртып, тиз арада чара күрә ала.

АШАТЫРГА, ӨЙРӘТЕРГӘ, ДӘВАЛАРГА

2300 гә якын кеше хезмәт куя торган предприятиенең эшен җайга салырга «Галактика» мәгълүмат системасы мөмкинлек бирә. Монда барлык җитештерү процесслары буенча мәгълүмат булдырыла, саклана һәм анализлана. Бу исә предприятие җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең вакытын һәм ресурсларын экономияли, бөтен ПАТП-ның эш нәтиҗәлелеген күтәрә. ПАТП-2 оешмасының шул рәвешле технология һәм мәгълүмат ягыннан тәэмин ителеше предприятие эшчеләренә мондый авыр хезмәтне башкару өчен мөмкин кадәр уңайлыклар тудыру максатында да кирәк.

– Җәмәгать транспортын йөртүче, иртәнге сәгать өчтә торып, машинасын әзерли һәм теләсә нинди һава торышы шартларында, юлда ни генә булуга да карамастан, тулы бер смена эшләп чыга, – ди Альберт Мөхәммәтшин.

Аның тәкъдиме белән ПАТПда хезмәт шартлары даими рәвештә яхшыртыла бара. Машина йөртүче булырга теләүчеләр өчен предприятиенең – үз автомәктәбе, квалификациясен күтәрергә теләүчеләр өчен уку үзәге эшли. Ремонт ясаучылар өчен гардероб, душ, кер юу бүлмәсе булган комплекс көйләнгән. Иртән юлга чыкканчы тамак ялгап алсыннар өчен, шоферларга буфет хезмәт күрсәтә. Кирәге чыкканда, һәр хезмәткәр медицина ярдәме кабинетына мөрәҗәгать итә ала, анда терапевт, стоматолог һәм хәтта массаж остасы кабул итә. Предприятиедә сәламәтлекне бик җитди кайгырталар: хезмәткәрләр ел саен тулы медицина тикшерүе уза һәм табиб юлламасы белән Татарстан шифаханәләренә җибәрелә.

ГОРУРЛЫК ҺӘМ ХӨРМӘТ БЕЛӘН

Техниканы да предприятиенең үзендә «дәвалыйлар»: гадәти ремонт остаханәсеннән һәм ярдәмче цехлардан тыш, биредә «НЕФАЗ» һәм «МАЗ»ларга хезмәт күрсәтә торган сертификацияле сервис үзәге эшли. Нәтиҗә куандыра: автобусларның техник әзерлек коэффициенты 0,97% тәшкил итә.

Әнә шушы чаралар һәм башкалары ярдәме белән, хәтта бик тыгыз эш графигы булганда да, ПАТП-2 хезмәткәрләре традицияләрне саклап калыр өчен мөмкинлекләр таба. Биредә бәйрәмнәрне һәрвакыт бик матур һәм күңелле итеп билгеләп үтәләр, балалар һәм өлкәннәр турында кайгырталар, спорт һәм хәйриячелек белән шөгыльләнәләр.

– Без берничә предприятиене берләштерүгә ирештек, заманча автопарк булдырып, аны тотып-карап тотуны тәэмин иттек, республика башкаласында барлык пассажирлар ташу хезмәтенең 50%ын алып бара торган транспорт эшен җайга салдык, – ди Альберт Мөхәммәтшин. – Бу – коллективыбызга горурланыр һәм хөрмәт казаныр өчен бер нигез, алга таба да тырышып эшләү өчен этәргеч булып тора. Шәһәр һәм республика җитәкчелеге транспортның, беренче чиратта җәмәгать транспортының, куркынычсыз һәм уңайлы хәрәкәтен тәэмин итүгә күп көч куя. Без дә бу эшкә лаеклы өлеш кертергә телибез.

– Хөрмәтле пассажир транспорты тармагы хезмәткәрләре һәм ветераннары! Республикабыз һәм аның башкаласы үзенең кунакчыллыгы, кешеләргә дустанә, җылы мөнәсәбәте белән дан тота. Күп яктан бу – сезнең дә казанышыгыз. Һөнәри бәйрәмегез белән ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз! Сезгә бәхет, тынычлык, иминлек һәм мул тормыш телим!

ПАТП-2 генераль директоры Альберт Мөхәммәтшин

Фотолар ПАТП-2 матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

ИКМӘКЛЕ ЕЛ

Быел республика кырларыннан җыеп алынган 5,4 миллион тоннадан артык ашлык – күркәм нәтиҗә. Узган елгы 2,4 миллион тонна белән чагыштырганда бик күп. Әмма аграрийлар үзләре моны тыйнак күрсәткеч дип саный: мулрак уңыш алган заманнар да бар иде…

Чыннан да беренче тапкыр 6 миллион тоннадан артык ашлык җыеп алынган 2008 ел Татарстан өчен рекордлы ел булып кала. 2001, 2002 нче тук елларны да искә төшерергә була, ул чакта амбарларга быелгыга караганда күбрәк икмәк салына. Шуңа да карамастан, мондый чагыштыруны төгәл дип әйтеп булмый: бу елларда табигать үзе авыл хуҗалыгына карата хәерхаһлы булды. Быелгы корылыклы июль һәм август айларын авыл хезмәтчәннәре өчен уңай дип атап булмый. Әмма һава торышы шартларына да карамастан, мул уңыш җыеп алынды.

АРЧА, ТӘТЕШ ҺӘМ БУА – ҮРНӘК КҮРСӘТҮЧЕЛӘР

– Җыеп алынганга караганда күбрәккә ирешергә ниятләгән идек, – диде ТР Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җаббаров. – Әмма бөртек ачрак һәм ваграк булып чыкты. Шулай да республика яхшы уңыш алды, дип саныйм.

Министр сүзләренә караганда, һава торышы шактый уңай булган, әмма аграрийларга «башак, аеруча сабан ашлыгы формалашкан» вакытта дым һәм салкынча һава җитмәгән.

Яңа статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, ведомство башлыгы тагын бер мөһим нәрсәне билгеләп үтә: «Әгәр дә сез игътибар иткән булсагыз, Татарстан Президенты мин доклад сөйләгәндә төгәллек кертүне сорады: бу эшкәрткәннән соң, сортировкадан соңмы, әллә бункер авырлыгындамы? Бу бункер авырлыгында. Тагын 100 мең тоннага якын кукуруз бөртеге алырбыз, дип көтәбез, шуңа күрә 5,4 млн тоннадан артык булыр, дип уйлыйм. Һәм эшкәртеп-чистартып бетерүне исәпкә алып, амбар-складларга якынча 5,1 млн тонна бөртекле ашлык салачакбыз».

Бүген югары уңыш алу өчен тырыш хезмәт генә җитми. Заманча технологияләр, сыйфатлы орлык, кирәкле күләмдә минераль ашлама таләп ителә. Экспертлар фикеренчә, барлык бу күрсәткечләр республика уңышына аеруча зур өлеш керткән районнарның мул ашлык җыеп алуында хәлиткеч роль уйнаган. Андыйлар арасына 200 мең тоннадан артык уңыш җыеп алган Арча, Тәтеш, Буа, Мөслим һәм Минзәлә районнары керә.

Барлык агротехнология чараларын оптималь срокларда сыйфатлы итеп үткәрә торган хуҗалыкларда югары уңыш җыялар. Бу аксиома. Шуңа да карамастан, Марат Җаббаров сүзләренә караганда, «кемдер моңа

Фото: «Татарстан» журналы архивыннан, tatar-inform.ru

игътибар итми, кемнеңдер – акчасы, кемнеңдер белгечләре юк, ә кемгәдер контроль җитми». «Нәтиҗәдә, без теләгән күрсәткечкә ирешә алмыйбыз», – диде ведомство җитәкчесе. Ваемсызлар белән нәрсә эшләргә? Вариантларның берсен, ихтимал, бик гуманлы булмаса да, мантыйкка ярашлы һәм, әйтергә кирәк, нәтиҗәлесен министр атап үтте: «Без киләсе елдан туфрак анализы турында паспорты булмаган хуҗалыкларга, мөгаен, ярдәм күрсәтүне туктатырбыз. Җирне максималь дәрәҗәдә дөрес карый-тәрбияли торган хуҗалыкларга булышасы килә. Чөнки болар барысы да уңышка йогынты ясый».

МАРАТ ҖАББАРОВ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ - ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЫ:
– ЖЫЕП АЛЫНГАНГА КАРАГАНДА КҮБРӘККӘ ИРЕШЕРГӘ НИЯТЛӘГӘН ИДЕК. ӘММА БӨРТЕК АЧРАК ҺӘМ ВАГРАК БУЛЫП ЧЫКТЫ. ШУЛАЙ ДА РЕСПУБЛИКА ЯХШЫ УҢЫШ ҖЫЕП АЛДЫ, ДИП САНЫЙМ.

ТАТЛЫ РИЗЫК ӨЧЕН 250 МЕҢ ТОННА

Бөртекледәр буенча алынган яхшы уңыш, әлбәттә, шатланыр өчен сәбәп. Калганнары ни хәлдә? Быел шулай ук бәрәңге, яшелчәләрне узган корылыклы ел белән чагыштырганда күбрәк җыярга ниятлиләр. Шикәр чөгендерен – 1 млн 650 мең тонна. Бу күпме, әллә бик күп түгелме? Үзегез уйлап карагыз: Татарстан Республикасының шикәргә ихтыяҗы – 100 мең тонна. Ә республика 250 мең тонна шикәр чөгендере игүне күздә тота – ике ярым тапкырга күбрәк!

Майлы культуралар, бәрәңге, яшелчәләр буенча фаразлар түбәндәгечә: 1600 мең тонна, 800 мең тоннадан артык һәм 260 мең тонна. Халыкның бәрәңгегә ихтыяҗы – якынча 350 мең тонна, тагын 160 мең тоннаны орлыкка сакларга кирәклеген исәпкә алсак, кытлык булмаячак. Әлбәттә, тиешенчә сакланган очракта. Икенче яктан караганда, алдагы елларда (узган корылыклы елны исәпкә алмаганда – ред. иск.) республикада 1,1–1,2 миллион тонна бәрәңге үстерелгән.

Республикада сөт саву күләме арткан – сигез ай эчендә үсеш 31,6 мең тоннаны тәшкил итте. Бу чорда барлыгы 1,3 млн тоннадан артык сөт савып алынды. «Ел азагына сөт буенча плюска чыгарга планлаштырабыз. Бер сыердан алынган савым буенча 5 процентлы үсеш белән барабыз», – дип раслый Марат Җаббаров. Дөрес, быел республикада 2 млн тонна сөт җитештереп булмаячак, әмма 1 млн 980 мең тоннаны күздә тоткан план үтәлер, дип ышандыра министр. «Быел бер сыердан 6,6 мең литр сөт савып алабыз, – дип аңлата ведомство башлыгы. – Киләсе елда 7 мең литр алырга планлаштырабыз».

Киләсе ел өчен уңышның һәм терлекчелек продукциясенең нигезе бүген үк салына.

ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕННӘН БАШКА КАЛМАЯЧАКБЫЗ

Шунысы билгеле: уҗым культуралары быел узган елдагыга караганда кимрәк чәчелмәячәк. Минераль ашлама һәм сыйфатлы оригиналь орлыкларга килгәндә исә, монда планнар арттырылачак. Әлбәттә, боларның барысына да акча кирәк була, бу техника әзерләүгә дә кагыла. Запас частьләрне сатып алу һәм төзәтү өчен генә дә 5 миллион сумнан артык акча таләп ителә. Узган ел бу сан кечкенәрәк иде, ләкин бәяләрнең артуын исәпкә алырга кирәк.

Заказларны озакка сузарга ярамый. Быелгы сезон моны яхшы исбатлады: алдан хәстәрен күргәннәр барлык кирәкле запас частьләрне, техниканы махсус операция башланганчы ук алып калырга өлгерде. Ә «ел дәвамында үз эшләрен көйли, запас частьләрне дус дәүләтләр аша кертә алдылар, тәэмин итү буенча өзеклекләр булмады», – дип аңлатты министр.

Терлекчелекне үстерү перспективалары турында сөйләгәндә, Марат Җаббаров хуҗалыкларның өч ел эчендә көтүне яңарту, сыерларны сайлап алу буенча җитди эш башкаруларын, шуның аркасында терлекләрнең баш саны кимүен билгеләп үтте. Шул ук вакытта республикага бик күп мөгезле эре терлек кертелә. Ел ахырына кадәр 16 мең башка якын яңа терлек алып кайту планлаштырыла, шул исәптән югары продуктлы алты мең башы чит илләрдән кайтартылачак. «Терлекләрнең баш санын 100%ка бетереп, аларны тулысынча яңарткан предприятиеләр бар».

Марат Җаббаров шулай ук тармакка дәүләт ярдәме кысаларында 27 чараны гамәлгә ашыру өчен 13,6 млрд сум акча каралуын хәбәр итте. Шуның 9,1 млрд сумы – республика бюджетыннан, калганнары федераль бюджеттан бүлеп биреләчәк.

«Ел ахырына кадәр сатылган ашлыкны субсидияләү өчен федераль бюджеттан 1,3 млрд сум акча керергә тиеш. Объектларны төзү чыгымнарын кайтару буенча программалар бар. Сайлап алу федераль дәрәҗәдә бара, без дә үз проектларыбызны күрсәттек. Анда да шактый суммалар алырбыз, дип өметләнәбез. Төзелешкә салынган 25%тан артык акча кире кайтарыла. Киләсе елда республика бюджетыннан шундый ук ярдәм көтәбез», – дип йомгаклады министр.

АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫ: «ЦИФР»ГА КҮЧКӘН КЕРЕМ АЛА

«А-ТРЭКЕР» компаниясе фермер хуҗалыгының җитештерүчәнлеген арттырырга, бу тармакта алдынгылык яуларга мөмкинлек бирә торган IT-технологияләр булдыра. Бизнеста уңышка ирешергә телисезме? Агросәнәгать комплексын цифрлаштыру эшенә кушылыгыз, бүген ул – уңайлы сервис кына түгел, заман таләбе дә!

«Цифрлы» технологияләр киләчәк түгел инде, ә хәзерге көн ихтыяҗы, шул исәптән авыл хуҗалыгында да. Нәкъ менә шуңа күрә «А-ТРЭКЕР» ширкәте, «Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» АҖ белән бергә, агросәнәгатьне цифрлы трансформацияләү өчен тырышлык куя.

Компания тәкъдим иткән продукт Li-Da (Livestock Data) дип атала. Ул барлык мәгълүматны системага сала, көтүдәге маллар санын, дөньяга килүдән башлап көтүдән чыгарылуга кадәр хайван белән булган барлык хәлләрне теркәп бара. Бу шулай ук хуҗалыктагы төп процесслар һәм персонал белән идарә итү өчен тулы CRM-система да булып тора.

Мәгълүмат җыюда өстәмә продуктлар – сөт хисаплагычлар, Россельхознадзор билгеләгән уникаль тәңгәлләштерү номерына ия ярлыклар ярдәм итә. «А-ТРЭКЕР» тәкъдим иткән маркировкалау чаралары ICAR халыкара оешмасы тарафыннан сертификацияләнгән, алар куллану өчен уңайлы һәм куркынычсыз, чыдам, металл элементлары юк, шуңа күрә аларны утильләштерү арзанрак, малларга зыяны да азрак.

Компаниянең тагын бер хезмәт җимеше – терлекнең хәрефле-санлы тәңгәлләштерү кодын укырга сәләтле сканер. Эш шунда ки, бөтен дөньяда саннар гына кулланыла, ә 2022 елның мартыннан Россиядә аларга хәрефләр дә өсти башладылар. Хуҗалыкларда гамәлдә булган сканерлар исә андый «катнаш» код белән эшли алмый. Бу бер проблемага әйләнә. Компания белгечләре аннан чыгу юлын тапкан – саннарны да, хәрефләрне дә укып, мәгълүматны bluetooth аша теләсә нинди җайланмага тапшыра ала торган сканер ясыйлар, өстәвенә, ул чит ил җиһазларыннан берничә тапкыр арзанрак та. Базарга товар быел ук чыгар дип планлаштырыла.

«А-ТРЭКЕР» – АККРЕДИТАЦИЯЛӘНГӘН IT-КОМПАНИЯ, ИННОПОЛИС РЕЗИДЕНТЫ

«БЕР ТӘРӘЗӘ» СИСТЕМАСЫ

Киләсе елда Li-Da системасына «Логистика», «Маркетплейс», «Компетенцияләр» модульләре өстәләчәк. Шул рәвешле компания «бер тәрәзә» системасын булдырырга тели, ягъни клиент төрле хезмәтләрдән бер кушымта ярдәмендә бик җиңел файдалана ала. Монда малның исәбен алып барырга, товарларга заказ бирергә, консалтинг компанияләре яки ветеринарлар белән аралашырга җай булачак – мөмкинлекләр исемлеге бик киң.

Система ярдәмендә фермерга субсидияләр алу, инвесторлар табу кулайлашачак. Барлык мәгълүматлар да исәпкә алынган, бар да ачык һәм аңлаешлы, бернәрсә дә уйлап табарга һәм исбатларга кирәк түгел.

ИҢ КӨЧЛЕЛӘР КАЛА

– Без клиентлар белән бергә үсәргә телибез – продуктыбызның фәлсәфәсе шундый, – ди идарәче партнер Марат Миңгәриев. – Әгәр сезнең фермер хуҗалыгы кечкенә икән, безнең продуктны бушлай аласыз, мәгълүматны болытта саклаган өчен генә түләргә кирәк. Бизнесыгыз үсә барган саен, сезнең программага өстәмә таләпләрегез барлыкка киләчәк һәм системага өстәмә функцияләрне тоташтыру ихтыяҗы туачак. Ул очракта без программаны сезнең ихтыяҗга яраклаштыру эшен башкарабыз. Бу эш техник бирем нигезендә түләүле шартларда тормышка ашырыла. Ләкин беренче этапта, кабатлап китәм, бушлай хезмәт күрсәтелә. Без үзебез килеп, барысын да урнаштырабыз, көйлибез, өйрәтәбез.

Зур булмаган фермер хуҗалыклары өчен бу – бик зур плюс, чөнки аграрийлар үзләренә «цифрлы» технологияләрнең ни өчен кирәклеген кайчак аңлап та бетермиләр, ни кызганыч, агросәнәгать комплексында цифрлаштыру дәрәҗәсе башка тармаклар белән чагыштырганда түбәнрәк. Ә биредә исә, акча тотмыйча гына, табышлы бизнес алып барырга өйрәнү мөмкинлеге бар. Ахыр чиктә базарда иң көчлеләр генә торып кала бит.

Сүз уңаеннан, бернинди махсус җиһаз да сатып алырга кирәкми, барысы да инде гамәлдә булган компьютерга һәм смартфонга урнаштырыла. Продукциянең веб-версиясе һәм телефон өчен кушымтасы бар. Программа һәм интерфейс кулланучы өчен мөмкин кадәр уңайлы итеп эшләнгән.

*«А-ТРЭКЕР» компаниясе хезмәттәшләрен һәм партнерларын **Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне белән котлый!** Сәламәтлек, бәхет, уңыш юлдаш булсын!*

«А-ТРЭКЕР» компаниясе

ТР, Иннополис шәһәре, Университет ур., 7 нче йорт, 640 нчы бүлмә

a-tracker.ru

mingarievmf@a-tracker.ru

+7 906 124-36-68

Фото «А-ТРЭКЕР» компаниясе тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

TILLERMASTER – УРТАЧА АВЫРЛЫКТАГЫ ТИЗ ЙӨРЕШЛЕ КУЛЬТИВАТОР

Росстат мәгълүматлары раслаганча, «Агромастер» компаниясе эчке базарда культиваторлар сату буенча быел Россия машина төзелеше предприятиеләре арасында беренче урында тора*.

Техника Россиянең 45 төбәгендә һәм Казахстанда сатыла. Tillermaster** чәчү алды культиваторы «Агромастер» компаниясенең иң киң кулланыштагы техника төрләреннән берсе булып тора. Аны аеруча Волгоград, Саратов, Ростов өлкәләрендә яраталар, Башкортостанда һәм Оренбург өлкәсендә дә сатып алучылар күп.

Уртача авырлыктагы Tillermaster культиваторы чәчү алдыннан барлык төр туфракны һәм пар басуын эшкәртү, шулай ук язгы дымны ябу өчен эшләнгән. Нигездә алдан эшкәртелгән туфракта кулланыла. Бер үтеп киткәндә үк культивацияли, орлык тирәсен тыгызлый, чүп үләннәрен кисә, өске катламның мүлчәләнүен һәм туфракның нәтиҗәле тигезләнүен тәэмин итә. 16 метрга кадәр киңлекне колачлап бару чәчү һәм эшкәртү вакытын берничә тапкыр кыскартырга мөмкинлек бирә.

Культиваторда пружиналы зигзагсыман тәрәкләргә беркетелгән уксыман яргычлар көйләнгән, агрегат берәр нәрсә өстенә килеп кергәндә, бу тәрәкләр бөкләнергә сәләтле. Яргычлар һәм тәрәкләр – Испаниянең Bellota фирмасыныкы. Эшкәртү мәйданын йөз процент колачлап барганга күрә, яргычлар чүп үләннәренең мөмкин кадәр тулы киселүен тәэмин итә. Фермер теләге нигезендә культиватор өч яки дүрт рәт яргычлы итеп җитештерелә. Дүрт рәттән гыйбарәт конструкция яргычларга үсемлек калдыклары тыгылуны сизелерлек киметергә мөмкинлек бирә.

Катоклар кантарларның яхшы таралуын һәм вакланувын тәэмин итә. Эшкәртү һәм эретеп ябыштыру өчен югары технологияле җиһазлар һәм сыйфатлы металл куллану бәрабәренә культиватор конструкциясенең чыдамлылык запасы бик зур. Агрегаттан файдалану һәм аңа хезмәт күрсәтү гаять уңайлы.

Шуны истә тотарга кирәк: һәр агрегатның үз вазыйфасы, үз максаты бар. Шуңа күрә камыллы, урылган кырга тиз йөрешле культиваторлар белән керергә ярамый, чөнки бу хата нәтиҗәдә агрегатның ватылуына китерергә мөмкин. Әгәр хуҗалыкка урылган кырны эшкәртергә кирәк икән, әүвәл дисклы корал белән йөреп, җирне йомшартырга, коелган орлыкларны туфрак белән бутап, аның келәмдәй тигез булып шытып чыкканын көтәргә мөмкин. Шуннан соң инде аны парналау культиваторы белән ваклап-кисеп, кырны тигезләп чыгарга була.

AGROMASTER
www.pk-agromaster.ru
8 (85556) 2-39-08
8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru
Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай ур., 33а

Фото «Агромастер» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

* 2022 елның 2 кварталы нәтиҗәләре буенча
** Тиллермастер

КОРРОЗИЯГӘ – КАРШЫ! ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ ЯКЛЫ!

Бөгелмәдәге «Инженер-җитештерү үзәге» компаниясе агрессив мохит йогынтысыннан торбаүткәргечләрне саклауның инновацияле ысулын уйлап табучы буларак билгеле. Завод җитештерә торган продукция инде күптәннән базарның әлеге сегментында иң ышанычлыларның берсе булып танылды, аны «Газпром», «Лукойл», «Татнефть», «Роснефть» кебек зур компанияләр сайлый.

Утыз еллар элек компаниягә РФ атказанган уйлап табучысы Вячеслав Айдуганов нигез сала. Бүген гаилә бизнесы белән аның кызы Ольга Айдуганова җитәкчелек итә. ИҖҮнең төп эш юнәлеше – торбаларны тышкы һәм эчке коррозиядән саклау. Торбаларның күгәрүе техноген характердагы һәлакәтләргә китерергә мөмкин, чөнки торба шул исәптән нефтьне озату өчен дә кулланыла.

– Безнең игътибар үзәгендә – агрессив мохиттә куллану сәбәпле күгәрергә, черергә сәләтле торбаүткәргечләр, өстәвенә, торба эчендә нефть, газ гына түгел, су да була ала, ә анда металл өчен шактый зарарлы өстәлмәләр булырга мөмкин, – дип сөйли **үзәкнең директоры Ольга Айдуганова.** –

Шуңа күрә безнең полиэтилен белән футерацияләнгән корыч торбаүткәргечләр нефтьчеләр һәм газчылар эшендә генә түгел, төрле тармакларда, шул исәптән ТЭЦ, азык-төлек сәнәгатендә, коммуналь хуҗалыкта, аэропорт, метро, тимер юл ягулык үткәргечләре һ.б.ларда кулланыла ала.

КУЛЛАНУ СРОГЫ КҮПКӘ АРТА

Бөгелмә компаниясе җитештерә торган торбаларның ышанычлылыгы вакыт белән расланган. Әйтик, 2016 елда Инженер-җитештерү үзәге «ТАНЭКО» өчен полиэтилен белән футерацияләнгән корыч торбаүткәргечләр җитештерә. Аларның сыйфатына карата бүгенгә кадәр берninди дә шелтә белдерелгәне юк! Алай гына түгел, мондый торбалар бәясе күгәрми торган металлдан эшләнгәненә караганда дүрт мәртәбәгә арзанрак чыга.

Заводның үзендә дә «фирма» торбаүткәргече эшли. Ул монда 2007 елдан бирле кулланышта, һәм хәзергә кадәр бер генә өзеклек тә булганы юк. Әлеге суүткәргечкә шәһәр районына караган тагын бер торба өстәп тоташтырылган. Шулай ук бернинди проблемаларсыз эшли!

ТӨЛКЕ БАЛАСЫ ҺӘМ БОЛАН МҮГЕНЕҢ МОНДА НИ КАТНАШЫ БАР?

– Предприятиебезнең миссиясе – киләчәкне саклый торган технологияләр эшләү. Безнең югары технологияле продуктларыбыз әйләнә-тирә мохит турында кайгыртуны, табигатьне тискәре йогынтыдан саклауны күздә тотып эшләнгән. Төлке баласы – компаниябезнең символы, һәм ул безнең миссияне, табигатькә, туган җиргә, шәһәргә, кешеләргә сак мөнәсәбәтебезне чагылдыра.

Без баштан ук үзебезне әйләнә-тирә мохитнең торышына битараф булмаган предприятие итеп таныттык, һәм хәзер дә бу мөнәсәбәтебез үзгәрешсез кала бирә.

ИҖҮ җитештергән торбаүткәргечләр озак һәм аварияләрсез эшләргә сәләтле, шуңа күрә экологияне саклый. Әлбәттә, торбаүткәргечләрне сузганда туфрак катламын бозу котылгысыз, ләкин вакыт узу белән, экосистема торгызыла. Әгәр инде торбаүткәргеч сыйфатсыз икән, бу тулы бер һәлакәткә китерергә мөмкин, чөнки торбаны өскә күтәрергә, димәк, тагын терек табигатькә зыян китерергә туры киләчәк.

Хәзер исә болан мүге турында. Ул Көнбатыш Себер экосистемасының нигезе, туфракны ныгыта, боланнар өчен ризык булып тора. Һәм 2006–2007 елларда компания җитештергән торбаүткәргечләр анда да салына. Алар хәзергә кадәр кулланышта, димәк, туфрак иске торбаларны ремонтлау яисә яңаларын сузудан зыян күрми. Мүк тә үсә, боланнар да тук!

Компания эшләгән технологияләрне куллану, туфракның өске катламын саклап калу белән бергә, газ һәм нефть түгелүгә юл куймыйча, табигатькә зыян китерүдән дә коткара.

– «ИҖҮ» ҖЧҖ ПРОДУКЦИЯСЕ **«РОССИЯНЕҢ ИҢ ЯХШЫ 100 ТОВАРЫ»** ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРӘ.

– «ИҖҮ» ҖЧҖ **«РФНЕҢ 100 ГАИЛӘ КОМПАНИЯСЕ»** ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРӘ.

– КОМПАНИЯ **«БӨТЕНРОССИЯ СӘНӘГАТЬ ТУРИЗМЫ АКСЕЛЕРАТОРЫ»** ӘГЪЗАСЫ БУЛЫП ТОРА.

ИПЦ

«Инженер-җитештерү үзәге» ҖЧҖ

тел.: 8 (800) 551-59-55

ТР, Бөгелмә ш., Гончаров ур., 12

Фотолар Ольга Айдуганова алынды. РЕКЛАМА

акыллы
гамәлләр
игелекле
мәңгелек
кыйммәтләр
эшләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Леонид Мачтаков Зәй ГРЭС **ничек** төзегән

Сәмра Бикмиева **ничек** яшерен мәгълүматлар тапкан

Ришат Хәлиуллин **кайда** юлсызлык белән көрәшкән

Татарстан Сочины **нәрсә** белән әсир итте

Сүзлекләр **ничек** туа

Зәй ГРЭСы. 1973 ел.

86 нчы көчәйтелгән аерым медицина хезмәте ротасы. 1945 ел.

Саескан Тавы янында Кама елгасы аша күпер.
Төзелешнең тәмамлануы. 2002 ел.

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп, бу буын кешеләре алга атлаган, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылган. Алар юллар төзегән, күперләр сузган, электростанцияләр, заводлар салган, яу кырларында ватанны саклаган, сугыштан соң илне күтәргән. Бүген әлеге фидакарь буынга – бер гасыр. Уртача алганда. Кемгәдер гасырлык юбилейга кадәр ике-өч ел калган. Кемдер аны якын көннәрдә билгеләп үткән. Кемдер исә юбилеен берничә ел элек бәйрәм иткән. Кемдер әле бөтенләй яшь – сигезенче дистәне генә ваклый...

«Татарстан», үзенең каһарман якташлары белән очрашып, аларның маҗаралар тулы тормыш юлы турында сезгә дә сөйләргә булды.

1 нче ТАРИХ
Леонид Мачтаков ничек Зәй ГРЭСын төзегән

2 нче ТАРИХ
Сәмра Бикмиева ничек яшерен мәгълүматларны тапкан

3 нче ТАРИХ
Ришат Хәлиуллин ничек Әлки районын асфальтлы иткән

Фотолар махсус проектта катнашучыларның шәхси архивларыннан

PRESSA

1 НЧЕ ТАРИХ

ЗӘЙ ГРЭСЫНДА – ТӘҮГЕ КӨННӘН БАШЛАП

Зәй ГРЭСындагы тәүге төзүчеләрдән берсе, Татарстанның иң өлкән энергетигы Леонид Яковлевич Мачтаков август аенда 99 яшьлеген билгеләп үтте.

Ул бөек тормыш юлы уза. Мәскәү, Сталинград янында, Курск дугасында сугыша, Днепрны кичә, Украина, Молдавия, Румыния, Болгария һәм Югославияне азат итә. Аның күкрәген сугышчан орден-медальләр бизи.

Леонид Яковлевичның тыныч тормыштагы бөтен гомере диярлек Зәй ГРЭСына багышланган. Ул «Почет Билгесе» ордены иясе.

– Зәй минем туган ягым, мин шушы районда тудым, – дип сөйли Леонид Яковлевич. – Станция төзелешенә 1954 елда килдем. Проектлауда катнаштым, төзедем... Инженердан капиталь төзелеш бүлеге җитәкчесенә кадәр хезмәт юлы үттем.

110 ЭШЕЛОН ҖИҺАЗ

Зур төзелешләр турында сез нәрсә беләсез? Ә Леонид Яковлевич барысын да белә!

– Төзелеш ул чакта яңа подрядлы ысул белән алып барылды, – дип искә ала Леонид Яковлевич. – Подрядлы ысул, техник документлар белән тәэмин итү, объектны кабул итү – асылда, канцелярия эше, әмма ул аеруча төгәллек, ваклык, белем, абсолют пөхтәлек таләп итә. Иң зур эш – җиһазларны комплектацияләү. Проектлаучыларга кирәкле җиһазлар исемлегенә заказ бирергә кирәк. Ә алар калын томнарны тәшкил итә – һәр заводныкы булырга тиеш, ә тәэмин итүче заводлар илледән артык. Килешүләргә исә таләп ителгән стандартларны, шартларны өстәп язып куярга кирәк. Аннары җиһазларны кабул итеп аласы, бушатасы, җитештерүче завод күрсәтмәләрен үтәп саклыйсы бар. Күпме җиһаз кабул итәргә кирәк! Бер пар казаны гына да 110 эшелонлык җиһаздан гыйбарәт, һәр эшелонда – 50шәр вагон... Күз алдына китерәсезме?! Аннары – монтаждан соң кабул итү... Хәзер моның өчен тулы бер идарә тотарга кирәк. Ул чакта ник җиңелрәк башкарыла иде? – ди Леонид Яковлевич һәм уңышлы эшнең төп серен ачып бирә. – Килештерү процессында беркайда да, бернинди дә бюрократик киртәләр кормадылар. Бөтен җирдә дә юл ачык иде!

УЗГАН ГАСЫР ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Зәй ГРЭСы проекты яңа техник алымнар кулланылуы белән кызыклы була. Төп корпусның каркасы беренче тапкыр җыелма тимер-бетоннан төзелә. Ә бина нигезе беренче тапкыр монолит тимер-бетоннан ясала. Бу исә янгыннан саклауның тагын да югарырак дәрәҗәсе дигән сүз.

Фото: Александр Ефремов, zainsk-inform.ru

– Без КАМАЗда кулланыла торган пыяла кую ысулына тукталдык. Ул ышанычлырак, тизрәк көйләнә, ныклырак та, – дип аңлата Леонид Яковлевич.

Шактый сизелерлек экономия биргән башка эшләр дә була. Аерым алганда, Зәй елгасы ярын ныгыту һәм аны бүлеп кую.

– Без хәрби суднолар өчен бояу җитештерә торган хәрби-диңгез флоты заводын эзләп таптык. Әнә шул «ВН-20» буявы белән төп корпусның бөтен фасадын буяп чыктык та.

МИНИСТР ИДЕЯМӘ ФАТИХА БИРДЕ

Леонид Яковлевич үзенең Зәй елгасын бүлеп кую турында рационализаторлык идеясенә 1961 елда СССР энергетика министры Непорожнийның шәхсән фатиха бирүе турында искә алырга ярата. Әлеге тәкъдимне кертүдән икътисадый файда 186 мең сум тәшкил иткән.

– Непорожний килде дә сорауны кабыргасы белән куйды, – дип искә ала Мачтаков. – «Тимербетон плотинагыз вакытында әзер булачакмы?»

Әле яңа гына плотина нигезе өчен чокыр казый башлаган чак, эшнең очы-кырые юк, рәсми кабул ителгән технологиягә ябышып ятсак – бигрәк тә.

Шул ук вакытта без станция янындагы торбаүткәргечләрне сала идек. Шулчак башыма бер идея килде! Эш шунда ки, станция яны узелын без тоннельләрнең тимер-бетон секцияләреннән ясый идек. Киңлеге – ике, биеклеге дүрт метрлык тартма рәвешендәге ул секцияләрне безнең сызымнар буенча Тольятти җитештерде. Ничә тартмага заказ бирелгәнен ачыклау өчен, техник бүлеккә кердем. Тагын илле тартма турында килешеп буламы, дип сораштым. Алар аны бик тиз эшли, була, диделәр. Мин Тольяттидагы заводка барып кайттым. Проблема булмаячак, дип ышандырдылар мине анда да.

Менә шуннан соң Гидропроектның баш проектлаучысы Маковка тәкъдим ясадым: әйдәгез, минәйтәм, Зәй янәшәсендә шушы тартмаларны тезеп чыгабыз, 100 метрлык тоннель булачак. Зәйдән зур канау казыйбыз, берәр дистә МАЗны шунда бирик, алар бер көн эчендә Зәйне таш белән күмеп куячак, шулай итеп елганы тоннельгә җибәрәбез дә дамбаны өя башлыйбыз. Ул вакытта без станцияне графикта каралганча, 1962 елда эшләтеп җибәрергә өлгерәбез.

«Менә Непорожний килсен дә, аңа сөйләп бирерсең, әгәр ул ризалык бирсә, синеңчә булыр!» – диде Маков.

Непорожнийның чираттагы сәфәре вакытында тәкъдимемне җиткердем, ә ул: «Дөрес карар, кичекмәстән эшкә керешегез!» – димәсенме!

Төзелеш чорында дистәдән артык рационализаторлык тәкъдимем гамәлгә ашырылды.

ҮЗЕҢ ТӨЗЕ!

Планнарның зурлыгы еш кына аларны тормышка ашыручыларның көнүзәк ихтыяҗларын исәпкә алмый. Зәй ГРЭСы төзелешендә тир түгүчеләргә дә, станцияне эшләтеп җибәрүчеләргә дә бернинди уңайлылыклар та каралмый, газ да, кайнар су да, гомумән, яшәрлек торак та юк.

Торак мәсьәләсе белән нишләргә?

– Бу сорау көтелмәгән рәвештә чишелеш тапты, – дип искә ала Леонид Яковлевич. – Бервакыт бүлеккә керүемә, хезмәткәрләр «Известия» газетасыннан Горький автомобиль заводының «самстрой» ысулы белән торак төзи башлавы турында мәкалә укып утыра. Фатир кирәкме – үзең төзе! Урынбасарым Сизов шул вакытта сүз уңаеннан гына сорау биреп куйды: нигә безгә дә шулай эшләмәскә?

> – КОМИССИЯ РӘИСЕ МИН, БЕР-БЕР НӘРСӘ КИЛЕП ЧЫКСА, ИҢ ӘҮВӘЛ **МИҢА ТӨЕНЧЕКЛӘРНЕ ТӨЙНӘРГӘ ТУРЫ КИЛӘЧӘК ИДЕ.**

Ул вакытта генераль подрядчыбыз «Камгэсэнергострой» иде. Предприятие торак төзелеше планын ел саен үти алмый кала, чөнки аның өчен бу – икенчел әһәмияткә ия юнәлеш, беренчесе, мөһиме – Түбән Кама ГЭСын төзү.

Мин төзелеш җитәкчесе Аркадий Эгенбургка предприятиесенең торак планын ничек үтәп, һич тә артык булмаган премияне ничек ала алачагын аңлатып бирдем. Сез безгә кирпеч, кран, измә бирәсез, минәйтәм, ә кешеләрне үзебез өйрәтербез. Алар иң яхшы төзүчеләр булып чыкты!

Нәтиҗәдә, «самстрой» методы белән без 20 йорт төзеп чыктык һәм җитешмәгән 600 фатир проблемасын хәл иттек. Бу йортларда хәзер дә яшиләр!

«БИШЛЕ»ЛЕК ГРЭС

...1976 елда 26 кешедән торган дәүләт кабул итү комиссиясе Зәй ГРЭСы буенча документацияне, җиһазларның торышын өч ай өйрәнә һәм станцияне даими рәвештә сәнәгатьтә файдалануга рөхсәт бирә. «Бишле» билгесе белән! СССРда шундый югары бәя белән куллануга тапшырылган бердәнбер станция була ул!

– Менә 50 ел үтте, һәм мондый бәяләмә ГРЭСның авариясез һәм экономияле эше белән тулысынча расланды, – ди Леонид Яковлевич. – Комиссия каршына шундый куәтле станцияне китереп бастырганчы, төзүчеләрнең, монтажчыларның, эксплуатациячеләрнең, коллегаларымның искиткеч зур хезмәтне ничек башкарып чыга алганына мин хәзер дә гаҗәпләнүдән туктамыйм. Комиссия вәкилләре тикшереп йөрделәр, метрын да үлчәделәр, нивелир белән дә карадылар... Һәр башкарылган эш өчен акт тутырылырга тиеш. 500 томлык шундый актларны кабул итү комиссиясенә тоттырдым. Комиссия рәисе мин, бер-бер нәрсә килеп чыкса, иң әүвәл миңа төенчекләрне төйнәргә туры киләчәк иде. Без, әлбәттә, «бишле» көтмәгән идек, «яхшы» билгесе куйсалар ярый әле, дип уйладык...

Ә 1975 елда, Бөек Җиңүнең 30 еллыгына, «Азатлык алып килүче сугышчы» һәйкәле өчен Зәй диплом белән бүләкләнә.
– Бу һәйкәлгә мин заказ бирдем, – ди Леонид Яковлевич, горурланып. – Скульптор Виктор Рогожиннан сугышчыны «Освобождение» киноэпопеясе герое образында сурәтләвен үтендем – ул каһарманның килешкилбәте бик истә кала торган, характерлы! 2021 елда исә һәйкәл яңартылган.

2 НЧЕ ТАРИХ

«ЧИБӘРКӘЙ» СЕРЕҢ АЧА

Фото Сәмра Бикмиеваның гаилә архивыннан алынды.

Хатын-кыздан яшен сорау килешми. Әмма Сәмра Сабир кызы Бикмиева яшен яшерми – аңа инде 101 тулган. Сәмра апаның гасырлык юбилеена Президент үзе килгән. Котлап, аның тормышы турындагы истәлекләрне, заманча итеп әйткәндә, сторителлингларны тыңлаган. Йөз ел эчендә тупланган хатирәләр барысы бергә зур бер тарихка – 86 нчы аерым медицина ротасының медицина хезмәте кече лейтенанты, Казан госпитале шәфкать туташы һәм совет тышкы разведкасының «Чибәркәй» кушаматлы разведчигының тормыш бәянына әйләнгән.

Сәмра апа гомеренең төп серен йөз яшенә кадәр «яшерен» дигән мөһер астында бикләп саклаган. Аннары көтмәгәндә аны ачарга булган. 18 октябрьдә «Китап Club» рестораныңда «Красивая» китабын тәкъдим итү кичәсе узачак, «Татарстан» анда яшеренгән кайбер серләрне ача.

ИЛЕННӘН СӨРЕЛГӘН

...Хәтергә уелып калган: 1947 елда, Чехословакиядә, тарихта соңыннан «сөрелгән президент» дип аталачак Эдвард Бенеш, Сәмраның бу илдән китәр вакыты җиткәч, аңа үзе язган шигырьне укый, ә андагы һәр куплетта «красна» (матур кыз, чибәркәй) дигән сүзне телгә ала. Сәмрага кал дип ялвара, күп нәрсәләр вәгъдә итә... Һай, ул президентлар!..

...Һуштан яздырырлык чибәр ир-ат булган Эдвардны искә төшерде ул. Президентлар андый матур булырга тиеш түгел, алтмыш яшьнең аръягына чыккач бигрәк тә. Бу аларның карьерасына зыян салырга мөмкин.

Сәмра өчен ул артык укымышлы зат була. Моны кыз шунда ук тоя, чөнки үзе Казан акушерлык мәктәбен генә тәмамлаган бит... Эдвард Бенеш исә өч университетлык белем багажына ия: Прагадагы – Карл, Париждагы Сорбонна университеты һәм Франциядәге Дижон университетының юридик факультеты. Чехлар һәм словаклар илендә бай крестьян улы Эдвардның андый белем алу хәленнән килә.

Сәмра, аның белән дөньяви әңгәмә корып, төрле илләрдә төрле буын кешеләре өчен белем алу мөмкинлекләре төрле булуын аңлый. Ләкин аның туган авылы Черки-Килдураздан беркем дә университетларга керә алмаган шул. Ә аларның – СССРда сәяси террор корбаны булган Бикмиевләр гаиләсенең – югары белем төшлә-

ренә дә керә алмый. Укырга дип авылдан Казанга чыгып качканда, ул бит үзе дә бер авыз сүз русча белми…

Хәзер менә Чехословакия президенты белән словак телендә сөйләшә. Җиңел генә чех теленә күчеп китә. Кирәге чыкса – инглизчәгә дә. Немец телен дә, рус теле кебек үк, камил белә. Телләргә аны бернинди университетларсыз гына иптәшләр өйрәтә...

...Чехословакия бәйсезлеген югалтыр дип курыккан Бенешның 1938 елда Советлар Союзыннан хәрби ярдәм кабул итүгә каршы чыгуын бу иптәшләр хәтерли әле. Ә инде 1943 елда Советлар Союзы белән Чехословакия арасында дуслык турында килешүгә кул куйса да, сугыштан соң Бенеш янына үзләренең «Чибәркәй» кушаматлы иң яхшы агентын җибәреп, совет разведкасы саклык чарасын күрергә ниятли.

Ул вакытта Сәмрага – 26, Эдвардка 62 яшь була. Яшьләре көзгедән караган кебек. Утны-суны кичкән ирнең тормышы күпкырлы: анда тышкы һәм эчке сәясәт тә мулдан; сөргенлек һәм эмиграциядәге тормыш та, нацизм белән көрәш тә, ике бөтендөнья сугышы да һәм... нәфис йөзле, шәрык халыкларына хас кысыграк күзләреннән очкын сибелеп торган чибәр кыз да бар.

Чирек гасырлык гомерендә Сәмра да күпне күрә: «халык дошманы кызы» келәймәсе сугылган балачак, ярлылык һәм ачлык, сугыш һәм кан, ирен һәм баласын югалту... Һәм якты дөньядан ваз кичеп йөргән чакта аны сайлап алган һәм коткарып калган эш. Шул эш Сәмраны, читләр язмышына килеп кереп, дөньяның берсеннән-берсе куәтле затларын, аларны соңыннан фаш итү өчен үзенә гашыйк иттереп, яшерен рәвештә төрле рольләр уйнарга өйрәтә дә инде.

– Мин кешеләрне әләкләп капкынга каптыру өчен күзәтергә теләмәдем, – дип күңелен ача Сәмра. – Әләкчелек һәм шпион булу совет кешесенә ят иде. Чын совет кешесе турында әйтүем, мин аерым бер затларны күздә тотмыйм. Максатым – нинди дер мәгълүмат алу гына түгел, ә кешене, киләчәктә ихтимал булган куркыныч нәтиҗәләрдән йолып алып, кирәкле юлга кертеп җибәрү иде.

ВАКЫТЛЫ ИЛБАШЫ

1948 елда ул Румыния президенты Константин Йон Пархон белән таныша. Бу вакытта Сәмрага Милена исеме бирелә.

Сәмра елмаеп җибәрә. Бу яңа исем аңа ошый. Һәм Константинның бу исемне ничек әйтүе дә. Аның көчле ихтыяр билгесе булган ияге бу вакытта йомшап, мескенләнеп кала, ә тәвәккәл карашы назланып китә. Милена янында булмаганда, ул бөтенләй башка – принципиаль һәм тәкәббер зат – чын Кымпулунг румыны. Сәмра-Милена мондый үзгәрешләрне ярата: курку белмәс һәм башимәс затларга ул бик җиңел генә кешелеклелек сыйфатларын кире кайтара. Соңыннан исә мәхәббәтле карашларга, җылы елмаюларга, назлы кагылуларга үзе дә соклана... Ир-атлар үзләренә җәлеп итә торган һәм кеше өчен табигый булган сыйфатларны нигә яшерәләрдер?

Ир-ат холкындагы масаючанлык Милена госпитальдә аның аягын тездән шактый югарырак урында бәйләгән чакта юкка чыга. Үзе табиб, эндокринология профессоры булган, үзен шундый кыю ир итеп күрсәткән Константинның төрле хирургик тыкшынулардан коты оча. Сугыш кичкән Милена исә бернәрсәдән дә курыкмый. Еш кына бомбалар шартлап ярылганда, кайчак күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгылыкта аның куллары ярадан җитез генә пуляны тартып чыгарган да, шулкадәр уңайлы итеп бинтланган ки, наркозсыз операцияләр белән тәмам җәфаланган солдатлар, кызның йомшак кагылуына изрәп, яраларын бәйләгән чакта ук йоклап киткәләгән. Румыния госпиталендә ярасын моңа кадәр ватандашлары бәйләгән Константин да, бу аерманы шундук сизеп, поляк шәфкать туташына гашыйк була. Миленаны ул поляк кызы дип уйлый. Бу юлы кызга әнә шундый легенда уйлап табыла. Әлеге уйдырма тарих белән бергә Үзәк тарафыннан бурычлар да куела – тикшерергә һәм мәгълүматны сорашып белешергә. Һәм кыз белешә дә. Бернәрсәгә дә үкенми ул. Хәтта Константинның ирене калтыраганын күргәч тә үкенми. Миленаның аны чынлыкта ни өчен «яратканын» аңлаганнан соң, үпкәләүдән калтырануның аның көчле ихтыярлы иягенә күчүен күргәч тә, үкенү тоймый Сәмра.

> ...ҺӘР ЗАМАННЫҢ ҮЗ КЫЕНЛЫКЛАРЫ БАР. КАЙВАКЫТ АЛАР АРТЫК АВЫР БУЛА. ҺИЧ ҖИҢЕП БУЛМАС КЕБЕК ТОЕЛА. **ӘММА АХЫР ЧИКТӘ АЛАРЫ ДА АРТТА КАЛА.**

Константинга китергән газаплары өчен үкенәме ул? Юк. Милена гомере буе бер генә нәрсә – тумаган улы һәм һәлак булган ире өчен генә үкенү хисе кичерә. Өйгә кайту турында гына хыяллана Сәмра. Аның соңгы күрсәтмәне генә үтисе кала, шуннан соң ул туган ягына кайтып китәчәк. 1941 елда сугыш башланганнан бирле, аның өйгә кайтканы юк лабаса. Әтисен күрәсе, сугыш йоткан абыйларын сагынып, сеңлесе белән кочаклашып елап аласы килә.

11 елдан соң, 1959 елның октябрендә, аны Константин Пархонга Ленин ордены тапшыру тантанасына чакыралар. Константин бу югары бүләкнең тулысынча Сәмра-Миленаның тырышлыгы икәнен аңлый. Румыниянең вакытлы президенты турында үзе ачыклаган мәгълүматны Сәмра-Милена отчетларына язмый калдырган шул. Шуңа күрә Пархон чакыруны шәхсән үзе имзалый. Зур итеп сырланган автограф янында ап-ачык итеп кулдан язып өстәп тә куя: ești frumoasă (син чибәр).

Ләкин Сәмра тантанага барып тормый. Ул чакта инде Пархон Үзәкне кызыксындырмый. Димәк, кызга да кирәк булмый.



З НЧЕ ТАРИХ

ОЛЫ ЮЛНЫҢ ТУЗАНЫ...

Руфия Фазылова

«...Алтмыш яшемдә йөри алмас булдым. Арка миенә зыян килеп ике ай урын өстендә яттым. Бер ай Республика клиник хастаханәсендә дәваландым. Анда арка миемне тарттырдылар. Өйгә кайтканда аякта йөрми идем әле. Рухи яктан бу халәтне бик авыр кичердем. Башка начар уйлар килә: шулай гарип калырмынмы? Ләкин бермәл үземне кулга алдым: болай ятып торудан файда юк, үземә шөгыльләнергә кирәк...

Балаларга култык таяклары алып кайтырга куштым. Өйдәгеләр эшкә китүгә, урынымнан акрын гына торам да култык таякларына тотынып басам. Арка миенә зыян килмәсен дип, бөтен көчне култык таягына бирәм. Бер минуттан артык торып булмый, яңадан урынга авам. Азрак ял итәм дә яңадан торам. Аркам авырта, сызлый, ләкин түзәм, чөнки башкача мөмкин түгеллеген аңлыйм. Басып тору вакытын көн саен шулай секундлап арттырам. Атна-ун көн шулай шөгыльләнгәч, бер адым атлап карадым. Булды. Икенче көнне тагын берне... Үзем сөенәм, үзем Аллаһка рәхмәт укыйм! Шуннан акрын гына өстәл янына килә башладым. Бу турыда өйдәгеләргә ләм-мим, сюрприз булсын, дим. Кичен гаиләм ашарга әзерләнеп йөргәндә таякларым белән аш бүлмәсенә килеп чыктым. Шаккаттылар! Хатынның күзләре яшьләнде. Мин көлеп җибәрдем: «Нәрсә, Ришат абыегыз гел шулай ятар дип уйладыгызмы?» - дидем».

КӨНГӘ ИЛЛЕ ЧАКРЫМ ҖӘЯҮ

Ришат Хәлиуллинга 1 мартта 76 яшь тулган. Алты елдан бирле Әлки ветераннар советын җитәкли ул. Көн саен яраткан эшенә бара: лаеклы ялга чыккан кешеләрнең гозерләрен тыңлый, хәлдән килгәнчә ярдәм итә. Район администрациясе вәкилләре белән өлкән яшьтәге юбилярны котлап өйләргә йөри. Моннан тыш, район күләмендә төрле чаралар үткәрәләр. Кыскасы, гомер буе тик тормаган Ришат Әсәт улы бүген дә тынгысыз тормыш белән яши. Тумышы белән Әлки районының Карамалы авылыннан ул. Белеме буенча – укытучы.

– Җиде сыйныфны тәмамлагач, Нурлат районының Күлбай Мораса мәктәбендә укыдык, – дип сүз башлады Әлки районы ветераннар советы рәисе. – Биш чакрым ераклыктагы мәктәптә урта белем алдым. Яз-көз муеннан пычрак ерып йөрдек. Ә кышкы салкыннарда мәктәпнең интернатында яшәдек. Укытучылар: «Бу пычракта азапланып йөрмәгез, монда гына калыгыз», – дисәләр дә, ничек тә өйгә кайту ягын карадык.

Фото: Александр Ефремов

Күлбай Мораса ярар әле, район үзәге Базарлы Матакка да җәяү барып, җәяү кайта идек. Бер ягы гына егерме биш чакрым. Көнендә барасың, көнендә кайтасың, илле чакрым дигән сүз. Әле бит пычрак ерып йөрисең...

Үсмер малай шул чагында еш уйлый: кайчан булса да ул яшәгән районда юл салынырмы икән? Алай-болай юл төзи башласалар, беренче булып барыр иде, чөнки бу – үзәгенә үткән проблема.

АТ КӨЧЕ БЕЛӘН...

Ришат Хәлиуллин белеме буенча укытучы, дидек. Сайлаган һөнәренә тугры калып, мәктәптә дә эшләгән, район мәгариф бүлеген дә җитәкләгән. Ә 1988 елдан Әлки районы башкарма комитеты рәисенең гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары булган. Районның коммуналь хуҗалыгы, юл төзелеше – дистә елдан артык Ришат абый барысын да контрольдә тоткан.

– Татарстан буенча һәр районда юл төзелеше оешмалары бар иде, сугыштан соң, 1955нче елларда оешкан алар, – ди әңгәмәдәшем. – Мин килгәндә, ул районның юл төзү участогы дип атала иде. Заманасына күрә шактый зур оешма: берничә техникасы бар. Төп көч – чылбырлы трактор, бульдозерлар. Кызык чаклар: асфальт сала торган җайланманы ДТ тракторы тартып йөри.

Ришат Әсәт улы әле ат белән юл салган чакларны да хәтерли. Юл салу өчен, ат арбасына төяп карьердан таш ташыганнар. Дөрес, яшь булганлыктан аларга бу авыр физик эш тәэсир итмәгән, тик олы юлга дамба өеп, шуңа таш түшәгән вакытларны яхшы хәтерли ул.

1959 елда ТР Югары Советы Президиумының карары чыга – ел саен юл төзү буенча ике айлыклар оештырырга. Менә шул ике айлыкның планын алдан төзеп, колхоз-совхозларга тараталар. Ул инде авылда кеше санына, атлар санына карап бирелә.

– Әлеге карардан соң илебездә юллар салына башлады, шул исәптән Татарстанда да, – дип дәвам итә Ришат Әсәт улы. – Безнең Әлки районында беренче күтәрелгән юл Ульяновск ягына таба була. Мин моның сәбәбен шунда күрәм: Ульяновск өлкәсендә Бряндино дип аталган тимер юл станциясе бар. Безнең районга дигән бөтен төзелеш материаллары шунда кайткан. Шуның өчен дә иң беренче ул якны караганнар.

1970 нче елларда Ульяновск ягына бара торган дамба ундүрт чакрым гына ясала да туктап кала. Шуннан Әлки белән Нурлат районын тоташтыра башлыйлар, чөнки колхозларга дигән төзелеш материаллары Нурлат станциясенә кайтарыла.

– 1980 нче елларга кадәр юл төзелеше бик зур авырлыклар белән барды, – ди Ришат Әсәт улы. – Ул чорда юлларны хәзерге кебек фәлән километр салмадылар, чөнки техника юк, вакыты да кысан. Ике ай эчендә нәрсә генә эшли аласың? (Гадәттә, ике айлыклар чәчүләр беткәч, май-июнь айларында узган).

Мин эшләгән чорда хәл бик үзгәргән иде инде. 1992 елга кадәр колхоз белән бергә авылларга таш җәелгән юллар күтәрдек.

БӘХЕТ БАСУ

1983 елда Әлки районында асфальт заводы төзелә. Бу инде заман өчен чын алга китеш була. Бер елдан соң Базарлы Матак–Казан юнәлешендә өч чакрым озынлыктагы асфальт юл салына. Кешеләр бу күренешне килеп-килеп карый. Могҗиза бит! Район җирендә асфальт булсын әле! Ата-баба күргән хәл түгел бу!

– 1990 елда ТР Министрлар Кабинетының карары чыкты – барлык районнарны бер-берсе белән асфальт юл тоташтырырга тиеш, – дип дәвам итә Ришат Әсәт улы. – Без менә шушы карарны тулысынча үтәдек: Әлки, Спас, Нурлат районнарын үзара асфальт юл белән тоташтырдык. Яшермим, ул чорда технологиясе бүтән иде, салынган юлның сыйфаты бик яхшы булмады. Нәтиҗәдә, ел саен диярлек юлны ремонтлап торырга кирәк. Монысы тагын бер эш, тагын чыгым.

КҮҢЕЛЕҢ ЯШЬ БУЛСА, ПАСПОРТТА ЯЗЫЛГАН ЕЛ БЕРНӘРСӘ ТҮГЕЛ ИКӘН. АНЫҢ ТУРЫНДА УЙЛАРГА КИРӘКМИ. ЙОКЫДАН СӨЕНЕП ТОРЫРГА, ШӨКЕР ИТЕП ЯТАРГА КИРӘК.

Ришат Әсәт улының күңелендә тагын бер вакыйга уелып калган – Кама елгасы аша күпер ачылу. 2002 ел була ул. Бу якларда яшәүче халык өчен ул зур шатлыклы вакыйга дию генә аз, олы бәхеткә тиң була!

– Казанга урау юллардан барып, сигез сәгать вакытны уздыра идек, – ди әңгәмәдәшем. – Ә башкалага даими йөреп торасың, оешмалар белән эшләүче кеше буларак, документсыз бер кадак та ала алмыйсың. Күпер салынганнан соң безнең яклар икенче тормыш белән яши башлады. Икешәр тәүлек паром көтеп утырган халык «Казан» сүзеннән курыкмый башлады.

...Ришат абый җәмәгате Әминә апа белән бер кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Кызы Базарлы Матакта, улы Казанда яши. Икесенең дә гаиләләре бар, икешәр бала тәрбиялиләр. Гаилә башлыгы сигезенче дистәне вакласа да, һаман әле сафта. Машинасына утырып эшенә бара, аннан кайткач бакчада эшли. Дәү әни исә оныклар, балалар кайткан вакытка тәмле ризыклар әзерли, бабаеның өс-башын карап тора.

– Картаясы килми, – ди Ришат Әсәт улы. – Күңелең яшь булса, паспортта язылган ел бернәрсә түгел икән. Аның турында уйларга кирәкми. Йокыдан сөенеп торырга, шөкер итеп ятарга кирәк. Безнең чорга бик күп авырлыклар туры килде. Һәм без аларны җиңеп чыга алдык. Бүгенге яшьләр дә тормышның әче җилләренә каршы тора алыр, дип өметләнәм. Юк, мин моңа ышанам...

ЯРДӘМ – ЯНӘШӘДӘ

Төрле мәгълүматлардан күренгәнчә, һәр бишенче россияле теге яки бу дәрәҗәдә деменция күренеше белән очрашырга мәҗбүр. Әгәр әлеге бәла сезнең ишекне дә каккан икән, нишләргә? Проблеманы хәл итү юлларыннан берсе – өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидлар өчен тәгаенләнгән «Добрые истории» пансионатлар челтәренә ярдәм сорап мөрәҗәгать итү.

Күп китаптан сыгылып торган киштәне күз алдына китерегез әле. Җитмештән дә ким түгел, ә бәлки әле йөз дә бардыр. Кинәт бер китап идәнгә төшеп китә. Аның артыннан икенчесе, өченчесе оча... Һәм менә инде киштә бушап та кала яза.



Өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидларны тәрбияләү буенча белгеч, «Добрые истории» пансионатлар челтәре җитәкчесе Альбина Сергеева безнең гасырның иң куркыныч чирләреннән берсе турында аллегорияләргә таянып сөйли. Андагы китаплар – безнең хатирәләр, күнекмәләр, белем белән тулы гомер елларыбыз.

– Алар кеше хәтереннән җуела. Кайберәүләрнең сиксән яшьтә дә бер-ике китабы гына төшеп китә, икенче берәү исә буп-буш киштә белән калырга мөмкин – гадәти эйберләрне, якын кешеләрен генә түгел, хәтта үз-үзен дә танымый башлый.

ТАБАРГА ҺӘМ БУЛЫШЫРГА

Бүген «Добрые истории» пансионатында тәрбияләнүчеләрнең 80 процентка якынында деменция билгеләре бар. Асылда, деменция үзе дә ул – симптомнар җыелмасы; хәтер, фикерләү, көндәлек гамәлләрне башкару сәләте җуелу синдромы. Шунысын белү мөһим: деменция нигездә өлкәннәргә зыян салса да, картаюның нормаль халәте булып саналмый. Ә бусын белү тагын да мөһимрәк: авыруның көчәюен туктатып була. Моның өчен кирәкле шарт – якын кешеңдә деменция башлану билгеләрен вакытында күреп алу һәм аны тиешле дәва һәм тәрбия белән тәэмин итү.

– Кагыйдә буларак, безгә инде авыру шактый көчәйгәч кенә килеп эләгәләр, – дип сөйли Альбина Сергеева. – Сәбәбе гади. Безнең җәмгыятьтә картлык темасы һаман да тыелганнардан санала әле. Ә инде бүгенге көндә шәхси генә түгел, җитди дөньякүләм проблемага әйләнеп барган когнитив тайпылышлар турында безнең илдә әле күптән түгел генә ачыктан-ачык сөйли башладылар. Шунлыктан күпләр якыннарында авыру башлануын сизми дә кала – аның беренчел билгеләрен «картлык көйсезләнүләре» генә дип кабул итәләр.

– Пансионат темасы үзе дә алдан ук тискәре мөнәсәбәт белән өретелгән, – дип дәвам итә Альбина. – Әниеңне яки әбиеңне анда урнаштырасың икән, димәк, син аңа «хыянәт итәсең», димәк, син – начар кеше... Стереотип шундый. Шунлыктан деменциядән интегүчеләрнең туганнары безгә квалификацияле ярдәм сорап инде вазгыять түзеп булмаслыкка әйләнгәч кенә мөрәҗәгать итә. Әйтик, бу арада гына бер хатын-кыз шалтыратты: «Инде өч ай буе әниемне карап өйдә утырам. Ялгызын гына калдыра алмыйм – бик арыдым. Нишләргә инде хәзер миңа?» – ди. Шәхсән минем үзем өчен җавап бик гади – ярдәм сорап безгә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

КАРАП-ТӘРБИЯЛӘП ТОРУ МӘКТӘБЕ

Өлкән яшьтәге ир-ат ихтыярсыз аккан күз яшьләреннән оялмыйча елый. Әмма бу – шатлык яшьләре. «Мине әнием таныды бит бүген, беләсезме?!» – ди ул дулкынланган персоналның сораулы карашларына җавап итеп.

– Без үзебез дә сөенечтән елар хәлдә идек ул вакытта, – дип исенә төшерә Альбина Сергеева. – Шундый һәр очрак безне яхшыга өметләндерә һәм алга барырга көч бирә. Һәм бездә мондый гыйбрәтле тарихлар инде байтак – пансионатыбызның исеме җисеменә туры килә.

Әмма бирелгән һәр игелекле гамәл елмаюдан гына башланмый шул. Кайвакыт авыруның туганнары пансионатка ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәндә, ул инде чын агрессорга әйләнгән була. Альбина шундый бер тарихны исенә төшерде – ире хатынының дошманлыгыннан тәмам гаҗизлеккә төшкән, нишләргә белми аптыраган очрак бу.

– Бик авыр хәл иде, әмма безнең кайгырту бушка китмәде – ханымның

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

холкы күзгә күренеп үзгәрде. Без аны барыбыз да ярата башладык, – дип елмая Альбина Сергеева. – Дарулар белән дөрес дәвалау һәм тәрбияләү аның агрессиясен юкка чыгарды, авыруның хәлен җиңеләйтте. Ире таный алмады хәтта хәләлен.

Еш кына, үзләре дә сизмичә, туганнары авыруның хәлен үзләре авырайта. Вакытында табибка мөрәҗәгать итмиләр, мондый авырулы кешегә кирәкле социализация, ягъни аралашу белән тәэмин итә алмыйлар. Ябык фатирда утыру да хәлне мөшкелләтә, чирне көчәйтә генә, урамда йөрү проблемага әйләнә, әмма бикләнеп утырудан башка чара калмый.

– Мондый авыруларны тәрбияләү буенча белгечкә әйләнгәч, без халыкны агарту эшчәнлеген дә башларга булдык, – дип сөйли Альбина Сергеева. – Былтыр карап-тәрбияләп тору мәктәбе оештыруга грант оттык. Бүген теләгән һәр кеше безнең белгечләребезнең лекцияләрен пансионатның ютуб-каналында язмада карый ала. Без исә әлеге мөһим миссияне дәвам итәргә ниятлибез.

Белгечләр биргән белемнең барысын да пансионат хезмәткәрләре үзләре дә куллана. Яхшы өйрәтелгән хаста караучылар, терапевт, психиатрдан тыш, аның штатында культуролог та бар, ул авыруларның аралашуын һәм ялын оештыра. Рәсем ясау, әвәләү, гимнастика, хорда җырлау – болар барысы да пансионаттагы тормышны кызыклырак итә. Әмма әле бусы да иң мөһиме түгел.

– Без алга китеш, әби-бабайларыбызның хәле күпкә яхшыруын күрәбез, – ди Альбина. – Бу безгә алга таба баруга стимул бирә.

Бүген «Добрые истории» пансионаты үз эшенә мондый авыруларны озак вакыт буе карауның прогрессив системасын кертә. Әлеге комплекслы программаның иң мөһим элементларыннан берсе – күнекмәләрен мөмкин кадәр күбрәк саклап калу өчен, өлкән яшьтәгеләрнең һәм инвалидларның тәрбиягә чыннан да мохтаҗ булуын ачыклау. Элегрәк кенә ул хаста караучылардан авыруны тиз арада юындыру-киендерү-ашату таләп ителгән. Бүген исә пансионатта мөмкин кадәр күбрәк гамәлләрне авыруның үзеннән үтәтергә тырышалар – бу мускуллар эшләсен, когнитив сәләтләр саклансын өчен кирәк.

– Эшне кешенең сәламәтлеген генә түгел, биографиясен дә өйрәнүдән башлыйбыз, – дип сөйли Альбина Сергеева. – Ул гомере буе нәрсә белән шөгыльләнгән, ниләр белән мавыккан? Мондый эшнең нәтиҗәләре дә илһамландырырлык була!

ЧИР ЯШӘРӘ

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, деменцияле кешеләр саны 2030 елда 82 миллион чамасы кешегә җитәчәк, 2050 елга исә аларның саны ике тапкыр диярлек артачак һәм 152 миллион тәшкил итәчәк. Күз алдына китерегез әле, бу бүгенге көндә Россиядә яшәүчеләр саны кадәр! Инде хәзер үк деменция төп үлем-китем сәбәпләре арасында дөньяда җиденче урында тора. Хәер, бусы да иң куркынычы түгел. Деменциянең «яшәрүе» куркыныч. Әле пенсиягә дә чыкмаган кешеләр аның белән һаман ешрак авырый.

Әйләнә – алар оныта, чама хисен югалта, ачыгуны тоймый, кайвакыт исә тәүлеклек норманы бер утыруда ашап бетерергә мөмкин.

– Мондый кешеләр даими социумда һәм иминлек шартларында булырга тиеш, – дип сөйли Альбина. – Шулай ук иркенлек таләп итәлә – изоляция авыруны шактый көчәйтергә мөмкин. Без үзебездә тәрбияләнүчеләрне боларның барысы белән дә тәэмин итәбез. Пансионатта алар рәхәтләнеп аралаша, көн саен саф һавада йөри ала – безнең территориябез бик матур. Әхрәкәт активлыгы – деменцияне кисәтүдә һәм мондый авыруларны тәрбияләүдә бик кирәкле фактор.

Интеллектуаль һөнәр ияләре әлеге чиргә бирешмәүчән, дигән фикер дә бар. Кызганыч ки, пансионат статистикасы моны дәлилли алмый. «Добрые истории» тәрбияләнүчеләре арасында укытучылар, табиблар, дәүләт хезмәткәрләре, инженерлар

КЕШЕ, ГАИЛӘ, БӨТЕН ДӨНЬЯ ПРОБЛЕМАСЫ...

Дөнья җәмәгатьчелеге деменция проблемасын хәл итә алмый. БСО белгечләре шундый нәтиҗә ясаган. Алар исәпләвенчә, дөньяда 55 миллионнан артык кеше әлеге чирдән интегә. «Деменция миллионнарча кешене хәтереннән, бәйсезлеге һәм абруеннан мәхрүм итеп кенә калмый, ул шулай ук безне дә үзебез белгән һәм яраткан кешеләрдән мәхрүм итә», – ди БСО Генераль директоры Тедрос Адханом Гебрейесус. Төрле мәгълүматлар буенча, Россиядә 2 миллион чамасы деменцияле кеше яши – без әлеге чир буенча «рекордчы» илләр исәбенә керәбез. Бу четерекле тема турында мөмкин кадәр ачыграк сөйләр вакыт җитте, дип саный Альбина Сергеева.

«Добрые истории» пансионатындагы деменция билгеләре булган иң яшь хатын-кызга нибары 52 яшь кенә.

– Туганнары әйтүенчә, аңарда когнитив тайпылышлар коронавирус белән авыргannan соң башланган, – дип сөйли Альбина. – Билгеле инде, бу хатын-кызның үзенә генә түгел, аның якыннары өчен дә зур сынауга әйләнгән.

Гаиләдә авыру кеше булганда, яшәү рәвеше тамырдан үзгәрә. Күпләр каядыр ял итәргә бару түгел, тизгә генә кунакка да барып кайта алудан мәхрүм кала. Ә бит аларга да ял кирәк. Тагын бер мөһим мәсьәлә – авыруның да, янәшәдәгеләрнең дә иминлеге мәсьәләсе. Көн саен эшкә йөрергә мәҗбүр булгач, куркынычсызлыкны ничек тәэмин итәргә соң?

Деменцияле кешегә вакытында ашау, дару эчү дә зур проблемага

бар... Мөгаен, сәбәбе шундадыр да: без хәзер бик аз хәрәкәтләнәбез, вак моториканы эшкә җикмибез, ә бит ул баш миенә бик яхшы тәэсир итә. Без бит хәтта кулдан язудан да туктадык диярлек!

Альбина Сергееваның зур хыялы – деменциядән интегүчеләр өчен махсуслашкан реабилитация үзәге ачу. Моның өчен аның белеме дә, тәҗрибәсе дә җитәрлек, һәм, иң мөһиме, беренинди очраклы кеше дә кермәгән профессиональ командасы бар.

– Без инде күптәннән үз эшебезне гади эш кенә дип кабул итүдән туктадык. Безнең һичшиксез авыруны аякка бастырасыбыз яки аның когнитив функцияләрен саклап калуга ирешәсебез килә. Пансионаттагы игелекле гамәлләребез исә үзебез өчен иң шәп мотивация булып тора.

«Добрые истории» интернатында бирелгән фото. РЕКЛАМА

ИДЕЛДӘН ЕНИСЕЙГА КАДӘР...

Сентябрьдә Россия журналистлары, бергәләп җылынырга ниятләп, традиция буенча Сочида, «Бөтен Россия – 2022» хәзерге заман журналистикасының XXVI форумында очрашты.

Тик җылыну насыйп булмады, Сочидагы бәрхет сезон яңгырлар һәм тынгысыз диңгез белән «сөендерде».

ИҖАДИ ЯКЫН КИЛҮ

Журналистлар күпмилләтле Россиянең бөтен төбәкләреннән җыелган иде: Иделдән – Енисейга, Камчаткадан Донбасска кадәр. Төбәкләрне тәкъдим иткәндә иҗади креатив таң калдырды: Краснодар крае алмадан ясалган филләре, Алания – осетин бәлешләре, Саха Республикасы – якут җырлары, Донбасс – «шахтер кызы» Анна Ревякина шигырьләре, «Российская газета» фронт корреспондентларының фотокүргәзмәсе белән сокландырды...

Фото: Татьяна Вафина

СОЧИ
ХОСТИНСКИЙ РАЙОН

MTS RUS
08:29
74 %
Сочи
15°
Дождь
Макс.: 17°, мин.: 12°
Ожидается облачная погода около 09:00.
Сейчас 09 10 11 12
60 %
15° 16° 16° 17° 17°
ПРОГНОЗ НА 10 ДН
Сегодня 90 % 12° 17°
Вс 50 % 11° 18°
Пн 11° 22°


БАШКОРТОСТАН
Республика
БАШКОРТОСТАН

ЯРКО
ИНТЕРЕСНО
ДУШЕВНО
на Ставрополье

СССР

ЯЗУЛЫ АРКАЛАР

«Аркагыз чиста икән!» – дип шаярта алмадылар бу форумда. Чөнки аркасына язу язылмаганнар бөтенләй юк иде диярлек. Үз аркаңның үзең турында сөйләү өчен менә дигән урын булуын журналистлар инде күптән белә; бу юлы исә анда үз төбәкләре һәм үзләре эшләгән гаммәви мәгълүмат чарасы турында белешмә урнаштырылган иде.

«ТАТМЕДИА» – ТАТАРСТАН УЛ

Форумның бер көне тулысынча «Татмедиа» хозурына бирелгән иде. Презентация, осталык дәресләре, түгәрәк өстәл. «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков форумда катнашучыларга яңа проектларның ничек ясалуы турында сөйләде, «Салават күпере» журналының баш мөхәррире Зилә Фәйзуллина журналистларны бәләкәй укучылар белән эшләүнең яңа формалары белән таныштырды, шагыйрь Равил Фәйзуллин үзенең яңа китабын тәкъдим итте. «Татарстан» журналы исә, форумда катнашучыларның һәркайсына бүләк ителеп, Татарстанда яшәүнең ни өчен яхшы булуын төшендерде.

Форум ябылган көнне журналистлык конкурсларына нәтиҗә ясалды. Татарстан Сочидан өч бүләк алып китте:

Евгений Лызаев («Нижнекамск-информ») «Иң яхшы операторлык эше» номинациясендә җиңде. Бүләк аңа «Вяземский котел» фильмы өчен бирелде.

Равил Мукменов («Снег Медиа» проекты авторы) «Иң яхшы журналистлык әсәре» номинациясендә җиңде.

«Татарстан» журналы «Махсус проект/ел акциясе» номинациясендә китап укуга мәхәббәт тәрбияләүгә багышланган «Тасвирлау гына җитми – укырга кирәк!» проекты өчен махсус диплом белән бүләкләнде.

ТАТАРСТАН
Сколько палочек в чак-чаке?

Будет как новенькая: поликлинику «вылечат»
Степные зори
Шах и мат
Ход конём Александра Горбунова
Если друг оказался не друг
Криминальная история
ской в мире нет!
ТАТАРСТАН
Сколько палочек в чак-чаке?

Союз журналистов России
Союз журналистов России
ТАТАРСТАН

НЕЙШИЙ МЕДИАХОЛДИНГ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
81
интернет-сайт
ТАТАРСТАН
Сколько палочек в чак-чаке

Бүгенге көндә татар телен саклау, аның байлыгыннан файдалана алу, туган телдә дөрес сөйләшү, язу кебек проблемалар актуальлеген югалтмый. Бу җәһәттән һөнәри эшчәнлеге телгә бәйле белгечләр өчен сүзлекләр төзү, телне барлау-саклау өлкәсендә абруйлы сүз әйтә алырлык оешмаларның эшчәнлеге кызыклы. «Татарстан» журналы үзен борчыган сораулар белән илебезнең иң өлкән фәнни оешмаларыннан берсе – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына мөрәҗәгать итте һәм лексикография бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Фәридә Таһирова белән әңгәмә корды.

ЭНӘ БЕЛӘН КОЕ КАЗУЧЫЛАР

– Фәридә Инсановна, институт эшчәнлеге белән дә, үзегез белән дә таныштырып китегез әле...

– Мин Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегенә 1992 елда килдем. Өч дистә ел узган икән инде... Килүгә миңа ике томлык «Татарча-русча сүзлек»не редакцияләргә бирделәр. Хәзер булса, мин аны берничә ай эшләр идем, ул вакытта бер атнада өлгерттем (көлә). Шул көннән башлап бүгенгәчә турыдан-туры сүзлекләр төзү һәм редакцияләү белән шөгыльләнәм. Моннан тыш, әлбәттә, төрле елларда төрле теоретик мәсьәләләргә дә тукталырга туры килде: тәрҗемә, терминология, тел сәясәте, фразеология, орфография, лингвокультура һ.б.

Гомумән, безнең буынга бик күп төрле сүзлекләр төзергә туры килде, моңа кадәр бу кадәр сүзлекләр эшләнмәгәндер. Хәзер дә институтыбыз эшчәнлегендә лексикография юнәлеше иң нәтиҗәлесе дип әйтергә була. Соңгы биш елда гына да безнең бүлектә егерме сүзлек чыккан.

– Бүген орфография, ономастика, үсемлекләр, хайваннар дөньясына һ.б. өлкәләргә караган русча-татарча сүзлекләр кытлыгы бар кебек. Институтта бу эш алып барыламы?

– Сүзлекләргә чыннан да һәрвакыт ихтыяҗ бар. Шул ук вакытта сез санаган сүзлекләрнең барысы да диярлек төзелгән. Төрле өлкәләргә караган сүзлекләр төзү эше эзлекле рәвештә озак еллар дәвамында алып барыла. Кызганычка, аны таныту гына җитми. Менә быел гына 6 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзү эшен төгәлләдек. Бу – тел гыйлемендә зур вакыйга. Һәм моны җәмәгатьчелеккә җиткерергә кирәк. Без төзегән сүзлекләрнең барысы да TATZET платформасына урнаштырыла бара, ул һәркем өчен ачык.

– Бүгенге көндә сүзлекләр төзү эшендә нинди перспективалар бар?

Фото: Александр Ефремов

ФӘРИДӘ ИНСАН КЫЗЫ ТАҺИРОВА, филология фәннәре кандидаты, ТӘҺСИ лексикография бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районы Иске Яндука авылында туып үскән. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлагач, Алабуга дәүләт педагогика институтына укырга кергән. Филология өлкәсенә очраклы гына килеп эләктем, дисә дә, Фәридә ханым гомере буена һөнәренә тугры булып калган. Филологиянең дә, алар үзләре әйткәнчә, «бухгалтерия»сендә энә белән кое казуда ул. Сүзлекче диләр аларны. «Сүзлекчеләр – телнең фанатлары, алар үзләрен күрсәтеп йөрми, мәгарәдәге кебек бөртекләп сүз җыюда булыр», – дип тасвирлый сүзлекче һөнәрен Фәридә Таһирова.

– Без төзегән сүзлекләр хәзер интернетка эзләү системаларына кертелә. Кемдер Америкада, кемдер Австралиядә, Төркиядә яши. Ягъни һәркем теләсә кайчан, дөньяның теләсә кайсы почмагыннан интернетка кереп, үзенә кирәкле сүзне карый ала. Ләкин бу чын электрон сүзлек түгел әле. Чын электрон сүзлек – перспективалы юнәлеш. Әйтик, анда өстәп, төзәтеп була. Һәм кәгазь сүзлектән аермалы буларак, анда төрле яктан керергә була. Кәгазь сүзлектән бер сүзне эзләп табу өчен аны алдан белергә һәм дөрес язылышы буенча эзләргә кирәк. Электрон сүзлекләрнең мөмкинлекләре киңрәк һәм торган саен киңәя. Бу өлкәдә төрекләр алдынгырак, аларның мөмкинлекләре дә күбрәк. Якутларда, Себер татарларында мегагрант буенча зур-зур лабораторияләр эшли. Мәсәлән, аларда фонетика лабораториясендә генә дә кырыгар кеше эшли, ягъни безнең тулаем институт кадәр. Корпуслар мәсьәләсендә дә шундый ук хәл. Себер халыклары турыдан-туры Россия Фәннәр академиясенә карагангамы, алар грантлар алып, корпуслар төзү эшенә тотынды.

– Тыныш билгеләренә килгәндә, өтерләр белән нишләргә? Редакцияләрдә эшләүче мөхәррирләр өчен берәр кулланма юкмы? Шулай ук орфографик хаталардан качар өчен бердәм кагыйдәләр комачауламас иде.

– Без үзебез дә сүзлек төзегәндә, редакцияләгәндә шул ук тыныш билгеләре, дөрес язылыш проблемаларына тап булабыз. Шунда ук аларны хәл итеп барырга тырышабыз. Тыныш билгеләрен аңлата торган кулланмалардан К.С. Сабиров хезмәтен күрсәтер идем (Сабиров К.С. Татар телендә тыныш билгеләре. Казан, 1956). Әлбәттә, аның яңа басмасын әзерләргә кирәк.

Орфографик сүзлекләр дә шактый. Бәлки кирәгеннән артыктыр да әле. Ләкин проблемалар кала бирә. Кайвакытта теоретик яктан хәл итеп, дөрес язу кагыйдәсен табу җиңелрәк, ә аны кабул иттерү, аңлату кыенрак була. «Без башкача өйрәндек», «безнең авылда болай түгел», «халык аңламаячак» кебек реакцияләр күзәтелә. Иманым камил, орфография мәсьәләсен бары тик белгечләр хәл итәргә тиеш. Төркиядә бу яктан Төрек теле курумы (Ататөрек вакытында, җөмһүриятнең беренче елларында ук нигез салынган оешма) чыгарган орфографик сүзлекнең соңгысы канун көченә ия, соңгысы дөнья күрүгә, алдагысы гамәлдән чыга. Бездә алай түгел.

Орфография мәсьәләләрен берьюлы хәл итү, аны идеаль хәлгә китерү мөмкин дә түгел, чөнки тел – җанлы, ул көн саен үзгәреп тора. Дөньяда идеаль орфографияле тел юк. Әйтик, инглиз теленә атнасына сигез сүз керә. Һәм алар, мәсәлән, ирландларның телендә яки кельтларныкында ничек язылса, инглиз теленә дә шул көе керә. Сөйләм теле аша бик күптәннән кергән сүзләр генә татар теле закончалыкларына яраклаштырылып языла. Соңгы йөз елда сүзләр китап аша керә һәм без аны язма телдән алабыз, шуңа күрә дә чыганак телдәгечә язабыз да.

Гомумән, тел нормалары мәсьәләләрендә ТӘһСИ кебек үзәк бер генә булырга тиеш. Без – академик үзәк. Җаваплылык та академик оешмада була.

– Тел нормалары үзгәрүгә ничек карыйсыз? «Ничек язабыз, шулай сөйләшәбез, әдәби тел аралашуны чикли» дигән фикерне яклаучыларга ничек карыйсыз?

– Мин бу мәсьәләдә бик усал. Әдәби телдән читләшеп, сөйләм телендә язарга өндәү – ахмаклык ул. Тарихта әледән-әле андый бәхәсләр чыгып торган. XX гасыр башында «Нинди телдә сөйләшик?» дигән темага ут ягып бәхәсләшкән чорлар булган, бу турыда заманның иң зур галим һәм язучылары үз фикерләрен әйтеп калдырган.

Әдәби тел татарларда бар икән, киресенчә, горурланырга кирәк. Кайбер халыкларда ул әле дә формалашып җитмәгән. Телнең нормасыз вакыты оешып җитмәгәнлекне, формалашмаганны аңлата. Ул бер дә үсешне күрсәтми. Әйтик, сүзлекләр төзегәндә, бик күп телләрне чагыштырырга туры килә. Кушма сүзләр белән шөгыльләнгәндә, бөтен төрки телләрнең грамматикалары белән таныштым. Бик күпләренең теориясе безнең телдән кайтышрак.

Тел законнары чикли дигәннән. Дөнья үзе тоташ нормалардан, законнардан тора. Табигать законнары (мәсәлән, табигый сайланыш), физика законнары (тарту көче), химия законнары һ.б. Нишләптер алар берәүгә дә комачауламый. Шулай тиеш дип кабул ителә. Нишләп тел законнары гына чикләргә тиеш соң әле? Язучыларны гына алыйк. Мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиевне укыганда, тел нормаларын да, кагыйдәләрен

PRESSA

дә онытасың, көләсең дә, елыйсың да. Аны бит берни дә чикләмәгән. Күп укыган кеше беркайчан да бу сүзне ничек язасы әле дип уйлап тормый, автомат рәвештә язып кына куя. Ул тел законнары турында уйламый, тота да үз романын яза. Укымыйча язучы булып булмый. Борын-борын заманда көнчыгыш шигъриятенең үсеш чорларында шагыйрьләр бер-берсенең 50 меңләп шигъри юлын яттан белергә тиеш булган. Ни өченме? Сүз запасы, образлар запасы җыелсын өчен. Бер-берсен кабатлар өчен түгел, киресенчә, кабатламас өчен кирәк булган ул. Бассейнга су тула-тула да, тулгач кына торбадан ага башлый. Телдә дә шулай.

– Үзегез хәзерге вакытта язылган китапларны, газета-журналларны укыганда, телче буларак, кул үзеннән-үзе төзәтергә каләм сорамыймы?

– Сорый шул. Телевизор тыңлаганда да хәтта. Бер җөмләдә -учы/-үче кушымчаларын тезә башласалар, телевизорны сүндереп куям, -учы/-үче исем фигыльдән бигрәк, исем буларак кулланыла. Ул – субъект. Ә бездә Яңа ел да килүче, яңгыр да явучы. Аның -а торган /-ә торган дигән формасы бар. Үткән заман формасы түгел ул. Төрекчә гениш заман дип әйтелә, киң заман ул. Киләчәк заманнан алып үткән заманга кадәр колачлый. Мондый кагыйдәләрне белмәү үз хезмәтеңә карата җавапсызлыктан килә. Тел байлыгы, сүз байлыгы җитми, стильләр бутала, рус сүзләрен татарчалаштырырга тырышу белән мавыгалар. Әнә бит алты том тора! Ул бит татар теленә һәйкәл! Ач та кирәкле сүзне, аның урынлы мәгънәсен эзләп тап.

Кыенлыклар белән очрашабыз урынына – кыенлыклар очрый, кыенлыкларга тап булабыз; ә туганнар, дуслар белән очрашабыз. Кораллар белән файдаланмыйбыз, кораллар кулланабыз, кораллардан файдаланабыз.

Күптән түгел генә чыккан «Татар теленең кыенлыклар сүзлеге»ндә без, типик хаталарны анализлап, алардан котылу юлларын күрсәттек.

Иң борчыганы – язучыларда, журналистларда тел байлыгы җитмәү. Тел чараларын сайлауда талымсызлык. Грамоталылык дәрәҗәсе төшү. Стильләр арасында чикләр бетү, түбән стильнең әдәби стильгә үтеп керүе һ.б. Болар аз укудан килә дип саныйм. Монда үпкәләү урынсыз, чөнки алар халык өчен яза, текстларын үзләре теләп халык хөкеменә чыгара, ә лингвист шул язма текстларны анализлый.

– Феминитивлар белән нишләргә? Сез галимме, галимәме?

– Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, биологик җенес белән телдәге род категориясенең корреляциясе юк. Әгәр аларны белдерә торган сүзләр бар икән, алар әзер алынма буларак кергән. Соңрак ясалганнары бик үк дөрес түгел. Кулланырга мөмкин, ләкин бик кирәк, ансыз булмый дигән әйбер юк. Филологлар рус әдәби телендә дә «поэтесса» дигән сүз юк диячәк. Чөнки ул сөйләм стиленә генә карый. Беренче урында мәгънә, ә аны төрлечә белдерергә мөмкин.

– Яшьләр сленгында инглиз теленнән рус теленә кергән сүзләр бик күп. Рус теле аша татар теленә дә керә. Шулай ук бизнес, халыкара мөнәсәбәтләрдә кулланыла.

– Әйе, андый сүзләр хәтта артык күп. Телләр арасындагы чикләр дә халыклар арасындагы чикләр кебек үк юкка чыгып бара, дип уйлыйм, чөнки гомуми мәгълүмат киңлеге нык берләштерә. Бер сүз рус теленә кергән икән, ул шул ук көнне татарча да кулланыла башлый, дип әйтерлек. Әгәр тел, сүз синең һөнәрең икән, син һәр сүзне урынлы, белеп кулланырга тиеш. Мәгънәсен ялгыш аңлап, урынлы-урынсыз куллану бизәмиме.

– Смайлик, эмодзи, стикерлар да язма телгә кереп китмәсме?

– Язма тел шактый консерватив ул. Якын арада гына андый үзгәрешләр булыр, дип уйламыйм. Ләкин беркайчан да булмас, дип кистереп тә әйтмим. Борынгы телләрдә тоташ язу, ноктасыз язу булган бит. Ләкин, минемчә, ул артка таба адым булыр иде. Нормалылык, пунктуация – үсеш алган тел сыйфаты. Символларга килгәндә дә шул ук фикердәмен. Үсеш символлардан (Борынгы Мисыр язуын хәтерләгез) хәрефләргә таба барган, киресенчә түгел.

– Менә ничә ел инде безнең өстә «Тел бетә!» дигән чаң тора. Татар теленең киләчәген 10-15 елдан соң ничек күрәсез? Телнең көче нәрсәдә?

– Әлеге вакытта милләтләр атамалары сүзлеген төзибез. Өр-яңа, бер җирдә дә булмаган сүзлек. Фәнни редактор буларак, аның инструкциясен эшләдем. Анда халыкның атамасы, яшәү урыны, теле, дине турында мәгълүмат биреләчәк. Мисал өчен, төрки телләрне генә алсак та, шактые үле яки юкка чыгу алдында тора икән! Ә ничек тел юкка чыга соң? Кисәк җимерелгән бина кебек түгел, әлбәттә. Башта сөйләшү сферасы урам яки гаилә белән чикләнә, аннан әби-бабасы телендә оныклары гына сөйләшми, алга таба әти-әнисе телен балалары белми. Белүче өлкән буыннан соң ул телдә сөйләшүче калмый. Бу сүзлек тагын бер кат уйланырга мәҗбүр итте. Татар теле андый ук хәлдә түгел кебек. Ләкин тынычланырга ярамый.

Татарларга карата бетәбез дип әйтү иртәрәктер, дип уйлыйм. Шәһәрләшү, глобальләшү – болар бит объектив әйберләр. Бер безгә генә янамый ул. Төркиядә, мәсәлән, күпчелек төрек халкы яши кебек. Юк, алар да төрек теленең киләчәге өчен борчыла. Алынмаларның күп керүен билгелиләр. 2015 ел аларда Төрек теле елы дип игълан ителгән иде. Төрек теле курумы канун көченә ия.

Татар теле гыйлеме бар, сүзлекләре бар, әдәби теле бар... Һәм ул әдәби тел югары дәрәҗәдә системалашкан, аның формалашуы тәгәлләнгән, ул камилләшә генә ала, чөнки бик борынгыдан язма тел буларак кулланылган. Сүзлек төзү тәҗрибәсе бик борынгыдан килә. Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгатеттөрк»тән башлыйбыз, гадәттә. Әзлекле рәвештә сүзлек төзү тәҗрибәсе баеган. Дамаскин сүзлеге, Каюм Насыйри төзегән сүзлекләр, мәсәлән.

Татар теленең көче аның язу тарихы, фәнни яктан әйбәт өйрәнелгән системасы, нормалылыгы, шул ук вакытта җанлы диалектлар һәм сөйләшләр системасы булуда. Ягъни телнең яшәве өчен нәрсә кирәк булса, татар телендә барысы да бар.

– Татарча фән теле...

– 90 нчы елларда, татар теле катып калган, фән теле буларак кулланылмый, дип әйтә идек. Ләкин китапханәләрдә бераз казынсак, 40–50 нче елларда татарча язылган бик матур фәнни китаплар барлыгын күрер идек. 20 нче елларда тернәкләнү чоры булып ала. Авыр елларда да эшләнгән, ул традиция юк түгел. Азмы-күпме фән теле булган. Галимнәр русча гына язган дигән сүз дөрес түгел. 90 нчы еллар шуны күрсәтте: ул онытылып бетмәгән. Ул вакытта төрле өлкәләргә караган шактый күп сүзлекләр бастырылды. Медицина, ветеринария, математика, физика терминнары сүзлекләре... Урман хуҗалыгы, авыл хуҗалыгы, нефть химиясе, сәүдәгә караган... Бүгенге көнгә алар калын-калын терминологик сүзлекләр булып җитеште. Шуңа күрә фән теле юк дип әйтү вазгыятьне чамалап бетермәүдән килә, дип саныйм. Архитектура-төзелеш, медицина институтында лекцияләрне татарча укыткан еллар булды.

– Хәзер татар теле һәм әдәбиятыннан диссертацияләрне дә русча язып, русча яклыйлар.

– Рус теле – дәүләт теле, шуңа да уку йорты, дәүләт теле буларак, русча язып, русча яклау таләбен куярга хаклы. Татарстан чикләрендә без дә татар теленә, дәүләт теле буларак, шундый ук таләп куярга хаклы идек, ләкин без ул таләпне куя белмәдек. Мин ул комиссияләрдә күп йөрдем. Ул вакытта резолюцияләр, тәкъдимнәр күп булды. Гамәлгә ашырырга безнең кыюлык җитмәде. Кызганыч. Шул ук алфавитны латинга алмаштыру мәсьәләсендә дә без бердәм була алмадык. Ул вакытта Мәскәүнең бездә эше юк иде әле, вазгыять без үзара килешкәнче үзгәреп куйды. Ләкин минем өчен латинга күчү аның кадәр әһәмиятле түгел, телне башкача да яшәтеп була. Кытай һәрбер иероглифны исендә калдыра әле. Без дә баланы «тәэмин» дип түгел, «тәэмин» дип әйтергә өйрәтә алабыз. Бер-ике чыгарманы гына истә калдырырлык хәтер бар бит. Тел программасы дип никадәр акча түктек, ата-ана өйрәтмәсә, ул программа буенча чыккан китапларның барлыгын да белмәячәк бала.

– Филолог, тел-әдәбият белгече бүген акча эшли аламы?

– Әгәр безнең кебек фанатиклар бар икән, туп-туры безгә килсеннәр инде. Бюджет оешмасы бит. Хәзерге вакытта тел программалары бар, алар аша тәгаен эшләргә финанслар бүленә. Безнең кечкенә сүзлекләр шул программа нигезендә чыга. Бер кечкенә сүзлек, мәсәлән, кимендә бер ел буена баш күтәрмичә эшләнгән эш ул. Ә күп очракта әле ул ун ел алдан әзерләнгән материаллар да булырга мөмкин. Аңлатмалы сүзлек 25 ел эшләнде. Ягъни тотрыклы хезмәт хакына яшәргә була.

ТАТМЕДИА

shop.tatmedia.ru

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Апанай мәчете **кайчан** ачылган

Татар изүен тегәргә **кайда** өйрәтәләр

Кариев театрында **нинди** яңа тамашалар куела

Карга авылы **ничек** яши

ислам ядкәрләре

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы 922 2022

КАЗАНДАГЫ АПАНАЙ МӘЧЕТЕ

Мәчет манарасы биеклеге һәм нәфислеге белән сокландыра. Гыйбадәтханә үзе кай ягы беләндер якында урнашкан Мәрҗани мәчетен хәтерләтә, фасады гына таш бизәкләр белән мулрак бизәлгән, бу аны бай сарайларга охшаш итә.

Күрше мәчет белән кайбер охшашлыгын тарихи яктан аңлатып була. Апанай мәчетен хәтта Мәрҗани мәчете белән бер елны сала башлыйлар. Моңа рөхсәт императрица Екатерина II галиҗәнапларының үзеннән алына – ул татар сәүдәгәрләренең Иске Татар бистәсендә Анна Иоановна указы буенча җимерелгән мәчетләр урынына таштан ике яңасын салуны сорап язган үте-

Фото: Әскәр Сабиров

нечен канәгатьләндерә. Апанай һәм Мәрҗани мәчетләрен төзегән архитекторның да бер үк кеше булуы бик мөмкин – ике мәчетнең дә манарасы урта гасыр татар архитектурасы традицияләренә туры китереп түбәдә ясалган, шулай ук икесенең дә архитектурасында рус бароккосы һәм татар декоратив сәнгате элементлары шәйләнә.

БАЙЛАР ҺӘМ ХӘЕРЧЕЛӘР ГЫЙБАДӘТХАНӘСЕ

Апанай мәчете Явыз Иван Казанны алганнан соң шәһәрдә пәйда булган икенче таш мәчет була. Шуңа күрә аның икенче исеме дә – Икенче Җәмигъ мәчете (Беренче Җәмигъ мәчете – Мәрҗани мәчете була, беренче азан анда бары тик бер генә ел алдарак – 1779 елда яңгырый. – Ред. иск.). Апанай мәчетенең төрле елларда йөрткән исемнәре арасында, мөгаен, иң серлесе Тау тишеге дип аталуыдыр – ихтимал, якында гына Кабан күленең текә яры булгангадыр.

Соңрак аны Байлар мәчете дип йөртә башлыйлар. Мәхәлләдә шактый хәлле кешеләр яши, шул исәптән күренекле татар сәүдәгәр-сәнәгатьчеләре Апанаевлар, Юнысовлар, Әзмәтевләр, Усмановлар. Апанаевлар озак еллар мәчетне карап тора. Нәтиҗәдә мәчетне дә алар фамилиясе белән атап йөртә башлыйлар. Шул ук вакытта мәчет салуга акча биргән һәм үзе дә турыдан-туры төзелештә катнашкан кешенең исеме күләгәдә кала.

СӘҮДӘГӘР СОЛТАНГАЛИЕВ МИРАСЫ

Бу татар сәүдәгәре Якуб Солтангалиев була. Күренекле шәхес. Хәтта Казан шәһәр ратушасының ике татар бистәсе буенча беренче башлыгы (асылда, шәһәрнең татарлар яшәгән өлешендә беренче мэр) булганга гына да түгел. Аның, җилкенеп, зур дәрт белән мәчет төзелешенә тотынуы буыннар хәтерендә калуга бик лаек.

Шиһабетдин Мәрҗани язганча, морза Якуб Солтангалиев мәчет төзелешенә күп акчалар биреп кенә калмый, төзелешкә ул бөтен көчен бирә. Эштән соң, кичләрен, диндәшләренә үрнәк күрсәтеп, хатыны белән бергә бай сәүдәгәр ташчыларга кирпеч биреп тора, бүрәнәләр ташый. Мәчет түбәсен калай белән тышларга карар кылганнан соң, моны башкарырлык останы Казанда тапмыйча, аны Мәскәүдән алып кайта.

Ишекләрен 1771 елда ачкан мәчет бер заллы булып чыга, фасадында биш тәрәзәсе була, манарасы – сигез кырлы. Шулай да бары тик йөз елдан соң – 1872 елда гына мәчет тәмамланган кыяфәт ала. Дин тотучыларга иске бина кысанрак тоела, һәм алар мәчетне яңартуга биш мең акча җыя. Архитектор Петр Романов проекты буенча төньяктан, төп бина стиленә яраштырып, ике катлы янкорма өстәп салалар. Ун елдан соң бер катлы кибет һәм мәчет тирәли кирпеч койма пәйда була, тагын биш елдан соң икенче катны өстәп төзиләр...

РЕФОРМАЛАРГА КАДӘР БЕРЕНЧЕСЕ

Апанай мәчете имамнары арасында кызыклы шәхесләр шактый була. Шулардан берсе – Гарәбстанда һәм Бохарада дин гыйлемен үзләштергән Салих Сәгыйтов. Ул мәчет каршында мәдрәсә ача һәм тирән белемле педагог буларак абруй казана. Сәлахетдин Исхаков (Сәгыйтов) тарихка патша хөкүмәтенең милли мәгарифне руслаштыру сәясәтенә каршы торучы кыю көрәшче буларак кереп кала. Ә Мөхәммәткасыйм Салихов исә мәхәлләдә җәдидчелек идеяләрен алга сөрүче буларак таныла.

Апанай (Күл буе) мәдрәсәсе XIX гасырда Россия мөселманнары арасында иң абруйлылардан санала. Күп дистә еллар дәвамында биредә ортодоксаль, әмма яхшы дини белем бирәләр. Гаҗәп түгел: бай сәүдәгәрләр бирегә гыйлемле дин белгечләрен чакыра ала. Галиммәгърифәтче Җамал Вәлиди, мәдрәсә «реформага кадәрге Казан мәдрәсәләре арасында беренче урында тора», анда «иң күренекле мөдәррисләр хезмәт куя», дип раслый. Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Хөсәен Фәизханов... – бу әлеге мәдрәсәдә төрле елларда белем алган күренекле дин белгечләренең, җәмәгать эшлеклеләренең, галимнәрнең, тарихчы һәм язучыларның кайберләре генә...

ЯҢАРЫШ...

Котырынган атеизм чорында Апанай мәчете 20 нче еллар ахырына кадәр эшли әле. Ул Татреспублика ҮБКның 1930 елның 6 февралендәге карары белән ябыла. Манараны большевиклар җимерә, ә намаз залында балалар бакчасы урнаштыралар.

Апанай мәчетен дин тотучыларга бары тик 65 елдан соң гына кайтаралар. Яңадан оештырылган Апанай мәчете мәхәлләсенең беренче имам-хатыйбы Вәлиулла хәзрәт Якупов һәм аның тарафдарлары тырышлыгы белән гыйбадәтханә торгызыла башлый, ул тарихи һәйкәлләрне реставрацияләү программасына кертелә. Манараны, мәчетнең тышкы һәм эчке бизәлешен архив документларына, иске фотосурәтләргә таянып яңарталар. Реставрациядән соң рәсми рәвештәге ачылышы 2011 елның 2 декабрендә уза.

Бүгенге көндә Апанай мәчетендә элеккеге кебек үк намаз укыла. Вәлиулла Якупов эшен Нияз хәзрәт Сабиров дәвам итә. Мәчет каршында белем бирү этномәдәни үзәге эшли, аның максаты – милли мәдәни традицияләрне яңарту.

Адресы: Казан, Иске Татар бистәсе, Каюм Насыйри ур., 27

> Апанай мәчете Явыз Иван Казанны алганнан соң шәһәрдә пәйда булган икенче таш мәчет була. Апанай мәчетенең төрле елларда йөрткән исемнәре арасында, мөгаен, иң серлесе Тау тишеге дип аталуыдыр – ихтимал, якында гына Кабан күленең текә яры булгангадыр. Соңрак аны Байлар мәчете дип йөртә башлыйлар: мәхәлләдә шактый хәлле кешеләр яши...

һөнәрле хур булмас

ИЗҮ – ЗАТЛЫЛЫК БИЛГЕСЕ

Руфия Фазылова

«Татарстан» журналы көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрне шактый барлады. Йон эрләү, май язу, көлтә бәйләү, кул тегермәне белән он тарту... Бүген боларның берсен дә эшләмибез. Узган ел «Әбидә кунакта» проекты кысаларында шушы шөгыльләрне белгән апалар белән очрашып, зур булмаган тапшырулар төшердек. Быел да бу эшне дәвам итәргә булдык, ата-бабаларыбыздан калган затлы һөнәрләребез бик күп бит.

ОСТАХАНӘ – МИЛЛИЛЕКНЕ АЛГА СӨРҮ

Башкалабызның борынгы Апанай мәчете мәдрәсәсе каршында милли-мәгариф үзәге эшләп килә. Ул халкыбызның йолаларын, шөгыльләрен торгызуга йөз тота. Үзәк каршында остаханә бар. Биредә кул эшләренә өйрәтәләр: төрле букча, изүдән башлап читек-чүәккә кадәр тегәләр. Монда балалар да яратып йөри: сәйләннән төрле бизәк, картиналар, милли рухтагы магнитлар ясыйлар – теләсә кем күңеленә хуш килгән шөгыльне таба ала.

– Остаханәне оештыру идеясе берничә ел элек туды, – ди Апанай мәдрәсәсе мөдире Әхмәт хәзрәт Сабиров. – Глобальләшү чорында яшибез бит, халкыбызның милли үзенчәлекләре югалып бара. Бу бигрәк тә үсмерләр, яшьләр өчен куркыныч, алар безнең милли үзенчәлекләрне өйрәнә алмый дигән сүз. Шуның өчен дә мондый остаханә булдырдык. Безгә 5 яшьтән алып 13–14 яшькә кадәр балалар килә. Алар башта махсус фетр тукымадан акча янчыгы ясап карый, аннан исә күн белән дә эшли башлый.

Остаханә көн саен эшли, чөнки юнәлешләр берничә, төрле көнне, төрле сәгатьтә килеп шөгыльләнәләр. Кул эшләренә өйрәтүче остазлар да берничә. Балалар белән бергә

Фото: Илнар Өметбаев

өлкәннәр өчен дә курслар бар. Мисал өчен, без килгәндә берничә ханым чүәк, читек тегәргә өйрәнә иде.

– Балалар өчен түгәрәкләр җомга, шимбә була, – диде остазларның берсе Ризидә ханым. – Өлкәннәр өчен оештырылган түгәрәкләрдән аермалы буларак, балалар башлаган эшләрен бер дәрестә төгәлли. Без әллә ни зур әйбер ясамыйбыз. Соңыннан бергәләп чәй эчәбез, әниләр дә кушыла. Кыскасы, һәр очрашу үзе бер бәйрәмгә әйләнә. Шуның өчен дә балалар бик яратып йөри.

«ӘБИЕМ ӨЙРӘТТЕ»

Остаханәдәге тагын бер юнәлеш – изү (күкрәкчә) тегү. Монысына нигездә өлкәннәр йөри, чөнки ул шактый четерекле эш. Пөхтә итеп кисәргә, тегәргә өйрәнгәч кенә эшкә алынырга мөмкин, шул исәптән үсмер балаларга да. Остаханәдә изү тегү юнәлешен Гүзәл ханым Шәйдуллина алып бара. Безгә дә бу эшнең барлык нечкәлекләрен бәйнә-бәйнә аңлатты ул:

– Күкрәкчә тегүне бик катлаулы эш димәс идем. Бигрәк тә бүгенге көндә: тукыманың нинди төре генә юк, бизәр өчен чуклы, ялтыравыклы тасма, төрле ташлар дисеңме... Фантазияңне эшкә җигәсең дә җаның теләгәнен эшлисең. Гап-гади күлмәк тә матур изү белән затлы киемгә әйләнә.

– Ә сез изү тегәргә кемнән өйрәндегез? – дибез.

– Дәү әнием өйрәтте. Гомумән, бик күп эшләрдә ул миңа остаз булды. Гел аны сагынып искә алам.

Гүзәл апа безгә эшне җиңеләйткән иде – изүгә дигән тукыманы кисеп куйган. Каты полиэтиленнан ясалган калыбы бар. Менә шуны тукымага куеп төшергән дә кисеп чыккан. Аннан инде җаның теләгәнчә кырыйларын ясыйсың, бизисең.

– Түгәрәккә йөрүче хатын-кызлар изүнең төп өлешен бер дәрестә эшләп бетерә, – диде Гүзәл ханым. – Бизәүне инде өйдә дә башкара алалар. Кул астында тегү машинасы булса, тагын да тиз инде.

Гүзәл апа үзе теккән изүләрне алып килгән иде: төрле тукымадан, төрлечә бизәлгән алар. Кул остасы аларга пар итеп калфак та тегә икән. Нәтиҗәдә тулы бер образ барлыкка килә.

– Безнең хатын-кызлар гомергә изү, калфак белән йөргән, – диде Гүзәл ханым. – Бу затлылык билгесе саналган. Кыз бала тугач та, ата-ана бирнә җыя башлаган. Шул исәптән калфак өчен төрле кыйммәтле ташлар, бизәкләр. Кияүгә чыкканда кызның изүе никадәр затлырак булса, гаиләнең матди хәле дә шуның кадәр яхшырак дип саналган.

ИЗҮНЕ нигездә өске почмаклары бөгелгән, күлмәкнең күкрәк уемы астыннан тотып торырлык бәйләвечләре булган дүртпочмаклы тукыма кисәгеннән (зурлыгы 20×30 яки 25×40 см) тегәләр. Изүнең күлмәк уемына туры килгән өлеше чигелгән яки аппликация белән бизәлгән була. Гадәти бизәк – чәчәк бәйләме, чәчәкле ботак. Ул тигез яки (ешрак) тамбур чигүе белән, кайбер очракларда келәм җөенә катнаштырып эшләнә. Борынгы үрнәкләрдә алар алтын җепләр белән, кайбер очракларда төсле ефәк кушып, тигез чигү белән чигелгән.
Изүгә ике төрле мәгънә йөкләнгән: бизәнү әйбере булудан тыш, сәнгати образга саклау мәгънәсе салынган, ул хатын-кызны явыз рухлардан сакларга тиеш булган. Изүне осталар үзләре өчен, туй бүләкләре һәм үлемтек (өлкән яшьтәге хатын-кызны җирләгәндә аның төсе итеп яшьтәшләренә изүләр өләшү гадәте булган) сыйфатында тарату өчен теккәннәр.
Изүләр XX йөз уртасында, Европа костюмы модага кергәннән соң, кулланылыштан чыккан.

Татар энциклопедиясеннән

Гүзәл апа үзе дә дәү әни. Ун яшьлек оныгын дин гыйлеменә, тегәргә, чигәргә өйрәткән. Моннан тыш, ул әле башкала мәчетләрендә мәет юу буенча курслар да алып бара. Интернетта видеодәресләре дә бар. Быел исә Апанай мәдрәсәсендә изү тегү буенча да әнә шундый дәресләр үткәрә.

Гүзәл апа чын мөгаллимә: матур итеп сөйли, аңлата, күрсәтә. Шуның өчен дә аның белән эшләргә бик рәхәт булды. Хөрмәтле укучыларыбыз, сезнең дә остаз белән якыннанрак танышу теләге туса, видеоны кереп карагыз. Татар тотып карамый ышанмый дисәләр дә, күргәч барыбер иκенче. Т

Язманың видеоварианты да бар.

китап к

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВНЕҢ КИТАП КИШТӘСЕ

«Китаплар – минем тормышым ул», – ди танылган татар язучысы, «Татарский мир» («Татар дөньясы») газетасының баш мөхәррире Ринат Мөхәммәдиев. Һәм бу чыннан да шулай! Ул Язучылар берлекләре халыкара берләшмәсендә Сергей Михалковның уң кулы була, РСФСР Югары Советында мәдәният мәсьәләләрен күтәреп чыга, Татарстан китап нәшриятын һәм ТАССР Язучылар берлеген җитәкли. Һәм шул ук вакытта яза, редакцияли, әдәби тәнкыйтьче буларак чыгышлар ясый... Ә менә нинди китапларга аның үзенең китап киштәсендә булу бәхете елмайган икән соң?

БАЛАЧАГЫМДА ҺӘМ ЯШЬЛЕГЕМДӘ ИЛҺАМЛАНДЫРГАН КИТАПЛАР...

Мин авылда туып үстем һәм бала чагымда татарча гына сөйләшә идем. Хәзер моңа ышануы кыен, әмма 1950–60 нчы елларда авылда татар теленә тәрҗемә ителгән рус классикасын гына түгел, чит ил әдәбиятын да табу бик җиңел иде. Жюль Верн романнары тәрҗемәләрен чират торып укуыбызны хәтерлим. Искиткеч оста тәрҗемә ителгәнгә, аларны оригиналда укыгандай тоела иде. Бу әсәрләр фантазиябезне баетты, белемебезне арттырды. Джек Лондонның романтик китаплары һәм Теодор Драйзерның атаклы романнары турында да шулай дип әйтә алам.

Бөек Ватан сугышы турында әсәрләр безнең арада бик популяр иде. Инде өлкәнәйгәч, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булгач, мин Нәби Дәүли белән таныштым һәм дуслаштым, үсмер чакта исә без аның «Яшәү белән үлем арасында» повестен һәм «Җимерелгән бастион» романын йотлыгып укыдык. Ул сугышны, әсирлекне һәм фашист төрмәсендә дә көрәшүне шулкадәр реалистик итеп сурәтли ки, әлеге китаплардан аерылу һич мөмкин түгел! Гаҗәп хәл булса да, барлык бу китаплар типографиядә табадан төшүгә үк безнең кулга килеп эләгә иде.

Мин шулай ук Мирсәй Әмир китаплары, Габдрахман Әпсәләмов әсәрләре, Габдулла Тукай шигъриятеннән илһам ала идем. Ул чакта ук Һади Такташ иҗатына мөкиббән булдым. Бигрәк тә аның «Мокамай» поэмасын ярата идем. Әгәр шулай әйтергә яраса, минем әдәбият белән мөнәсәбәтләремдә бу романтик чор булды.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

...Князь Феликс Юсупов мемуарларын. Парижда басылган һәм русчага тәрҗемә ителгән. Бик зур кызыксыну белән укыйм. Кайчандыр мин әлеге күренекле нәсел вәкилләре белән аралашкан идем. Аларның нәсел тарихының татар тамырларына тоташуын, үзләренең Россия дәүләтенең патриотлары булуын, башка илләрнең патша, король һәм вельможалары белән аралашуын, шунлыктан күп нәрсә хакында шактый объектив фикер йөртә алуын яхшы беләм. Феликс Феликсович үз хатирәләрен ничек бар шулай, элгәрләре биографиясен шомартмый-күпертми язган. Асылда, аның мемуарлары аша Россия тарихы белән танышырга була.

ИҢ КӨЧЛЕ ТӘЭСИРЛӘНДЕРГӘНЕ...

Миңа, татар язучысы буларак, Әмирхан Еникинең повесть һәм хикәяләре иң көчле тәэсир иткәндер, мөгаен. Теләсә кайсы вакытта – болай гына да, эч пошканда, илһам сүрелгәндә яисә эш бармаганда – аның китабын алып укый башлыйм һәм дөньямны онытам.

Фото: tatar-inform.ru

иштәсе

ИҢ ЯРАТКАННАРЫ

Бәхеткә, Язучылар берлекләре халыкара берләшмәсе рәисе урынбасары булып эшләгәндә, мин әдәбиятыбыз классиклары белән якыннан аралаштым. Күбесе белән дуслаштым, мәсәлән, Евгений Евтушенко белән. Поэзияне берәзлексез уку мөмкин булмаса да, мин Евгений Александрович шигырьләрен кабат-кабат укырга яратам. Шулай ук үземә бик ошаган Андрей Вознесенский әсәрләрен дә еш кулыма алам.

Валентин Распутин һәм Виктор Астафьевның басылып чыккан һәр китабын укып бардым. Татар язучылары әсәрләре арасында иң яратка765ым исә – Мөхәммәт Мәһдиев язганнары. Миңа аның повесть һәм романнарын редакцияләү бәхете тәтеде – 1970 нче елларда ул бик популяр иде.

КИҢӘШ ИТӘМ!

Һәр кеше үз язучысын табарга тиеш, дип саныйм. Мәсәлән, Михаил Булгаковны яки Борис Пастернакны һәркемгә дә укырга киңәш итеп булмый. Бу катлаулы әдәбият, аны яратыр өчен билгеле бер юл үтү зарур. Билгеле, үзеңне тәрбияләргә дә кирәк. Мин үзем моңа мисал була алам. Университетта укыганда, мин Дәрдемәнд турында бик аз белә идем. Бүген исә теләсә кайсы вакытта киштәдән аның китабын алам икән, уйлану һәм илһамлану өчен нибары бер шигырен уку да җитә. Һади Такташ әсәрләре белән дә шулай ук...

Яшь буынга Юрий Бондарев китапларын укырга киңәш итәм! Мин аның белән дус идем һәм романнарын күптән түгел тагын бер кат укып чыктым. «Горячий снег» – искиткеч китап, Юрий Васильевич үзе дә аны, барлык әсәрләрем арасында иң яраткан романым, дип әйтә иде.

Шулай ук Чыңгыз Айтматовны тәкъдим итәм. Кызганыч ки, бүген Мәскәүдә аны оныта башладылар. Айтматовны хәзер Урта Азиядә, Төркиядә, безнең Татарстанда еш искә алалар. «Первый учитель», «И дольше века длится день» – әлеге әсәрләр бүген дә бик актуаль.

Үз китапларым турында да әйтми кала алмыйм, чөнки алар минем өчен иң кадерлеләре бит. Мөгаен, иң яхшылары дип «Ак кыялар турында хыял» повестен, «Сират күпере» романын һәм тагын «Утлы таба өстендә» документаль китабын атармын. Соңгысы Советлар Союзының таркалуы, бүгенге проблемаларны тудырган һәм кичәге кардәшләрне дошманга әйләндергән вакыйгалар хакында. Депутат һәм РСФСР Югары Советы каршындагы мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе җитәкчесе буларак, мин тарихның ничек язылганын үз күзләрем белән күзәтә алдым. Ул чактагы вазгыять турында мин чын дөресен яздым, китап татар һәм рус («Крушение» исеме белән) телләрендә басылып чыкты, шулай ук дистәләрчә чит телгә тәрҗемә ителде.



ӘЛЕДӘН-ӘЛЕ АЛЫП УКЫЙМ...

Минем фикеремчә, иң яхшы хикәячеләр – Әмирхан Еники, Антон Чехов, Сомерсет Моэмдыр ул... Яраткан хикәяләремне әллә ничәшәр тапкыр укый алам. Мәсәлән, Чеховның «Душечка» хикәясе, андагы Оленька Племянникова зирәклеге һәм төрле хәлләргә тиз арада яраклаша белүе белән генә түгел, тугрылыгы һәм эчкерсезлеге белән дә таң калдыра. Бу бик беркатлы һәм ихлас хикәя, тик нәкъ менә шундый әдәбият минем күңелемә хуш килә дә. Әмирхан Еникинең «Матурлык» хикәясе дә шундыйлардан. Ул миңа укыган саен яңа яктан ачыла бара. Уильям Сомерсет Моэм хикәяләре хакында да шуны ук әйтә алам. Ә инде аның Англиядәге биржа маклеры Чарльз Стрикленд турындагы «Луна и грош» романы һәрвакыт минем эш өстәлемдә ята. Мин аны теләсә кайсы битеннән ачып укырга яратам.

КИТАП ОШАМАСА...

Әгәр 5–10 биттән соң китап миңа ошамаса, укымаячакмын, кайвакыт битләрен актарып чыгам. Мин инде күптәннән үземә ошамаган әйберне укып азапланмыйм. Әйләнә-тирәдә укып туя алмаслык әллә никадәр әдәбият булганда, нигә азапланырга һәм вакыт әрәм итәргә соң! Әмма минем кулыма чын китап эләгә икән, мин аны төн йокламыйча да укып бетерергә әзер!

КӘГАЗЬМЕ, ӘЛЛӘ ЭЛЕКТРОНМЫ?

Мин әсәрләремне ноутбукта язарга бик озак күнектем – кулыма каләм тотмаган килеш минем башым уйларга теләми иде. Әмма мин үземне җиңдем һәм хәзер кулдан автограф кына бирәмдер. Укуга килгәндә исә, монда минем таләбем катгый – кәгазь китапка өстенлек бирәм. Хәтта аны кулында гына тотып торсаң да, яки йоклаганда янәшәңдә генә ятса да, хисләр бөтенләй башка төрле. Кәгазь формат беркайчан да юкка чыгарга тиеш түгел!

КИТАП МИНЕМ ӨЧЕН НӘРСӘ УЛ

Ул минем тормышым, минем университетларым. Укырга һәрвакыттта вакыт таба идем. Өйдәге кабинетымда өч диварны китапханә алып тора. Мин бу китапларга карыйм да – барысы да таныш, һәркайсын кулга алып кабат укыйсы килә. Әлбәттә, бу мөмкин түгел, шунлыктан сайларга туры килә – кайсын хәтердә яңартырга мөмкин, кайсындыр исә икенче юлы укып ләззәтләнермен, дип күңелне юатам. Ә бит дөньяда әле яңа китаплар да никадәр! Аларның кайберләрен хәтта кибеттә үк укый башлыйсың.

PRESSA

«ОЗЫН-ОЗАК БАЛАЧАК»КА БИЛЕТ

Ксения Сёмина

Эзләнү, яңарышка омтылу, мөгаен, Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында балалар һәм үсмерләр өчен иҗат ителә торган спектакльләрнең халәтен (яки кәефен) шулай дип атап буладыр. Бу ни өчен кирәк соң?

Фото: karievteatr.ru



Сәхнәдә – XX гасыр башында татар авылында яшәүчеләрнең аклы-каралы сын-фотосурәтләре. Алар өчен актерлар сөйли. Алар баш герой Кендек һәм аның Олы Инәенең (ул – авылның Кендек әбисе) чираттагы тапкыр бәби таптырырга баруы хакында бәян итә. Кендек күзеннән карaганда, әйләнә-тирәдәге кешеләрнең тормышы гаҗәп һәм куркыныч, рәхимсез һәм сөю тулы булып күренә. Актерлар һаман яңадан-яңа персонажларны чыгара тора, аларга төрле төстәге тасма-хисләрне бәйли, аларның кошлар сайрап торган читлек-йөрәкләрен ача... Мостай Кәримнең повесте тамаша залына атлап кергәндәй тоела, һәм без, ниһаять, «бәхетле дә, бәхетсез дә балачагыбызның озын-озак еллар буе безнең арттан нигә ияреп баруын, дөресрәге, аның беркая да китмичә һаман күңелебездә яшәвен» аңлыйбыз.

Әлеге «Озын-озак балачак» гаилә спектакленең Кариев театры сәхнәсендә премьерасы узган ел булды. Ул вакыттан бирле труппа инде берничә яңа спектакль чыгарырга өлгерде. Яңа спектакльләр бер-берсен алыштыра: экияттән соң лирик повесть, аннары драма һәм кабат экият куела – шулай өзлексез дәвам итә. Сүз уңаеннан, бу театрда динамика һәрвакыт хәрәкәт кенә дә түгел, еш кына ул – форма, төс, яктылык, костюмнар, бию пластикасы, декорацияләр дә. Сюжетларга яңа яңгыраш бирергә сәләтле һәр нәрсә – татар телендә, һәм аңарда гына да түгел. Яшь тамашачы театры спектакльләре – күп актерлар уйнаган, еш кына бик төрле куелыш стиленә ия чакырылган режиссерлар иҗат иткән, әмма һәрвакытта да бик матур манзара ул. Менә театрның баш режиссеры Ренат Әюпов Америка балалар язучысы Кейт Дикамиллоның «Куян Эдвардның гаҗәеп сәяхәте» экияти повестен Татарстанда татар телендә беренче тифлокомментарийлы спектакльгә әверелдерә. Менә Бурятия режиссеры Сойжин Жамбалова төрек шагыйре әсәрләре буенча «Хикмәт экиятләре»н куя. Менә инде «Бер экият лабораториясе»ндә катнашучы балалар Камыр батыр турындагы татар халык экиятендәге батырны супергерой сәләтләренә ия заманча персонажга әйләндерә. Балалар репертуары спектакльләре – төрле планеталардан җыелган төсле. Һәм һәркайсының үз тарихы һәм үз максаты бар.

1, 2
«Озын-озак балачак» спектакле.

3, 4
«Тимур һәм комета» спектакле.

16 ЯШЬКӘ КАДӘРГЕЛӘРГӘ ТӘГАЕНЛӘНӘ

– «Озын-озак балачак» – күп тапкырлар куелган әсәр. Безнең аны үзгәрәк итеп сәхнәләштерәсе килде. Рәссам Альберт Нестеров белән менә нәрсә уйлап таптык: узган гасырда яшәгән татарларның фотосурәтләрен интернетта табып, аларга Мостай Кәрим геройларының сыйфатларын бирергә булдык, – дип сөйли спектакльнең режиссеры Илсур Казакбаев. – Шунысын да әйтергә кирәк: яшь барган саен мин прозаны, авторның кешеләрне, табигатьне, әйләнә-тирәне сурәтләвен ярата башладым. Бу яктан караганда Мостай Кәрим тексты башкортча да, татарча да – гаҗәеп. Мин аны мөмкин кадәр күбрәк калдырырга, тамашачыга да аның матурлыгын тою мөмкинлеген бирергә булдым. Спектакльне карагач, аның бу әсәрне табып укыйсы килсен. Ике-өч кенә кеше шулай эшләсә дә, мин бик шат булыр идем.

Әмма һәр спектакльне ниндидер уникаль тамашага әйләндерү нигә кирәк соң? Яңа пьесаларның берсе артыннан берсе куелып торуыннан ни файда? Эш шунда ки, кариевлыларның үз тамашачылары – балалар һәм үсмерләр белән сөйләшәселәре килә. Монда исә стасис була алмый.

– Безнең максат - яшь тамашачыбызның спектакльдән соң уйлануына, икенче юлы яшьтәшләрен дә театрга чакыруына ирешү, - ди Г.Кариев исемендәге театр директоры Луиза Янсуар. - Һәм балалар, яшьләр белән диалог кора алу хакына, без еш кына фикер алышу, укытучылар, экспертлар белән аралашу форматына, пьеса авторлары, сәхнәләштерүчеләр белән очрашуларга өстенлек бирәбез. Безгә театрның тере булуы, сулый, сөйли, кабул итә белүе һәм үзенә тартып торуы мөһим.

– Мин бик күп әсәрләр укыйм, шул исәптән хәзерге заман авторларыныкын да. Бүген язучының яшь укучы яисә тамашачыга карата позициясе үзгәрә бара. Акыл өйрәтү юкка чыга, аңа алмашка бертигез дәрәҗәдә аралашу килә, еш кына сабыйның яки үсмернең үз исеменнән әйткән сүзләре пәйда була, – ди театрның әдәбият бүлеге мөдире Ләйсән Фәизова. – Ихтимал, бу балалар өчен «безнең заман геройлары» аларның үзләре булгангадыр. Өлкәннәр кебек үк, аларның да үзләре, проблемалары – аралашудагы кыенлыклар, ата-аналар һәм өлкәннәрнең аңламавы, ялгызлык, үзләрен эзләү турында спектакльләр карыйсы киләдер. Һәм без әлеге теләкләрне үтәргә омтылабыз.

БАШКАЛАРГА АҢЛАТ

Театр үз тамашачысына тагын да якынаю юлларын эзли. Полина Коротычның «Вадик поет свою музыку» шигъри пьесасының татарчага тәрҗемәсе буенча Мәскәү режиссеры Тимур Шәрәфетдинов Кариев театры сәхнәсендә «Тимур һәм комета» спектаклен куйган. Ул үз--үзен күрсәтү мөмкинлеге эзләп, сөйләшә торган Мәчесен һәм Песнәгеен алып, ташландык «Икеа»га үз шәһәрен төзергә киткән малай турында. Бераз сюрреалистик сюжетлы һәм гадәти булмаган шигъри формадагы спектакль гади һәм һәркемгә бик якын булган нәрсәләр турында сөйли. Әкренләп Тимур аңа ялгызлык түгел, бәлки үзен яраткан, аңлаган һәм ярдәмгә килергә әзер торган кешеләр кирәк булуын аңлый.

– Бу пьеса нәрсәгәдер өйрәтергә тиешме? Мин, театр баланы нәрсәгә дә булса өйрәтергә тиеш, дип бөтенләй уйламыйм. Ул ниндидер хисләр кичерү, аларның спектрын киңәйтү мөмкинлеген бирергә, балалар һәм ата-аналар өчен аралашу мохитен булдырырга тиеш. Алар бер-берсенә спектакльне аңлата. Һәм бу аларны бик якынайта. Мин театрның балаларның, шулай ук өлкәннәрнең дә, эмпатиясен үстерүгә булышуын теләр идем. Безгә менә шул кирәк, – ди Полина Коротыч үзе.

«ЮТУБ» МОХИТЕ ТҮГЕЛ ИНДЕ

Кариев театрындагы спектакльләр өлкән яшьтәге кешегә дә яңа эмоциональ тәҗрибә бирерлек итеп эшләнгән. Әлеге тылсым, мөгаен, театрга килүче гаиләләрнең үзара аралашуын уңайлы һәм файдалы итү теләгеннән туадыр.

– Социаль челтәрләрдә театрдагы кебек атмосфера юк бит. Шунлыктан мин спектакльләргә йөрим. Миңа геройлар дөньясына кереп чуму ошый. Кайвакыт бу үзеңнең нинди дер проблемаңны читтән күреп алып, аны хәл итү юлын табарга булыша, – ди 11 яшьлек Мәликә.

– Үзеңне, башкаларны аңлау, безнең барыбызның да төрле булуны кабул итү мөһим һәм дуслардагы әлеге төрлелекнең кадерен белергә кирәк – «Тимур һәм комета» спектаклен карагач, без шулар турында сөйләштек. Ә кече кызыма исә Песнәкнең, үз Твиттерыннан баш тартып, үзе бик теләгән, әмма моңарчы вакыт таба алмаган яраткан шөгыле – бию белән мавыга башлавы аеруча ошады, – ди театрның тугры тамашачылары һәм андагы проектларының даими катнашучылары Мәликә белән 13 яшьлек Энҗенең әнисе Гөлназ. – Минем үземә исә «Хикмәт әкиятләре» бик ошый. Бер үк актерлар беренче әкияттә тискәре геройларны, икенчесендә исә уңай геройларны уйный һәм киресенчә. Мине аларның шулай оста үзгәрә алу сәләте таң калдыра. Һәм мин Кариев театрын нәкъ менә шуның өчен яратам да: артистлар барлык спектакльләрдә дә бөтен көчен куеп уйный.

ТЕАТР – ГАИЛӘ ЭШЕ

– Балалар драмасында иң мөһиме, мөгаен, намуслылык һәм ышанычтыр. Сабыйлар бик нечкә күңелле һәм, әгәр алар синең сүзең яки уеныңда фальшь тоя икән, синең белән кызыксынуы шундук югалачак. Без аларга дөньяның төрле булуы, анда фаҗигаләр һәм көенечләр очравы, әмма шул ук вакытта җиһанның яктылык һәм игелеккә дә бай булуы хакында ихластан сөйләп бирергә тырышабыз, – ди «Хикмәт әкиятләре», «Озын-озак балачак» һәм башка спектакльләрдә баш рольләрне башкаручы актер Булат Гатауллин. – Бу җәһәттән минем өчен иң җитди тамашаларның берсе – «Куян Эдвардның гаҗәеп сәяхәте». Мин анда фарфор куянны уйныйм: югалтулар, ялгызлык куркынычы, якыннарының үлеме аны эгоисттан сизгер йөрәкле, дуслаша һәм ярата белгән тере җан иясенә әйләндерә. Эдвард әкренләп шуны аңлый: яхшылыкка өметләнәсең һәм ышанасың икән, җиһан чыннан да яхшыракка әйләнә ала.

Кариев театры спектакльләренең барысы да диярлек гаилә белән карауны күз уңында тота. Балалар һәм ата-аналар диалогы өчен мәйдан булдыруга биредә зур әһәмият бирелә.

– XIX гасырда берничә буын катнашындагы өй театры традициясе бик киң таралган була. XX гасыр күмәк яшәү һәм вакыт уздыру кагыйдәләрен үзгәртә. Хәзер исә мондый традицияләр торгызыла, гаилә театрлары фестивальләре дә бар хәтта. Бу бик кызыклы, илһамландыргыч тәҗрибә. Безнең дә кайчан да булса шундый проект оештырасыбыз килә, – ди Ләйсән Фәизова.

Хәзер Яшь тамашачы театрында яңа спектакль репетициясе бара. Илсур Казакбаев быел яшь тамашачыларга катлаулы тормыш проблемалары турында Минзәлә драма театры сәхнәсендә куелган «Җинаять һәм җәза» спектакле премьерасында сөйләгән иде инде. Хәзер режиссер кабат классикага алынган, бу юлы Шекспирның «Ромео һәм Джульетта»-сы. Спектакльнең премьерасы 19 октябрьдә булыр, дип көтелә.

5 «Хикмәт әкиятләре» спектакле.

6 «Куян Эдвардның гаҗәеп сәяхәте» спектакле.

КАРГАЛЫ КАРГА





Фото: Александр Ефремов

КАРГА

Әлки районында Карга исемле авыл бар. Иң кызыгы – бу авылны каргалар үз иткән. «Бөтен район каргалары бездә», – ди җирле халык. Аеруча көзен күбәяләр икән. Каргада тагын кемнәрне, ниләрне күрдек? Төзек, матур авылда яшәүчеләр нәрсә турында хыяллана? Шушы сорауларга җавап табып кайттык.

Руфия Фазылова

АВЫЛ ЭЧЕНДӘ ТАНК?!

Карга авыл җирлегенә бүтән авыллар керми. (Бүген бит унбишәр авылны берләштергән җирлекләр бар). Биредә 417 кеше теркәлгән, шуларның 357се даими яши, 140 йорт бар. Авылда бер генә юлсыз урам да юк. Үзәк юлларга асфальт түшәлсә, кечкенә урам юлларына таш җәелгән. Кайсын үзсалым акчасына, кайсын «яхшы күңелле авылдаш» хисабына салганнар.

Иң беренче авыл уртасындагы зур парк игътибарны җәлеп итте. Әйе, хәзер авылларда да әллә нинди ял парклары бар. Ләкин биредәгесе үзгә – анда чын танк белән «Катюша» сугышчан машинасы тора. Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә урнаштырылган ул. Шулай ук «яхшы күңелле авылдаш» бүләге икән. Аның кем икәнен бездән яшермәделәр – Фоат Вәли улы Вәлиев, ТР Дәүләт Советы депутаты, Алексеевск юллар төзү һәм эксплуатацияләү оешмасының Директорлар советы әгъзасы.

– Күптән түгел Фоат Вәлиевич Мәдәният йортына капиталь төзекләндерү үткәрде, – диде Карга авыл җирлеге башлыгы Рамил Минһаҗев. – Ул хәзер күпфункцияле үзәк дип атала: медпункт, авыл җирлеге идарәсе, китапханә, почтаны үз эченә алды. Җылы, якты, заманча бүлмәләрдә эшлибез. Барысы да бер җирдә булгач бик уңайлы.

Күпфункцияле үзәкне без дә карап чыктык, аеруча медпункт күңелгә хуш килде. Ике яклы, процедуралар өчен бөтен уңайлыклары бар. Фельдшер Роза Галиева бик тәҗрибәле белгеч – кырык елга якын шушы өлкәдә кайный. Заманында өйләрдә бала да таптырган. Әле дә бөтен процедураларны үзе ясый. Теләсә кайсы җире

авырткан кеше башта Роза апа янына бара. «Безне өйдә генә аякка бастыр, читкә барып йөрисе килми», – диләр икән. Әлбәттә, берәр җитди авыру булса, фельдшер авылдашларын район хастаханәсенә җибәрә.

– 1986 елда Буа медицина училищесын тәмамладым, – диде Роза апа. – Үзем Әлки районында туып үскән булсам да, укырга әнинең туган ягына дип бардым. Ул Тәтеш районыннан. Менә шул вакыттан бирле бу хезмәттә. Нинди генә очраклар булмады, сөйләсәң ис-акылларың китәрлек, сеңлем. Элек бит юл юк, күпер юк. Теләсәң нәрсә эшлә, кешенең гомерен саклап калырга кирәк. Шуның өчен бик җитди карарлар кабул итәргә туры килде. Аллаһка шөкер, фаҗигале хәлләр булмады.

Каргада бердәнбер проблема – эчә торган суның сыйфаты бик үк яхшы түгел. Аерым урамнарда бигрәк тә. Гаҗәп, биредә чишмәләр юк. Эчәргә яраклы су шактый ерак – йөз метр тирәнлектә урнашкан. Шуның өчен махсус фильтрлар куеп, суның сыйфатын контрольдә тотарга туры килә.

1
Авыл уртасындагы зур парк игътибарны җәлеп итте.

2
Паркта чын танк белән «Катюша» сугышчан машинасы тора.

3
– Барысын да санитар таләпләргә туры китереп эшлибез, – диде биредә эшләүче Хәлил Вазыйхов.

ИТ ЭШКӘРТҮ ЦЕХЫ

Каргада дүрт ел элек ит эшкәртү цехы ачылган. Авылның уникe кешесе шунда эшли. Аена йөзләгән мал-туарны хәләл стандартлар буенча чалалар. Шунда ук пилмән цехы да урнашкан. Түшкәләрне бүлгәләп, фарш ясыйлар. Итне аерым кисәкләргә бүлеп тә зур туңдыргычларда катыралар. Барлык продукция дә шәхси бер эшмәкәрнең хәләл кафе, кибетләренә китә. Шунда ук зур булмаган теплица да бар. Анда ел әйләнәсе яшел тәмләткечләр үсә.

– Малларны халыктан җыябыз, – диде биредә эшләүче Хәлил Вазыйхов. – Барысын да санитар таләпләргә туры китереп эшлибез. Авыл кешеләренә дә барып терлек чалабыз. Кемдер монда да алып килә, кыскасы, бу мәсьәләдә авылда эш җайланган.

Ит эшкәртү цехындагыларның күбесе ачылган вакыттан бирле биредә хезмәт куя. Арада хатын-кызлар күбрәк, алар пилмән цехында эшли. Ул апалар белән дә аралашып алдык – кемдер лаеклы ялда булса да эшләп йөри. Декреттан соң эшкә чыккан ханымнар да бар. «Хезмәт хакы әйбәт, вакытында түлиләр», – диештеләр.

Пилмән цехы бүлеге җитәкчесе Гүзәл Хәсәнҗанова гаиләсе белән Каргада яши. Биш малай әнисе. Бирегә килгәнче, Базарлы Матакка барып, район хастаханәсендә эшләп йөргән. Ит эшкәртү цехына эшкә чакыргач, сөенә-сөенә урнашкан.

– Башта берничә көн эшкә өйрәндек, – диде Гүзәл ханым. – Беребезнең дә эш тәҗрибәсе юк иде. Хәзер инде чын остага әйләндек. Ундүрт төрле продукция ясыйбыз. Тавык ите, сыер итеннән ике төрле кәтлит, өч төрле мантый, өч төрле пилмән, тефтели, голубцы, чебуреки – барысы да бар. Эш сәгате иртәнге сигездән бишкә кадәр. Иртән кызларыбыз сыерларын савып, өйдәге эшне бетереп килә, кичке савымга тагын кайтып өлгерәләр.

Биредә эшләүче хатын-кызларны гаҗәпләнеп күзәттем: куллары кулга йокмый. Шулай сөйләшә-серләшә көненә меңәр пилмән ясыйлар икән. Эшкә дә булган, телгә дә үткен алар, кыскасы, чын әлкиләрчә!

Авылның тырыш апалары турында сүз чыккач, Чулпания Фәттахова турында да әйтми кала алмыйм. Авылның остабикәсе ул, ашларда Коръән укый, мөнәҗәтләр әйтә. Авыл кешеләре аны яратып «Акъәби» дип йөртә. Яшьрәк чагында Чулпания апа җырлаган да. Хәер, әле соңгы елларда да зур сәхнәләрдә чыгыш ясап йөргән, «Балкыш» фестивалендә берничә тапкыр катнашкан.

– Безнең балачак бик авыр елларга туры килде инде, – диде Чулпания апа. – 1957 елда Карга авылында совхоз оешты, мәнә шуннан соң гына халыкка аз-маз акча түли башладылар. Ә аңарчы «таякка» эшләп йөрдек. Шул елларда эти-әниләргә пенсия дә бирә башладылар. Хәтерлим, сигез сум иде ул. 1960 нчы елларда туйганчы ипи ашый башладык. Мин шул елны кияүгә чыктым, шуңа да истә калган. Акрын гына йортларга ут керә башлады, балаларның өс-башлары да ярыйсыланды. Безнең авыл гомергә тырыш булды, начар яшәдек, дия алмыйм. Терлеген дә асрадык, эшенә дә йөрдек. Хәзер дә тырыша авыл кешесе – ихата тулы терлек, бакчасында ни генә үстерми...

МӘКТӘПЛЕ АВЫЛ

Менә шулай дип сөенеп яшәргә калдык: мәктәпле авыллар елдан-ел кими. Каргада төп белем бирү мәктәбе матур гына эшләп килә. Утыз бала укый, бу бер Карга балалары гына. Әйе, башка бик күп авыллардагы кебек үк, биредә дә укучылар кимегән. Тик соңгы елларда балалар саны гел бер тирә – утыз тирәсе икән. Якын киләчәктә хәл шулай калачак.

– 2000 елда мәктәбебез янды, ике ел эчендә яңа урында, яңа белем учагы төзеделәр, – диде Карга мәктәбе директоры Гөлнара Шәйхетдинова. – Димәк, бу бинада егерме ел эшлибез.

4 Мәдәният йорты хәзер күпфункцияле үзәк дип атала.

5 Фельдшер Роза Галиева.

6 Ит эшкәртү цехында ундүрт төрле продукция ясыйлар.

7 Чулпания Фәттаховны авыл кешеләре «Акъәби» дип йөртә.

8

Карга төп белем бирү мәктәбендә утыз бала укый.

9

Коридорда шахмат уйнау почмагы бар, аерым түгәрәк тә эшли.

10

Яңа мәктәп бинасы 2002 елда төзелгән.

Шуннан бирле косметик ремонт белән генә мәктәпне яңартып киләбез. Балалар гына булсын, бинабыз бик әйбәт әле.

Гөлнара Шәйхетдинова мәктәптә рус теле һәм рус әдәбияты укыта. Мәктәп директоры булып дүртенче елын эшли икән.

– Бала саны бик аз түгел, бик сөенәбез, – диде ул. – Иң кечкенә сыйныфта өч бала, иң зурысында – тугыз. Ләкин алар тәнәфесләрдә гел бергә. Коридорда шахмат уйнау почмагы булдырдык, аерым түгәрәк бар. Шулай ук коридорда теннис та уйныйлар, бергәләп бәйрәм, кичәләргә әзерләнәләр. Кыскасы, бер гаилә без.

Авылның ун баласы район үзәгенә – Базарлы Матакка йөреп белем ала. Моның сәбәбе – Карга төп белем бирү мәктәбендә төп фәннәр татарча укытыла. Ә район үзәгенә йөреп укучы ул малай-кызларның татарчалары аксый икән.

– Ул балалар катнаш гаиләдә тәрбияләнә, – диде мәктәп директоры. – Читтән күчеп кайткан гаилә дә бар. Аларга рус телендә укырга җайлырак. Хәзер бит программалар авыр, өй эшләрен әзерләгәндә эти-әниләр дә ярдәм итә. Ә татарчага тәрҗемә ителгән дәреслекләр бик катлаулы, татарчаны камил белмәгән бала аны аңламаячак. Шуның өчен дә ул эти-әниләргә үпкәбез юк, бу аларның хокукы. Базарлы Матактан һәр көнне автобус килеп ала, кайтарып куя. Ун белән унбергә үзебезнең укучылар да район үзәгенә барып укый.

Мәктәпнең укытучылары белән дә таныштым. Барысы да диярлек тәҗрибәле укытучы икән. Балаларның уку өлгереше яхшы, бишкә генә укучылар да бар. Соңгы төп дәүләт имтихан нәтиҗәләре «4» тә «5» кенә булган.

– Балаларыбыз бик тәрбияле дә, үткен дә, – диде мөгаллимнәр. – Башка авыллардан килгән укытучылар да: «Сезнең балалар бик ачык», – диләр. Бу чынлап та шулай, алар теләсә кайсы очракта да югалып калмый. Мәктәпне тәмамлагач та, яхшы уку йортларына кереп, тормышта үз юлларын табалар.

«КАЗЛАРГА ИХТЫЯҖ ЗУР»

Мәктәптә үк балаларны аналарча кайгыртучы мөгаллимә Мәдинә Хөсәеновага күзем төшкән иде. Карга авыл җирлеге башлыгы Рамил Минһаҗев безне Мәдинә апаларга аерым алып барды. Сәбәбе бар – Хөсәеновлар авылда күп итеп каз асраучы гаиләләрнең берсе. (Авыл уртасында күл бар, меңәрләгән баш каз җәй буе шунда үсә.) Ел саен ике йөз баш казны үстереп урнаштыралар икән.

– Әйдәгез, казларны күрсәтәм, – дип, хуҗабикә безне арткы якка алып чыкты. Мәктәптән кайтып өс-башын алмаштырган да, Мәдинә апа әнә шулай кош-кортлары янына чыккан. Җәмәгате Рафик абый фермер икән, ул эштә иде.

– Ел да Линда токымлы казлар алабыз, – диде хуҗабикә. – Узган ел 160 баш алган идек, быел 200 иттек. Сорау булгач, үстерергә күңелле.

– Ә кемнәргә сатасыз? – дим.

– Дистә елдан бирле даими сатып алучыларыбыз бар. Базарлы Матактан күп килгәләр. Бер алганда утыз, кырык казга заказ бирәләр. Инде бүгеннән үк бу казларга хуҗа бар.

– Өмә ясап йолкыйсызмы?

– Юк, берүзем йолкыйм. Эштән кайткач, унар баш та суйган чаклар бар.

–?!

– Әйе (көлә). Егерме биш яшьлек өйләнмәгән төпчек улыбыз бар, ул да булыша. Мин аны үз белгәнемчә шулай акрын гына эшлим. Башта түшкәләрне марля аша элеккеге үтүк белән үтүклим. Ә үтүкне алдан газда тотып алам. Теләсә кайсы эштә осталык кирәк, ә ул еллар буе эшли-эшли килә. Һәркемнең яхшылап йолкынган, чиста, ялтырап торган каз аласы килә. Казны еш кына бүләк, күчтәнәч итеп бирәләр бит. Гел әйтәм: каз бәбкәләрен үстерү алай ук катлаулы түгел, ә менә сатуга әзерләү пөхтәлек, саклык сорый. Казның тиресен ертырга, артык кайнар пар белән пешерергә ярамый. Ана казларны йолку аеруча авыр, аларның тиресе юкарак, йомшаграк, бозып куюың да мөмкин. Шуның өчен белеп кенә эш итәргә кирәк.

Мәдинә апа җәмәгате белән өч бала тәрбияләп үстергән. Алар бүген туган нигезләреннән читтә яши. Ир белән хатын Рафик абыйның әти-әнисен соңгы юлга тәрбияләп озаткан. Ә хәзер исә Мәдинә апаның әтисен үзләренә алып килгәннәр.

– Ирем озак еллар совхозда инженер булып эшләде, – диде хуҗабикә. – Ул иртәдән кичкә кадәр кадәр эштә була иде. Өч балабызны тәрбияләргә каенанам белән каенатам булышты. Мин дә бит көне буе мәктәптә. Укытучының дәрестән тыш та күп эше барлыгын алар яхшы аңлый иде, аларга бик рәхмәтлемен.

Мәдинә апа лаеклы ялда инде, алты дистәне тутырган. Тик һаман әле мәктәптә эшләп йөри – Карга төп белем бирү мәктәбендә рус теле, рус әдәбияты укыта. Бер ел эшләми дә торган, тик аннары яңадан чакыртып алганнар.

11
– Мәктәптән кайткач, унар баш каз йолкыйм, – диде Мәдинә Хөсәенова.

Хөсәеновлар гаиләсендә «Каз нәзере» дип аталган кызык бер йола бар. Аны Мәдинә апага тумышы белән Кама Тамагы районыннан булган каенанасы өйрәтеп калдырган. «Каз нәзере» ул – казларны эшкәртеп бетергәч мәҗлес җыю. Бер елны Мәдинә апа чирләп китеп, кунак җыймыйча, сәдака гына таратырга уйлый. Шул көнне «үз өлешләрен сорап килгән» казлар төшенә керә. Шуннан бирле мәҗлес үткәрергәме-юкмы дигән сорау тумый икән.

– Кунакка авылыбызның хәзрәтен, барлык туганнарны һәм якыннарны чакырам, – диде хуҗабикә. – Каздан зур бәлеш әзерлим, каз маенда коймак пешерәм, кош түшкәсен дә пешереп табынга куям. Мулла Коръән сүрәләре укый, алга таба да зур табын янында күпсанлы туган-тумача җыелсын, дөньяларыбыз тыныч булсын, дип теләк тели.

...Карга табигатьтә әллә ни купшылык белән аерылып тормый. Зыян салып йөрүче дә бит. Ә менә Карга авылының исеме җисеменә туры килми. Карлыгач кебек тырыш алар – авылда күп итеп мал-туар асрыйлар. Шуның өчен дә тормышлары мул.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Гөлүсә Закированың «Каргауыл» китабыннан:

– Карга авылының барлыкка килү вакыты төгәл билгеле түгел. XVII гасыр документларында Карга – «Актай елгасының югарырак ярындагы Яңа Ахтачы», «Югары Ахтачы, шул ук Карга» кебек исемнәр белән искә алына. «Югары» һәм «Яңа» дигән билгеләмәләргә караганда, Карганың XVII гасырның I яртысында барлыкка килгән Ахтачы-Базяково һәм Ахтачы-Садыйков авылларыннан соңрак нигезләнүе ачыклана.

Авыл исеме хакында халык хәтерендә бердәнбер риваять сакланып калган: «Борынгы заманда кешеләр, бераз калкурак урынны сайлап, шунда килеп төпләнә башлаган, авыл барлыкка килгән. Ләкин аның исеме булмаган. Уйлашканнар да мондый карарга килгәннәр, имеш. «Бер ялгыз агач тирәсенә җыелырга һәм шул агачка иң беренче нинди кош килеп куна, авылны шул кош исеме белән атарга». Халык җыелгач, агачка карга килеп кунган, имеш. Шулай итеп авыл Карга исемен йөртә башлаган».

КӨЗГЕ ТӨСЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА

Көзен безне һәр яктан сары, яшел, коңгырт, җирән төсләр әйләндереп ала. Җете төсләр безгә өстән ява, аяк астында кыштырдый, агачтан агачка сикерә, чыршы асларында үсә, ә кайвакыт, кызганычка каршы, каз-тавыклар янына «кунакка» килә. Менә шундый җылы алтын көз манзарасын сезгә дә тәкъдим итәбез!

Фото: Сергей Белобров, Анастасия Хатыйпова

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Сайттагы яңалык
Яңалыклар

Реклама 16+

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан»журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+